www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 22 (1438) 9 июнь 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

8

“Чура батыр” дастаны аша татар тарихын, һәм, киресенчә, милләтнең үткәннәре аша дастан эчтәлеген өйрәнү кирәк.

12

Чаллының А. Гыйләҗев исемендәге театры узган иҗат фасылында төрле юнәлешләрдә, төрле рухтагы тамашалар тәкъдим итте.

24

Авылдагы клубны Фәүзия Әхмәтшина кебек оста куллы, тиктормас зат җитәкләсә, бөтен авыл чигә башласа да гаҗәп түгел.

Сабан туе борын-борынгыдан Бил бирмәскә безне өйрәткән!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● Ленинград өлкәсенең Тосно шәһәрендәге Ушаки ял итү һәм халык иҗаты үзәгендә җырчы, Татарстанның халык артисты Рәшит Ваһаповның искә алу кичәсе узды.

● Әтнәдә сыерчык бала очырганда үткәрелә торган «Әләшә» бәйрәме булды.

● Әлки районында «Татар гаиләсе: гореф-гадәтләр» китабының презентациясе узды.

● Татар артистларының иҗаты белән танышу, аны популярлаштыру; артист һөнәренә хөрмәт тәрбияләү максатында Бөтендөнья татар конгрессы «Минем яраткан артистым» конкурсын игълан итте.

● Татарстанның Мәскәүдәге Тулы вәкаләтле вәкиллеге карамагында эшли торган Мәдәният һәм сәнгать әһелләре клубында Профессиональ композиторлар ассоциациясе оештырылды.

● Кыргызстанда узган «Мәгълүмати җәмгыятьтә хәтер институтлары, китап һәм уку» халыкара конференциясендә Г.Тукай әдәби музее директоры Гүзәл Төхфәтова мирасханә эше һәм Тукай китаплары турында чыгыш ясады.

● Башкортстанның Зилаер районы Иске Якуп авылында республика символы – курайга һәйкәл куелды.

● Казандагы Республика балалар клиник хастаханәсе җирлегендә «Әбүгалисина» мәчетеннән һәм православие чиркәвеннән торачак «Тыныч бакча» рухи үзәк комплексы төзелеше башланды.

● Татарстан рәссамнарының эшләре Истанбулда «АртКонтакт – 2023» халыкара сәнгать күргәзмәсендә тәкъдим ителә.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Мәгъсүм ГӘРӘЕВ, журналист, публицист-язучы:

«Татар журналистикасы үлмәсен өчен, үткен каләмле журналистлар кирәк. Аларны әзерләүче кешеләр кирәк. Булачак журналистларны Казан университетында укытып, яхшы журналистлар әзерләп булмый. Шуңа бик яхшы мисал – Г.Камал театры артистларының Михаил Щепкин исемендәге Югары театр училищесында укып кайтуы. Шуннан соң Нәҗибә Ихсанова, Туфан Миңнуллин, Равил Шәрәфи, Ринат Таҗетдинов һ.б. кебек чын артистлар кабынды. Аларны дөньяның классик артистлары укытты».

СЫНАМЫШЛАР

10 июньдә тыныч һәм җилсез булса, игеннәр уңа ● Шөпшәләр күп очса, көн аяза ● 11 июньдә карабодай чәчәләр ● 14 июньдә болытлы йә яңгырлы булса, киндер һәм җитен уңа ● Яңгырдан соң салават күпере чыкса, көн аяза.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 02 минутта** чыкты, һәм ул **20 сәгать 25 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **17 сәгать 23 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **9 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **16 июньдә 17 сәгать 32 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

13 июнь – рәссам Радик Вакыйф улы Минһаҗевка 60 яшь (1963).

15 июнь – язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Зөфәр Мирхәйдәр улы Дәүләтовка 70 яшь (1953);

– актриса, Татарстанның халык артисты Зөлфирә Сафа кызы Зариповага 70 яшь (1953);

– рәссам Әнвәр Камил улы Сәйфетдиновка 60 яшь (1963);

– гамәли бизәлеш рәссамы Фәридә Мирзанур кызы Сәхабетдиновага 60 яшь (1963).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Июньнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(10-18 июнь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген зөлкагдә аеның 20 нче көне

ХАЛЫК ҖЫРЧЫСЫ БҮЛӘГЕ

Г.Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең концерт залында олуг җырчыбыз Илһам Шакиров исемендәге II республика премиясен тапшыру тантанасы узды.

Бу дәрәҗәле бүләк, бөек җырчының юлын дәвам итеп, җыр традициябезне саклап калу максатында 2020 елның 22 августында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән рында яшьләрнең дә күренгәләве күңелне күтәрде.

Бүләкләү тантанасында республикабызның Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразыев катнашты. Ул олуг җырчыбыз И.Шакиров рухын мәңгеләштерү өчен башкарып өлгергән эшләрне барлады. Туган ягында музей ачу, Казаныбызның бер урамына Илһам Шакиров исемен бирү, «Казан Экспо» концертлар залын аның исеме белән исемләү һәм, ниһаять, премия шул эшләр рәтендә. 2025 елда Илһам аганың тууына 90 ел тулачак, һәм без бу көнгә ныклап әзерләнергә тиеш, диде Премьер-министр урынбасары.

гамәлгә куелган иде. Аны ике елга бер тапшырырга карар кылынды. 2021 елның 15 февралендә, И.Шакировның туган көнендә, премиягә өч җырчы – академик вокал төрендә Резидә Галимова һәм Филүс Каһиров һәм халыкчан җырлау номинациясендә Флер Шакиров ия булган иде.

Илһам ага исемендәге бүләкне тапшыру затлы, матур концерт рәвешендә үтә. Аны карарга тамашачы быел да зал тутырып килде. Башлыча өлкән яшьтәге милләттәшләребез И.Шакиров җырларын сагынып килгән, чөнки бүген аларны зур сәхнәләрдә сирәк ишетәсең. Әмма арала-

Шуннан соң бүләкләү тантанасы булды. Быел дәрәҗәле бүләккә академик җырлау төрендә Флёра Сөләйманова һәм Фердинанд Сәлахов, халыкчан җырлау номинациясендә Г.Камал театрының күренекле артисты һәм халык җырларын башкару остасы Әсхәт Хисмәт белән Башкортстанда яшәүче милләттәшебез, гомер буе инженер булып эшләсә дә, гармунын кулыннан төшермәгән, күпләгән музыкаль бәйгеләрдә лауреат булган Фәүдәт Гыйләҗев ия булды.

Ни кызганыч, Флёра Сөләйманова премияне тапшыру тантанасына килә алмаган. Тамашачы аның башкаруында «Әниемә» җырын видеоязма аша тыңлады. Җырны Казан шәһәр филармониясенең «Чулпан» балалар ансамбленең җырлап бетерүе символик мәгънәгә ия. Җыр сәхнәсен дистә еллар тоткан олпат шәхесләребез китә барса да, аларның эшен дәвам итәрдәй яшьләребез бар, дигән мәгънә салынган иде бу чыгышка.

Быелгы концерт аеруча мәгънәле, эчтәлекле булды кебек. Сценарий авторы шагыйрә Илсөяр Иксанова һәм режиссер, күренекле артист Илдар Хәйруллин җырларны зур шагыйрьләребезнең Илһам агага, милли җыр сәнгатебезгә багышланган һәм милләт язмышы турында шигырьләре белән аралаштырган. Аларны сәхнәдән Г.Камал театры артистлары Искәндәр Хәйруллин һәм Фәннүр Мөхәммәтҗанов укып ирештерде.

«...Алар – безнең,
яңа заманның,
Иң алдынгы сәнгать батыры –
Шигърияттә – Тукай,
Музыкада – Сәйдәш,
Сәхнәләрдә – Илһам
Шакиров...»

Шагыйрь Гәрәй Рәхимнең шушы юлларына бөек җырчының бөтен асылы сыйган.

Кичә барышында җырчының шигъри юллары белән зурлаган шагыйрьләрнең дә, җыр авторларының һәм аларга көй иҗат иткән композиторларның да портретлары экраннан күрсәтелү эчтәлекне тагын да тулыландыра төште.

Бериш җырларның иҗат ителү, каян ничек табылуы турында кызыклы тарихларны ишетү дә тамашачы өчен файдалы булгандыр. Кичәне алып баручылар Айзилә Батырханова һәм Ришат Әхмәдуллин, өтерен, ноктасын нәкъ урынына куеп, бу тарихларны истә калырлык итеп җиткерә белде.

Концертта шулай ук җырчылар Алинә Кәримова, Зөлфирә Шәйдуллина, Алмас Хөсәенов, Илгиз Мөхетдинов, беренче премия лауреатлары Резидә Галимова белән Филүс Каһиров, шулай ук Салават Фәтхетдинов катнашып, Рәсим Ильясов җитәкчелегендәге «Казан нуры» халык музыка уен кораллары оркестры белән бергә Илһам ага репертуарындагы һәм башка яраткан, тансык җырларыбызны ирештерде.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мирас җидегән
вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар

Милли-мәдәни вә рухи мирас

Халкыбызның бик борынгыдан килә торган милли бәйрәме – Сабан туйлары вакыты җитте. Татарның җан (милли мәдәнияте), рух (югары милли аңы) һәм тән (татар халкы үзе) берлеген чагылдыра торган һәм борынгы бабаларыбыздан милли-мәдәни вә рухи мирас булараk күчеп килгән ошбу рухи хәзинә тамырлары белән бик тирәнгә – болгар бабаларыбыз чорына ук китә. Мең елларга сузылган яшәү дәверендә халкыбыз төрлесен кичергән: иген иккән, дәүләтләр корган, зур яуларда да катнашкан; бер дәүләте җимерелгәч, яңаларын корган... Ә соңгы биш гасырда инде тоталитар режим шартларында да яшәргә мәҗбүр ителгән. Дөресен әйткәндә, татарның дәүләтчелеге инде бүген дә, халыкара хокук нормаларын тупас бозып һәм референдум нәтиҗәләре белән санлашмыйча, юк дәрәҗәсенә төшерелгән. Ә Сабан туйлары һаман яши һәм халкыбызны, ул кайда гына яшәсә дә, тулы бер милләт итеп саклап килә. Мондый могҗизаның сере нәрсәдә соң? Ә ул сер бик гади ачыла: чөнки ошбу милли мирасыбызның фәлсәфи нигезе нык һәм анда татарның милли-мәдәни вә рухи коды салынган. Шуңа күрә бүген инде ул халкыбызның милли вә мәдәни тәңгәллеген күрсәтә торган аерым форма – гомуммилли статус та алып бара. XXI гасыр башыннан бу бәйрәм Россиянең күп кенә төбәкләрендә һәм милләттәшләребез тупланып яшәгән барлык татар җәмгыятьләрендә дә диярлек зурлап үткәрелә. Шундый ук бәйрәмнәр якындагы һәм ерактагы чит илләрдә яшәүче татар диаспоралары тарафыннан да оештырыла.

Тик бу уңайдан игътибарны бер сәер хәл – бериш милләттәшләребездә бу бәйрәмгә карата яшь торган сансызлык вә җиңелчә караш та җәлеп итә. Сабан туйларының отыры киң колач алуы ни өчендер андыйларның эчен пошыра. Социаль челтәрләрдә алар бу бәйрәмне әһәмиятсез итеп күрсәтү өчен ниләр генә язмый. Ә тел төбе яхшы аңлашыла: янәсе, татар теле, милли мәгарифе бетерелгән бер мәлдә бетмәс-төкәнмәс җыр-биюләр белән халыкның башын катырасыз. Әлбәттә, моның психологик ягын аңларга була: аның нигезендә милли уңышсызлыклар фонында туган кимсенү кәсәфәте ята. Ә татарга аның файдасы бармы соң? Бүгеннән үк Сабан туйларын туктату телнең һәм милли мәгарифнең яңаруына китерерме? Берсе икенчесенә комачауламый бит. Әйе, тел һәм мәгариф тә бик мөһим. Шулай саныйсың икән, тотасың да, шул юнәлешләргә алынасың. Булдыра алмыйсың һәм милли бәйрәмнең тирән мәгънәсен дә аңламыйсың икән, ул чакта инде, һич югы, башкаларга комачаулама. Юкса, бүгенге кыен чорда Сабан туйларын да туктату милли-мәдәни вә рухи мирасыбызның тамырына үз кулыбыз белән балта чабуга тиң булыр иде. Ә бу мирас бүген татар тәңгәллеген саклап калу һәм яңарту механизмының алшартларын билгели, милләттәшләребездә үз халкы тарихына мөнәсәбәтле булу тойгысын көчәйтә, вакыт вә киңлек аша аларны берләштереп, татарларның милли үзгәлеген яңа шартларда булдыру һәм саклау юлларын билгели. Ахыр чиктә болар һәммәсе дә милли экологиябездә тигезлек сакланусын тәэмин итә, шәхеснең үсүе өчен үз халкының мәдәнияте, тарихы һәм бүгенге тормышы белән кызыксынуын арттыра, милләт вәкиле булараk, үз функцияләрен үтәүдә аңа кулай психологик шартлар тудыра.

Әлбәттә, болар һәммәсе дә Сабан туе үзенең чын милли асылына туры китереп үткәрелгәндә генә мөмкин. Шуңа күрә алга куйган югары максатлар милли бәйрәмебезне үткәрү кагыйдәләренә югары таләпләр дә куя. Бу бигрәк тә бәйрәмнең милли рухын, фәлсәфи эчтәлеген һәм мәдәни асылын саклауга, шулай ук аңа йөкләнгән иҗтимагый-сәяси вазифаларның югары дәрәҗәдә үтәлүенә кагыла. Аңлашыла ки, Сабан туенда төп аралашу чарасы булып бары тик татар теле генә хезмәт итә ала. Чөнки, башка очракта, ул бәйрәм инде чын мәгънәсендә Сабан туе булудан туктый. Шуңа татар халкының милли бәйрәмен оештыручылар боларны исләрендә нык тотсын һәм гамәли кулланышка да кертсен иде.

Ә милли бәйрәмебез инде быел да үзенең сезонын ачты. Әйтик, 26-27 май көннәрендә Әстерхан өлкәсендә зур колач вә оешканлык белән XIII Бөтенроссия авыл Сабан туе узды. Кайбер мәгълүматлар буенча, анда 60 мең чамасы кеше катнашкан. Бәйрәм рухын тою өчен, анда катнашучыларның йөзләрен күрү (ә электрон чаралар андый мөмкинлек бирә) дә җитә. Бу атнада (ягъни 10-11 июнь көннәрендә) милли бәйрәмебез Татарстан районнарында һәм авылларында да узачак. Чыгышлары белән авылдан булганнар өчен ул хәзер, мөгаен, елның иң кадерле һәм көтеп алынган бәйрәмедер. Чөнки аларның күпчелеге бүген туган авылыннан читтә, калаларда яши. Ә милли бәйрәмебез аларның җанга иң кадерле җире – туган туфракта бергә җыелуы өчен куанычлы форсат та булып тора. Күпләр үзен хәтта яшьлегенә кабат кайтып килгәндәй дә хис итә. Милли бәйрәмебез – Сабан туйлары белән, кадерле туганнар!

Фоат УРАЗАЙ.

«Гаилә» китапханәсе ачылды

Казанның 27 нче «Гаилә» дип исемләнгән китапханәсе төзекләндерелгәннән соң кабат эшли башлады. Китапханә ачылышында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, ТР Рәисе Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Казан мэры Илсур Метшин, мәдәният министры Ирада Әюпова һ.б. булды.

Китапханә 1980 елларда төзелгән булган. Ремонт эшләре узган елның октябрендә башланган. «Бина яңартылды, төрле уңайлыклар булдырылды, китапханә белән бәйле эшләр автоматлаштырылды, техник мәсьәләләр хәл ителде. Иң мөһиме – биредә 50 меңгә якын данә китап бар, шул ук вакытта укучылар бездә «Литрес» сайтыннан электрон китаплар укый ала», – диде «Казан шәһәренең Үзәкләштерелгән китапханә системасы» директоры Резедә Исмәгыйлева.

«Әгәр кайсыдыр китап бездә булмаса, заказ бирә алабыз, һәм аны өч көн эчендә китереп бирәчәкләр. Китап уку – бер, балаларга китап авторлары турында күбрәк сөйләргә, иҗат әһелләре белән иҗади очрашулар да үткәрергә кирәк. Шуның өчен балалар һәм ата-аналар өчен әдәби-музыкаль кичәләр, очрашулар булыр дип уйлыйм», – дип аңлатты ул.

«Гаилә» китапханәсе хезмәткәрләре гаиләләрне китап укуга җәлеп итүне төп концепция итеп билгеләгән. «Теләгән һәркем монда килеп йөри ала. Якын-тирә йортларда яшәүчеләр инде кызыксына башлады. Балалар, яшьләрне җәлеп итә алырбыз дип өметләнәм. Китапханәдә барлык шартлар да бар: балаларны биләү урыны, шахмат бүлмәләре, әйберләрне куяр өчен ачкычка бикләнә торган тартмалар һ.б», – диде Р.Исмәгыйлева.

Китапханәдә журналист һәм блогерларга төрле шәхесләр белән әңгәмәләр кору өчен резиденция булдырылган. «Монда әкиятләр, аудиокитаплар, подкастлар яздырыр өчен җиһазлар бар, кирәк икән, синтезаторда да уйнарга була, нотали китаплар да бар. Иҗат белән шөгыльләнер өчен менә дигән урын», – диде Казан шәһәре мәдәният идарәсе җитәкчесе Азат Абзалов.

«Без кунакларга заманча компьютер технологияләрен «язучы – журналист» әңгәмәсендә файдалану мөмкинлеген гамәлдә тәкъдим иттек. Техник әсбаплар белән махсус җиһазландырылган бүлмәдә пластинкалардан тарихи язмалар тыңлау, видеога төшерү мөмкинлеге дә бар. Wi-fi зонасы эшли, китапханәнең компьютер җайланмаларыннан да файдаланырга мөмкин», – диде тантанада катнашкан шагыйрә Сания Әхмәтҗанова.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Корбан бәйрәме тәртибе

Татарстан мөфтиятенең Казыйлар һәм Голәмәләр шуралары тарафыннан 2023 елда Корбан бәйрәмен һәм гает намазын үткәрү тәртипләре расланды.

Гарәфә көне итеп 27 июнь көне билгеләнде, Корбан гаетенең беренче көне 28 июньгә туры килә (Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне). Бу көнне Татарстан мәчетләрендә җәмәгать белән бәйрәм намазлары үтәчәк.

Татарстанның барлык мәчетләрендә дә Корбан бәйрәме уңаеннан гает намазын кояш чыгып 30 минут узгач уку тәкъдим ителә. (Мисал өчен, 28 июнь көнне кояш Казанда 03.01 сәгатьтә, Актанышта – 02.42 сәгатьтә чыга). Башкала мәчетләрендә Корбан гаете түбәндәге тәртиптә үтәчәк:

- 2.30-03.00 – Коръән укылу;
- 03.00-03.30 – гает вәгазе укылу;
- 03.30 – гает намазын уку;
- 03.40 – гарәп телендә хөтбә, Коръән укып дога кылу.

Гает намазы укылганнан соң махсус билгеләнгән урыннарда корбан чалу башланачак, һәм ул Казан шәһәрендә 30 июнь 20.32 сәгатькә кадәр (кояш баеганчы) дәвам итәчәк. Корбан нисабы күләме 36 мең сумны тәшкил итә.

Җырчы белән әдип Казанда кавышты

Быел опера җырчысы Федор Шаляпинның тууына 150 ел һәм язучы Максим Горькийның тууына 155 ел тулу билгеләп үтелә. Шул уңайдан Казанда мемориаль композиция ачылды. Тантанада Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашты. «Рус теле көне алдыннан без монда, рус мәдәниятенең ике күренекле шәхесенең бердәмлеге символына әйләнгән музей янында җыелдык», – диде Р.Миңнеханов. Ул Горький һәм Шаляпинның үзләрен кардәшләр дип атауларын, аларны сәнгатькә, Ватанга һәм аның талантлы халкына мәхәббәт берләштергәнен билгеләп үтте: «Казан алар өчен рухи үсеш һәм формалашу шәһәре булган. Бүген бу ике талантлы кеше үзләре яраткан һәм аларны яраткан шәһәрләре фонында янә бергә».

Татарстан Рәисе искәрткәнчә, быел яшь башкаручылар һәм музыкантлар өчен Ф.Шаляпин исемендәге республика премиясе булдырылачак.

Мемориаль композиция М.Горький һәм Ф.Шаляпин музее бинасы фасадына урнаштырылган. 1967 елда бирегә куелган яшь М. Горький бюстын скульптор Иван Новоселов ясаган булган. Хәзер монда Федор Шаляпин бюсты, шулай ук скульптор Зөлфия Мөхәммәдҗанованың «XIX һәм XX гасырлар чигендәге Казан күренешләре» панносы куелды.

1 нче биттә – Әстерхан өлкәсендә узган Бөтенроссия авыл Сабан туеннан бер күренеш.
Фото: rais.tatarstan.ru

Чаллы бәбиләре – Думада

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Мәскәүдә эш сәфәре кысаларында Россия Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин белән очрашты, шулай ук Россия парламентының түбән палатасында «Туу тарихы» фотокүргәзмәсен ачуда катнашты, Дәүләт Думасы фракцияләре җитәкчеләре һәм Татарстаннан сайланган депутатлар белән аралашты.

«Туу тарихы» дип аталган күргәзмәдә Татарстан фоторәссамы Диләрә Эстринаның эшләре тәкъдим ителде. Ул Халыкара балаларны яклау көненә багышланган иде. Тематик күргәзмәне оештыру инициативасы белән Дәүләт Думасының Гаилә, хатын-кызлар һәм балалар мәсьәләләре комитеты әгъзалары чыккан. Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова билгеләп үткәнчә, мондый күргәзмәне оештыру идеясе узган ел туган, ул вакытта республикада традицион рәвештә үткәрелә торган илкүләм проектларны гамәлгә ашыру буенча фотосурәтләр конкурсына Чаллыдан уникаль фотосурәтләр килгән. «Без шунда ук 150 фотодан торган мондый архивның альбомнарда яки әстәлдә генә саклана алмавын аңладык, – дип сөйләде депутат. – Балалар саны елдан-ел кими барган, бала табу сирәгәя барган бүгенге көннәрдә мондый күргәзмәләр аеруча мөһим».

«Демографик вәзгыять, туучыларның кимүе, гаилә институтын саклау һәм ныгыту – бүгенге көндә төбәкләрне борчыган мәсьәләләр, – дип билгеләп үтте Татарстан парламенты башлыгы. – Гаилә һәм балалар – безнең фундаменталь кыйммәтләр, ә балалар, үз чиратында, еш кына гаиләне ныгытучы төп көч булып тора». Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, күпмилләтле Россиянең һәр халкының гореф-гадәтләре һәм мәдәнияте нәкъ менә гаиләдә саклана һәм тапшырыла. Бала дөньяга килү мизгеленең тиңсезлеген раслаган «Туу тарихы» фотопроекты Татарстанда 2018 елдан гамәлгә ашырыла. Туган мәле фотога төшерелгән беренче балага быел 5 яшь тула.

Күргәзмәдә тәкъдим ителгән барлык эшләр Чаллы шәһәренең Кама балалар медицина үзәгендә төшерелгән. Аларның авторы Диләрә Эстрина – үзе дә ике бала әнисе.

Күргәзмәне ачуда Дәүләт Думасындагы фракцияләр җитәкчеләре, профильле комитетлар рәисләре, Татарстаннан сайланган Дәүләт Думасы депутатлары, федераль министрлыклар һәм ведомстволар, иҗтимагый оешмалар һәм коммерциягә булмаган сектор вәкилләре катнашты. Фотокүргәзмәне ачу тантанасында Россиянең танылган телевидение алып баручысы, профессор, җәмәгать эшлеклесе Елена Малышева махсус кунак булды.

Тарихның байлыгын күрсәтергә кирәк

Самара татарлары, Казанның Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре белән очрашып, Алтын Урда тарихы һәм халыкның милли үзаңын күтәрү турында фикер алышты.

Очрашу Самараның Җәмигъ мәчетендә узды. «Без бүген монда Самара татарлары тарихының бүгенге хәле һәм тарихны өйрәнү юнәлешендә Татарстан фәнни оешмалары белән хезмәттәшлекне үстерү турында сөйләшергә җыелдык», – дип аңлатты очрашу максатын каланың татар төбәкчеләре җәмгыяте җитәкчесе Шамил Галимов.

Самара өлкәсе мөфтие Талип хәзрәт Яруллин тарихын белмәгән халыкның киләчәге булмавына басым ясады. «Күп вакыт татарларны монда килмешәк халык дип таныйлар. Әгәр без борынгыдан монда яшәвебезне дәлилләп торсак, киләчәгебез хәерле булыр.Былтыр тарихчыларыбыз Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы уңаеннан Самарада һәйкәл куйды. Аның «кайтавазы» хәзер дә яңгырап тора әле. Тарихыбыз белән горурланып яшәргә язсын иде», – диде Талип хәзрәт Яруллин.

Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Алтын Урда һәм татар ханлыкларын өйрәнү үзәге җитәкчесе Илнур Миргалиев җирле татар төбәкчеләре белән хезмәттәшлек итүен искә алды. Аның сүзләренчә, 1391 елда Самара янында, ягъни Кондырча елгасы буенда, урта гасырлар тарихында иң зур сугышларның берсе – Туктамыш хан белән Аксак Тимер бәрелеше була. Бу сугыш Алтын Урданың җимерелүенә этәргеч ясый. «Татар тарихын бозып күрсәтергә теләүчеләр күп. Моны Самара өлкәсе төбәкчеләре аеруча авыр кабул итә. Алтын Урданы җимергән Аксак Тимергә һәйкәл куюга беренчеләрдән булып Самара татарлары каршы чыкты, аны Гитлерга тиңләде. Нәтиҗәдә, һәйкәл куелмады. Моның өчен мин Самара татарларына рәхмәт әйтәм», – диде И.Миргалиев. Галим Алтын Урда чорын өйрәнү һәм бу җирлектә 7 гасыр элек туган шагыйрь Сәйф Сараи шәхесен күтәрү аша Самара татарларының бай тарихын күрсәтеп булуын әйтте.

Институтның өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре докторы Искәндәр Измайлов татар милләтенең килеп чыгышы теорияләре турында сөйләде, урта гасырлар татар тарихы белән таныштырды.

Очрашуда катнашкан төбәкчеләр халыкның тарих белән кызыксынуы артуын әйтте. Алар халыкчан язылган, җиңел аңлаешлы тарих китапларына, инфографикаларга, кыска видеороликларга ихтыяҗ зур булуын җиткерде. Төбәк тарихы белән мавыгучылар фикеренчә, заманча форматта эшләнгән тарихи мәгълүмат социаль челтәрләрдә яхшы тарала һәм күп карала.

Рифат КАЮМОВ.
Автор фотосы.

Шагыйрь дә, нашир дә иде

Танылган әдәбият тәнкыйтьчесе, шагыйрь, нашир, педагог, җәмәгать эшлеклесе, Муса Җәлил һәм Гавриил Державин исемендәге республика премияләре лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мөдәррис Вәлиевнең 70 еллыгы уңаеннан каләм әһелләре, киң җәмәгатьчелек вәкилләре, туганнары Казанның Киндерле зиратында әдипне искә алды, аның рухына дога кылды һәм каберенә чәчәкләр салды.

«Мәрасимдә чыгыш ясаучылар Мөдәррис Вәлиевнең күп үрләрне егетләрчә яулаган киңкырлы шәхес булуы хакында бер горурлык хисе белән сөйләделәр», – диде Муса Җәлил премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рәмис Аймәт.

Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин әйтүенчә, әдәби тәнкыйть өлкәсендә танылып, мөхтәрәм аксакаллар тарафыннан югары бәя алса да, Мөдәррис Вәлиев татар әдәбияты галәменә шагыйрь буларак аваз сала. «Аның тәүге шигырьләре 16 яшендә үк минем кереш сүзем белән «Татарстан яшьләре» газетасында дөнья күрде. Мөдәррис Вәлиев әле бүгенгә кадәр тиешле бәясен алмаган шагыйрь. Ул бүген дә заманча яңгырый торган элитар шагыйрь», – диде ул.

«Чыгыш ясаучылар, Мөдәррис Вәлиевнең «Мәгариф» китап нәшриятын оештырып, мәктәпләрне һәм башка уку йортларын яхшы сыйфатлы дәреслекләр белән тәэмин итүдәге эшчәнлеге – үзе бер аерым бәяләнергә тиешле зур сәхифә, дип белдерде», – диде Рәмис Аймәт.

Әдәбият галиме, КФУ профессоры Фоат Галимуллин татарларда китап культурасының моңарчы да тотрыклы булуын, Мөдәррис Вәлиевнең шушы культураны югары сәнгать дәрәҗәсенә күтәрә алуын билгеләп үтте.

КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов үз чыгышында М.Вәлиевнең «Нәшрият эше һәм редактор хезмәте» дигән белгечлек буенча студентларга махсус курс укып, шәкертләр тәрбияләве хакында искә алды.

Искә алу мәрасимендә шулай ук Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин, «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы генераль директоры Әнәс Әскәров, шагыйрьләр Зиннур Мансуров, Җәүдәт Сөләйман, Рәмис Аймәт тә хатирәләрен уртаклашты. Чараны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла алып барды.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Кырын эш кырык елдан соң да беленә. Башкортстанның Балтач районында җанисәп алдыннан ачылган «Мишәр үзәге»нә бәйле ялган 2 елдан соң ук ачылды. «Чын мишәр экспонатлары» дип тупланган әйберләр татар агаеныкы булып чыкты! Балтач кешесе Хәниф Әхтәмов татарны «болгату» өчен кулланылган үз әйберләрен кире үзенә кайтару артыннан йөри.

● Башкортстанның Халыклар дуслыгы йорты сайтыннан. Уртада – мишәр үзәген ачуда башлап йөргән Айдар Сираев.

«Мишәр» сандыгы – татарныкы!

Җанисәп алдыннан Башкортстанда «Мишәр үзәге» ачылды. Балтач районы үзәгендәге Халыклар дуслыгы йорты карамагындагы бу йортны ачуда мәдәният министры Әминә Шәфыйкова катнашты, Башкортстандагы татарларны «төньяк-көнбатыш башкортлары» итеп санау турында хыялланган Салават Хәмидуллин якты юллар теләде.

Гомумән, бик гаҗәп иде ул мишәр йорты – аның татарны бүлгәләү өчен генә уйлап табылган ясалма, уйдырма гамәл икәне күренеп тора иде. Мишәр йортының директоры Айдар Сираев үзе дә мишәр булып чыкмады, әмма ничек булса да мишәрне татардан аеру өчен үзгәлек кирәк булуын сөйләде. Уйлый торгач, иске киемнәрдәге һәм гадәти сандыклардагы уртак элемент – ромб бизәкләрне «мишәр бизәкләре» дип атарга кирәк, дигән фикергә килгән. Шуннан соң яңа милләт булдыру – дөресрәге татардан бер өлешен аерып чыгаруга керешкән.

Гадәти татар халык әкиятләре дә «мишәр әкиятләренә» әйләнгән иде анда. Моның берзаман уен гына түгеллеге ачыкланды – ромбларны нигез итеп алып, «мишәр халык киемнәре» дә тектерә башлаганнар. Башкортстанның Халыклар дуслыгы йорты сайтында «ромбиклы киемнәрдән» чыгыш ясаган фольклор төркеменең фотолары бар.

Ромбикларга кагылышлы хәлләрнең дәвамы барлыкка килде. «Интертат»ка Балтач районы Көндәшле авылыннан Әхтәмов Хәниф Әгъләм улы мөрәҗәгать итте. Икеләтә ялган! Мишәрнең бизәкләре дип атау өчен нигез итеп алынган сандык татар агаеныкы булып чыкты.

– Без авыл уртасында сквер төзергә үзебезнең йорт урыныбызны бирдек, – дип сөйләде Хәниф абый. – Авылда музей ачабыз дигәч, үзебезнең эти-әниләрдән, әби-бабайлардан калган бөтен җиһазларны: сандык, гөбе, кашна – барчасын да Көндәшледә музейга дип калдырдык. Алар, бездән сорамыйча, шуларны илткәннәр дә биргәннәр Балтачка – «Мишәр үзәге»нә. Аны Айдар Сираев дигән бер кеше оештырды. Аннары үзе үк «исбатлый» бит әле: «Менә бу – мишәр сандыгы. Күрәсезме, орнаментлары мишәрнеке», – дип, ромбларны күрсәтә. Андый орнаментлар кайда гына юк! Кайда татар яши, шунда бар алар. Ромб – мишәрнеке, тастымал – мишәрнеке, кашна мишәрнеке – бөтенесе мишәрнеке дип йөриләр! Мин үзебезнең нәселдән килгән әйберләребезне шул музейга биреп, безнең әйберләребезне кулланып, «монда Мишәр үзәге» дип йөргәннәренә риза түгелмен.

– Сез шуңа гарьләндегезме?

– Гарьләнмичә, минем энеләрем, туганнарым бар бит, Үзбәкстандагы, Омскидагы туганнарым шуны күргәннәр. «Абый, нишләп безнең сандык ул музейда, нишләп анда безнең әйберләр? Кире кайтарырга кирәк!» – диләр. Алтын бәясе тора ул безнең гаиләнең әйберләре.

Алла бирсә, кайтып, үзебезнең нәсел әйберләрен кире кайтарып алырга исәбем бар. Озакламый башкортка әйләндерәләр, алар башкортныкы, дип.

– Хәзер ул әйберләр татарга каршы хезмәт итә булып чыгамыни?

– Ул татарга каршы хезмәт итә, татар сүзен әйтү юк анда. Анда Айгөл дигән Көндәшле кызы якын да китерми «татар» сүзен. Гомумән, татарлар булмаган, дип шәрран яра. Башкортча язылган койрыклы, өтерле, әллә нинди шигырьләрне җибәрәләр – менә кая бара алар дөньясы.

– Сез «мишәрләр – аерым халык» дигәнгә ничек карыйсыз?

– Мишәр бернинди аерым халык булмаган, гомер-гомергә без «татар» дип аталдык. Туу турындагы таныклыкта да «татар», әби-бабайлар да «татар» дип йөрде. Пенза мишәрләре дип аталганнарның да үзләрен «мишәр» дип йөртмәгәннәрен тора-бара белдек. «Татар» дип йөрткәннәр. Татар булып йөрдек, паспортта да татар. «Мишәр» дигән сүзне белми дә идек…

Хәниф Әхтәмов әйтүенчә, халыкның «мишәр» дип аталырга риза булуы – басым нәтиҗәсе. «Бер елны халык санын алырга килгәч, без «башкорт» булып язылмыйбыз, «мишәр» булып язылабыз, диделәр, аптырагач инде», – ди ул.

– Мәктәптә дә көчләп башкорт телен кертә башлагач, рус теленә күчтеләр. Хәзер Көндәшле мәктәбендә күрше Курач авылы укытучылары – урыс халкыннан булган укытучылар укыта. Бетте мәктәптә үзебезнең ана телебездә укыту-тәрбия бирү...

– Сез «мишәр» дип йөрүләрне каян чыккан дип уйлыйсыз?

– Каты «ч» белән сөйләшү бар бит инде. Айдар инде аны «бренд» дип уйлап чыгарды. Имеш, «Чокалының чокырыннан чыккан чакта чи чияләр» – безнең мишәр сөйләшүе икән. Имеш, балан бәлеше безнең мишәрнеке икән. Баланны мари да, чуаш та, урыс та – барысы да пешерә. Балан бит инде ул.

Богдан, Тимкә, Чокалы, Уразай, Көндәшле – 7 авыл бер рәвешле сөйләшәбез.

– Мишәр үзәген оештыручылар үзләре кемнәр соң? Мишәрләрме, татарлармы?

– Хәзерге алып баручысы – хатын-кыз, Көндәшле авылыннан чыккан Айгөл. Ул агитацияне гел башкача алып бара: без татарлар түгел, ди. Үзе Көндәшле кызы! Әйттем мин аңа, телефон аша да яздым, аннары ул мине «дуслар»дан чыгарып атты.

– Нәрсә дип язган идегез?

– Белмисез сез тарихны, мин беләм, ди. Аңа Уфа «галимнәре» Уфадан күп итеп китаплар кайтарган. Шуларны укый да укый. Шуннан соң... Эш урыны бар, кемгәдер хезмәт итәргә кирәк бит.

Сираев егетләр белән ирланд биюләре оештырып йөрде инде. Ул бер эштән икенче эшкә йөри торган кеше. Улын урысча җырлата. Мин әйтәм – татарча шигырьләр өйрәт улыңа, татарча белер! «Белер, белер», – ди, үзе гел урысчага каера. Әңгам абый Атнабаевны да белми! Сорап яздым: «Беләсеңме?» – «Кем ул?» – ди. Менә бу – Айдар Сираев! Ул татар әдәбиятын да белми. Мин бераз йомшартып яза башлагач, рәхмәт, диде.

– Ни өчен татарлар шулай «мин – башкорт», «мин – мишәр» дип йөри икән?

— Безнең авылларда вузга керү өчен «башкорт» дип язылучылар бар. Кайткач, кайбер авыл кешеләре белән сөйләшәм. «Без бит Башкириядә яшибез, башкорт булырга тиешбез», – диләр. Нindidер аңгыралык бар. Мин әйтәм, Чуашиядә татарлар яши бит, берсе дә «чуаш» диеп язылмый! – дим. Теге җавап кайтара: «Башкорт булып язылгач, эшкә урнашу да җиңелрәк». Әнә шулай китә инде...

Үземнең мисалда гына әйтәм: 8 классны тәмамлагач, индустриаль техникумга укырга керергә Салаватка бардык. Документларны хатын-кыз кабул итте. «Менә моны күчереп яз әле», – ди. Автобиография булган икән ул. Ул әйтмәде төзәтеп язарга – анда «татарин» дигәнне «башкир» дип язасы калган икән. Диктант яздык, диктантны мин бик матур, шәп язам. «2» куйдылар. Соңыннан аңладым – автобиографиямне «башкорт» дип төзәткән булсам, үтеп кенә китә идем. Менә шундый хәлләр иде 60 нчы елларда.

– Соңгы җанисәптә басым булмадымы?

– Мин сөйләштем – авылларда барыбыз да «татар» дип язылдык, диләр. Берничәсе мишәр булып язылган инде.

Айдар Сираев килгәч, Көндәшле авылын җыйган, безнең укытучы хромкасын алып килгән. «Менә мишәр җырлары», – дип, үзләрен шулай мишәр итеп күрсәткәннәр.

Рәмис ЛАТЫЙПОВ.
intertat.tatar.

● **Мишәр халкына «милли кием» бүләк итүгә нигез булган сандык.** Рәмис Латыйпов фотосы, 2021 ел.

● **Башкортстанның «Мишәр үзәге»ндә 2021 елда төшерелгән фото. Татар уеннары, ашлары һәм әкиятләре мишәрнеке дип аталган.** Рәмис Латыйпов фотосы.

Бигиевне куып чыгару...

Классик әдәбиятыбыз үрнәкләрен кулыма еш алам. Олуг әдипләребез әсәрләренең бер хасияте бар: алар, күп дистә еллар элек иҗат ителгән булса да, ни хикмәттер, бүгенгегә авазлаш була, ягъни синең дә заман рухына тирәнрәк төшенүеңне тәэмин итә, фикерләвеңне җанландырып җибәрә. Шушы арада Кави Нәҗминең сиксәненче еллар башында басылган «Әсәрләр»енең дүрттомлыгын күздән кичердем. Аның мирасы никадәр бай һәм төрле булуына тагын бер тапкыр инандым.

Әйтик, дүртенче томда «Бер юнәлештә баручы отрядлар» дигән мәкалә урын алган. 1929 елның августында татар язучыларыннан зур төркем Казан-Әстерхан-Махачкала-Баку-Ялта-Симферополь-Харьков-Мәскәү-Казан маршруты буенча сәяхәт итеп кайта. Араларында музыкантлардан бердәнбер кеше Салих Сәйдәшев тә була. Бу сәяхәт турында анда катнашкан Г.Кутуй, Һ.Такташ, Г.Иделле һ.б.ның истәлекләре бар. К.Нәҗми дә кайнар эздән шул хакта каләм тибрәтеп алган икән. Әлеге истәлегеннән мәгълүм булганча, ил гизүчеләр Мәскәүдә, М.Горький белән булган әңгәмәдән соң, элеккеге Әсәдуллаев мәктәбе бинасында башкалада яшәүче «татар хезмәт ияләре» алдында да хисап бирү чарасы уздыра. Шунда К.Нәҗми: «Нинди җилләр белән дер, Муса Биги(ев) килеп чыкты. Бәлкем, ул безнең экскурсиядән берәр ипле сүз ишетү турында хыялланган дыр. Ялгышты «мескен»! Татар эшчеләре белән без бертавыштан аны куып чыгардык», – ди.

М.Бигиевнең – үз татарлары янына сагынып килгән олуг зыялының тамаша залыннан чыгарылуын күз алдына китерәсең дә, җан өшеп китә. Шуннан сөрелгәндә ул ниләр кичерде икән, дип, тирән уйга бирелəсең.

Бүгенгедән торып фараз кылам: ихлас күңелдән совет чоры әдәбиятын тудырабыз дип ышанып сәяхәт иткән бу каләм ияләребез шушы зур сәфәрдән күңелләренә ниләр алды икән? К.Нәҗми, мәсәлән, шәхсән үзе ясаган нәтиҗәләрне болай аңлата: «Без, ирекле-ирексез бер-беренә каршы ике дәвернең тәзелешен чагыштырып, борынгылыкны сагынуның никадәр җирәнгеч һәм түбән тойгы булуын, киләчәкнең никадәр көләч һәм якты булачагын сиздек» (76 б.). Ихтимал алар залга җыелган тыңлаучылар белән дә (эшчеләр мондый сөйләшүләргә килделәрме икән, җыелсалар, шул ук зыялылар булгандыр) шул рухтагы тәэсирләре белән уртаклашкандыр. Менә шунда бер читтә М.Бигиев тә тыңлап утырса, дөнья җимерелер идеме? Ул Казандагы хәзерге әдәбият-сәнгать кешеләренең ни белән гамьләнүләрен яхшырак аңлап кына китәр, сөйләшүдә катнашмас та иде. Хәер, әлеге каләм ияләрен гаепләп әйтүем түгел. 1929 ел кебек динебезгә, гореф-гадәтләребезгә аеруча һөҗүм көчәйгән бер вакытта әдәбиятларның пролетар дуслыгы турында башкаланың үзендә сүз алып барганда, залда дини тәгълимат буенча иң зур белгечләрдән булган М.Бигиев утырса, аларның бөтен сәяхәтләренә тискәре тамга куелырга да мөмкин булгандыр. М.Бигиевне залдан чыгару үзенә күрә совет хакимияте алдында йөз аклыгы булып саналгандыр.

Хәзерге шартларда «булгандыр», «саналгандыр», «тиешледер» дип фаразлавыбыз күктән төшкән мисал түгел, шундый чор чыннан да булган, халкыбызның меңнәрчә асыл ул-кызлары газап кичерүгә дучар ителгән иҗтимагый-сәяси мохит яшәп алган. Аны беркая да яшереп куеп булмый. М.Бигиев – шул интеллигенциянең берсе. Шуңа күрә халкыбыз милли уянуга йөз тоткан хәзерге чорда әлеге затлы шәхесебезгә карата игътибар арту бер дә очраклы түгел.

Дөресен әйткәндә, «Бигиев» фамилиясе моңа кадәр дә халкыбыз өчен чит-ят булмады. Бердән, аның әтисе Ярулла Габделкәрим улы Ростов шәһәренең күренекле дин әһеле – ахун була. Әлбәттә, Пенза якларыннан килеп, яңа урында абруй яулау өчен, булдыклылык һәм тырышлык, белемлелек һәм тагын башка гаярь сыйфатларга ия булу таләп ителгән. Ничек итсә иткән, Ярулла хәзрәт моңа ирешкән. Бу сыйфатларны балаларында да булдырырга омтылган. Икенчедән, Мусаның абыйсы Заһир, нибары утыз ике яшькә кадәр генә яшәвенә карамастан, язучы булып танылa. Егерме яшендә ике роман авторы булар ак бәяләнә. «Тәрҗеман» газетасы 1890 елның 10 август санында басылган «Яңа китаплар» исемле мәкаләсендә алар турында «әдәбияттагы яңа агымның иң күренекле әсәрләреннән саналырга хаклы», дип яза. Аның тагын «Мөртәд», «Катыйлә» исемле романнарны да язып тәмамланган дигән мәгълүмат бар. Күренекле галимебез Мөхәммәт ага Гайнуллин авторның үз кулы белән аларның кульязма хәлендәге нөсхәләрен Бохара әмире Габделәхәткә бүләк иткәнлеге, энесе Мусаның исә аларны «Китаб» исемен йөрткән нәшриятка тапшырганлыгы турында әйтеп калдырды (Гайнуллин М. Татар әдипләре. – Казан: ТКН, 1978. – 28 б.). Шулай ук М.Бигиев абыйсының «Мәвәраэннәһердә сәяхәт» исемле китабын бастырып чыгаруга ирешә. Кызганыч,«Мөртәд», «Катыйлә» романнары дөнья күрми кала. Бу хакта Г.Тукаебызның да үкенеч белдергән сүзләрен күбебез яхшы беләбез.

Заһир Бигиев исеме, тормыш юлы һәм иҗаты М.Гайнуллин тырышлыгы белән совет чорында мәйданга кайтарылды, хәтта мәктәп дәреслекләренә кертелде. Ләкин нәсел-нәсәбе турында сүз барганда, галим әдипнең энесе Муса хакында бәян итә алмады. Әйтик, аның 1945 елда Заһир Бигиевнең 75 еллыгына багышлап язылган мәкаләсендә, аңлашыла ки, бу хакта җәелеп китә алмавы күренде (Гайнуллин М. Заһир Бигиев // Совет әдәбияты. – 1945. - № 9. – 74-83 бб.). Әйтергә кирәк, остазыбыз Мөхәммәт Хәйрулла улы Заһир Бигиевкә карата әзлекле рәвештә игътибарлы булды. XIX йөз әдәбияты буенча язылган бер генә хезмәтендә дә аны читләтеп үтмәде. Әмма, билгеле сәбәпләр аркасында, энесе Мусаны уңай яктан искә алу мөмкин түгел иде.

Ләкин бу М.Гайнуллин М.Бигиев турында хәбәрдар булмаган дигән сүз түгел. Моны тәгаен беләм. 1983 елда аның хәләл җефете, педагогика институтындагы укытучым Җамал апа Вәҗиева миңа әйтте:

– Сине Мөхәммәт абыең чакыра, сөйләшәсе сүзләр бар, ди.



Казан үзәгендәге профессорлар тыкрыгындагы өйләрен табу кыен булмады. Мөхәммәт абыйның чирләбрәк торган вакыты иде. Ләкин икенче катта, талчыбыктан үрелгән креслоларга утырып, шактый дәвамлы сөйләшеп алдык. Дөресе, мин тыңлап кына утырдым диярлек. Шул очрашудан соң, аның сиксән яшенә багышлап, «Социалистик Татарстан» газетасында (1983. 25 сентябрь) «Киң колачлы галим» дигән мәкалә дә бастырдым. Сөйләшү барышында, З.Бигиев турында сүз чыккач, ул язучының Муса исемле бертуганының бик зур эшчәнлек күрсәткән шәхес булуы турында сөйләп алды. Әмма аның үзенә бу хөрмәтлебез турында әлегәчә сүз әйтү мөмкин булмавына үкенеч белдерде.

М.Бигиев дөньяви һәм дини әзерлекле егет булып үсә. Әтиләре Ярулла, үзе хәзрәт булса да, балаларын гадәти тормыш өчен әзерләүгә дә уңай караштa була. Муса Ростовтагы реаль училищеда техник әзерлек ала. Заһирне рус мәктәбендә дә укыта. Бәлки, малайлар, дөньяви юнәлештә яшәп тә, үзләрен ышанычлы хис итәр иде. Тик, әтиләре үлгәч, әниләре Заһирнең укуын мәдрәсәдә генә дәвам иттерүен тели. Муса да Бакчасарай, Казан, Бохара мәдрәсәләрендә белем ала. Бу юл аны Әл-Әзһәр дәрелфөнүненә алып килә, ягъни ислам дөньясындагы иң мәшһүр уку йортларының берсендә зур әзерлек ала. Шулай да аңарда дөньявилык һәм динилек юнәлешләренә омтылу аннан соң да дәвам итә. Биографлары аның Петербург университетының хокук факультетында ирекле тыңлаучы булып йөргәнлеген дә искәртә. Бу аңа 1909 елда Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә ислам хокукы буенча дәресләр алып барганда ярдәм иткәндер.

Бу урында аны күрергә туры килгән әдибебез Атилла Расихның истәлеге кызыклы. Ул «Ишан оныгы» дигән әсәрендә егерменче елларда әнисе белән Троицкидан Казанга килеп китүләре турында яза. Алар бу вакытта Казанда яшәүче Муса Бигиев фатирында да була. Олылар сөйләве буенча, Атилла бу кешенең Петербургта мулла булып торганлыгын да ишеткән икән. Шуңа күрә ул әлеге затны чалма-чапаннан күз алдына китергән. Ләкин күрә: ул бөтенләй андый рәвештә түгел. Әгәр кем икәнен белмәсәң, дини реформалар кертү нияте белән яшәүче дип уйламассың да, урыс зыялысыдыр дип уйларга мөмкин булыр иде, ди.

М.Бигиевнең дөньявилыкка тартылуына XX йөз башында татарларга вакытлы матбугат булдыру мөмкинлеге бирелү дә этәргеч биргәндер. Габдерәшит Ибраһимовның «Өлфәт» («Берлек») газетасы белән якынлыгы шуның мисалы. Бу газета, И.Гаспринскийдан үрнәк алып, мөселманнарны бердәм итү идеясен байрак итеп күтәргән басма. М.Бигиев тә газетаның төп юнәлешенә туры килерлек итеп яза. Әлеге газетаның җәмгысы туксанга якын саны чыккан. Шуларның өчтән берендә М.Бигиевнең үткен мәкаләләре урын алган. Мондый эзлеклелек бары тик иң актив язышучыларда гына була ала. Аның «Мөселманнар союзы»н («Иттифак әл-Мөслимин») төзүдә катнашуы да нәзари әзерлегенең гамәли адымнар ясауга китерүе турында сөйли. 1905 елның августында мөселманнарның беренче оештыру корылтаенда катнашуы да шушы юнәлештә рухи камилләшүенең нәтиҗәсе иде. Шуннан соңгы корылтайларның да ул даими катнашучысы була.

Матбугаттагы чыгышларына җәмәгатьчелекнең кызыксынучан мөнәсәбәте аны тагын да житлеккәнрәк хезмәтләр язуга канатландыра. 1906 елдан аның дини тәгълиматка багышланган китаплары басыла башлый. М.Бигиевнең бу өлкәдәге иң олы хезмәте – изге Коръәнебезнең мәгънәсен татар теленә тәрҗемә итүе. Ул бу эшне 1911 елда тәмамлый. Ләкин әле бу вакытта әлеге төп дини китабыбызны шушы рәвештә төрле телләрдә аңлатуга тискәре караш яши килә. Шуңа күрә М.Бигиевнең бу эше төрле бәхәсләр уята. Шул сәбәпле бу хезмәте халыкка басма китап хәлендә ирешә алмый да кала. Аннан инде Бөтендөнья сугышы башлана, аңа инкыйлаб килеп кушыла. Хакимият тарафыннан дингә мөнәсәбәт тә тамырыннан үзгәрә. Петербургта Җәмигъ мәчете имам-хатыйбы булу, «Әл-Мөнбәр» газетасын чыгару да күп көч һәм вакыт ала. Ләкин ислам тәгълиматын өйрәнү буенча эшчәнлеген читкә куймый. 1923 елда Берлинда «Ислам әлифбасы» китабын бастыруы (моны Россиядә эшләү мөмкин түгел иде) аны инде чын мәгънәсендә совет хакимияте өчен чит кешегә әверелдерә. Аңа эш бирмиләр, төрмәдә дә утыртып чыгаралар.

1929 елның августында Мәскәүдә безнең язучылар янына килүе дә юкка гына булмагандыр, милләтнең хәзерге зыялылары белән нииндидер аңлашу булмасмы дип тә өмет иткәндер. Ләкин бу омтылыш, күргәнебезчә, күңелсез тәмамлана. 1930 елда, ул, гаиләсен хәзергә монда калдырып, Кытайга, аннан Әфганстанга, Һиндстанга китә, Мисырга барып чыга. Берничә тапкыр хаҗда була. 1949 елның 28 октябрендә Каһирәдә җан тәслим итә.

Сүз менә шундый затлы, какшамас рухлы шәхесебез, олуг дин галимебез, фәлсәфәче, мәгърифәтче, җәдитчелек хәрәкәтенең башында торучыларның берсе турында бара. Матбугаттагы бу чыгышыбыз аның рухын шат кылсын иде дигән өметтә калабыз.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН,
КФУ профессоры.

ЯЗНЫ КӨТКӘНДӘ

Каләмемә яз кагылды бүген,
Үзгәрттерде төптән сүзләремне.
Әйтерсең лә, үткәрмәдем кебек
Чирәм күзен ачмас көзләремне.

Төмсә көннәремне кояш нуры
Коендырды бикле ишек аша.
Нинди ләззәт! Нинди көяз тойгы!
Хис-дулкыннар миннән алда таша.

Хыялымда бозлар инде әнә
Чатный-чатный барлый китәр юлын.
Зәңгәр күккә багып, ашъяулыгын,
Көйли назлап яшькелт хәтфә-болын.

ТӨШ

Төшемә кердең дә, уянгач
Төсмерләп уйландым бик озак.
Таныш та кебексең, түгел дә,
Сер-йомгак, бу нинди табышмак?

Имештер, озаттым зур юлга,
Иңсәңдә – биштәрле капчыгың.
Нишләптер (бәлки, төш булганга),
Аяклар тоймады таң чыгын.

«Көтәрмен, әйләнеп кайт!» – диеп,
Иреннәр туктаусыз кабатлый.
Үзем дә кебекмен, түгел дә,
Чынбарлык үткәреп яңаклый...

ТУГАН ҖИР УЛ – БЕРӘҮ!

Сүзебезне уйлап сөйлик әле,
Дога булып бара ич алар.
Яхшылыкка юрыйк барысын да,
Болай да күп ялган-ялалар.

Сүзебезне уйлап сөйлик әле,
Юкны-барны тормыйк болгатып.
Күп сынаулар аша үткән Ватан,
Тезләнмәгән... шуны онытмыйк!

Сүзебезне уйлап сөйлик әле,
Акылыбыз булсын гел аек.
Таң чыгына бармы тиңе булган?!
...Туган җир ул – берәү, башка юк!

* * *

Каен ышыгында торам,
Күл өстен туный яңгыр.
Кем белсен, бәлки, сулыкка
Берәр ачуы бардыр.

Шап та шоп килеп бәрелә,
Тамчылары дәррәүләп.
Читтән генә күзәтәбез,
Каен белән икәүләп.

Күл чайкала, күл тибрәлә,
Түзә инде, нишләсен?
Салкын көзге яңгырларның
Белә ич бер үтәсен.

Бу дөньяда бар да үтә,
Син дә, мин дә – үткенче.
Чыландым яңгыр астында –
Калмасын үкенече...

САК БУЛ, АЛДАНМА!

«Бал тамган телдән
Агу да тама».
Оста уйланган,
Уздырып кара!

Дәвер-иләктән
Иләнгән әйтем.
Халкым, син шулай
Гел хакны әйттең.

Тормыш – дәреслек,
Һәм – алтын сүзең.

Люция ӘБЛИЕВА

Сүзебезне уйлап сөйлик әле, Дога булып бара ич алар...

Ачасың җайлап
Дөм сукыр күзне.

Өслектә түгел,
Тирәндә сере.
Колга, хакимгә
Бердәй тәэсире.

Халкым кисәтә:
Сак бул, алданма!
Бал тамган телдән
Агу да тама.

ШИГЪРИЯТ ДӨНЬЯСЫНДА

Өндәүләрдән торган шигырьләрне
Кабул итәсеңме, замандашым?
Затлы имезлеккә төреп биргәч,
Икенчерәк тәме, беләм, ашның.

Сорау куя торган очракта да,
Кирәкме соң өндәүләргә бикләү?
Бу бит, миңа калса, бармакларны,
Авырттырмый, җайлап кына бөкләү.

Шөһрәт гөмбәзенә күтәрелер
Миссияне үтиме бу билге?
...Күңел көтә иҗат мәйданына,
Сөлге буып чыккан нылы билне.

ТОТАШ ЯКТЫЛЫК!

«Нарат урманында иртә»,
Сихри бер тынлык.
Монда дөнья шау-шуына
Мыскал урын юк.

Беленер-беленмәс кенә
Томан тарала.
Кояшның нурлары үткән,
Нәни акланга.

Рәссам узган давылны да
Оста яшергән.
Яшел хәтфә үләннәрне
Бизәп төшергән.

Аю балалары уйный,
Рәхәткә чигеп.
Табигать үзе аларны
Курчалый кебек.

Таң исе аңкый бар җирдә,
Бөркелә сафлык.
Караңгы урман эчендә
Тоташ яктылык...

ҮТЕНЕЧ

Тәрәзәмә җил шакыды,
Килгән кич утырырга.
Тегеннән-моннан җыелган,
Хәбәрен тутырырга.

Кертергәме-юкмы сине?
Холкың бит иңке-миңке.
Йолкып ташлыйсың кайвакыт
Йөз еллык өянкене.

Кирәгең әле күренми,
Бүгенге кичем – үзгә.
Синең белән шуңа күрә
Керәсем килми сүзгә.

Тыныч кына хатирәләр,
Сүтәргә иде исәп.
Җеп очымны чуалтырсың,
Мондый халәтем сирәк...

Тәгәрәсен җайлап йомгак,
Биеми генә тыпыр.
Сине көтеп торган бардыр,
Әйдә, шул якка сыпыр.

Әгәр дә кирәгең чыкса,
Җил түтәй, алай-болай,
Ишек келәсен төшереп,
Ачып кертермен... шулай.

Күңелгә ятыш булмаган
Истәлекләрне төяп
Бирермен, куяр өченгә
Каф тауларына сөяп.

САК БУЛ!

Шатлык өләшкәндә сак бул, дустым,
Сөенгәнне генә сөендер.
Барысы да кабул итеп бетми,
Эче поша аңа кемнеңдер.

Югыйсә бит тамчы кадәр генә
Өлеше юк аның бу эштә.
Әмма ләкин сине түбәнсетеп,
Әйтер сүзен таба, көрешсә.

Җайлы гына кемгә килгән җиңү?
Аңлый аны бары аулаган.
Була... була... шатлык өләшкәндә,
Агу белән әнә саплаган.

Бөекләргә кизәнүче байтак,
Чыдап кына торсын ак катам!
Чебен кадәр мәгълүматы белән
Филгә үрелгәнгә шаккатам!

Имеш, алар дөрес эшләмәгән,
«Болай итәр идем, мин булсам!
Бәхет диңгезенә чумар иде,
Дөнья йөзендәге һәр инсан!»

Авызымнан, шундый вакытларда
Чыгып оча теге... «япунмать».
...Бөекләрнең тырнак бөртегенә
Тормаганнар суга чаң-набат!

ЫШАНМАСАҢ...

Шигырь калыбына сыеп бетми,
Яши-яши мин дә үзгәрдем.
Сөюемне роман итеп язам,
Иң-иңнәрен сайлап сүзләрнең.

Килеп чыкмый... Төсләр эзлим менә,
Кулларымда уйный пумала.
Мольбертымда әзер сюжет ята...
Юк, минемчә түгел... уала.

Күңел төрләреннән үргып чыккан
Моң бирәлер, бәлки, аңлатып?
...Җиде нота гына җитми икән,
Ышанмасаң... кара яратып.

* * *

Мин сине күзләрдән яшердем,
Алтыннан булса да төсләре.
Җәлләдем буярга асылга
Ямь-яшел, яз тулы хисләрне.

Мин сине күзләргә кертәсем,
Һич килми... Үзең дә беләсең.
Күңелем сизәдер, күрәсең.
Җилләре бәгырьне теләсен.

Мин сине җәйләрдә калдырам,
Әйләнеп ул кире кайтачак.
Җанымда – иркәле карашың:
«Уртак таң берсүзсез атачак!»

ҖӘЛ...

Йолдызлар яңгырын күзәтү
Язмаган... Нишлисең, бик тә җәл.
Хыялда такыя кем үрми?!
Булгалый, әйе шул андый мәл...

Бөркетләр үз иткән кыяга
Чакырдың... И үзең бер сабый!
Кирегә, җирләргә каерып,
Көчләрнең барлыгын уйламый.

Күзләрдән күзеңне алмаган,
Вакытны кайтарам төсмерләп.
Кызганыч, әле дә тоямын,
Тәннәрем киткәнен чемердәп.
Җәл...

ДӨРЕС ЮЛ

Алтын-бриллианттан йөзак салып
Куйсаң да син күңел түренә,
Үпкә, борчу-кайгы ишеләре
Җаен таба анда керергә.

Ачкыч таба нәфрәт, үч тойгысы,
(Әйтерсең юк башка эшләре!)
Әйбәт булыр иде, кимчелекләр
Чистарынып керсә элгәре.

Җиңел генә җиңәр идең дә бит, –
Тамырлары киткән тирәнгә.
Мамонтларны аулап йөргән бабай,
Интеккәндер аннан, бигайбә.

Ә бит дөньялыкта сине урап,
Алган күпме матур-гүзәллек.
Таң атуы – сихри бер манзара,
Баш очында – гаҗәп зәңгәрлек.

Бер-берсеннән яхшы мөнәсәбәт
Кабул итә кеше көн туса.
Урын калмаска да тиеш түгел,
Вак-төяк уйларга, югыйсә.

Котылырга яман-хөсетлектән,
Кемдер әйтер: «Әйдә, эт өстер!»
Ләкин мәсьәләнең чишелешен
Үзебездән эзләү дөрестер.

Марсель БАКИРОВ

«Чура батыр» дастаны

«Чура батыр» дип аталган төрки дастан Казан ханлыгы чоры әдәбиятына карый һәм татар дәүләтенең Явыз Иванга каршы героик көрәшен, аның җиңелү фаҗигасен эпос теле, эпик образлар ярдәмендә бәян итә. Әлеге әсәрнең, ориенталист И. Н. Березин төзеп чыгарган «Турецкая хрестоматия» җыентыгындагы татар текстыннан тыш, казах, нугай, Польша татарлары, шулай ук өлешчә башкортлар арасында язып алынган һәм басмаларда дөнья күргән төрле милли вариантлары билгеле.

«Чура батыр»ның казах варианты («Шора батыр» һәм аның әтисенә багышланган «Нәрек» дастаннары) эпик «Кырык нугай батыры» циклына кертеп карала. «Нугай» төшенчәсе ошбу очракта казахларның да кыпчак-нугай катламына нисбәтле героик үткәненә бәйле рәвештә кулланыла. Эпос белгече В. М. Жирмунский фикеренчә, бу әсәрләр казахлар һәм нугайлар күченеп йөргән, үзара аралашкан Җаек буе һәм дә аннан аргы биләмәләрдә – Көнбатыш Казахстанда иҗат ителгән. Аларда казахларның калмыкларга каршы көрәш мотивы Чура батырның эшчәнлеген-көрәшен билгели торган төп коллизия итеп тасвирланган да.

Фольклорчы-археограф, профессор Ә. Диваев әле генә телгә алынган ике казах эпос-дастанында, шулай ук әсәрнең үзе язып алган архаик вариантында Чура батыр, туган төбәгеннән барып, калмыкларга каршы көрәшеп йөргән Казан каласын, асылда, Идел буендагы без белгән кала түгел, ә Җидесу төбәгендә, Алмалыкта урнашкан һәм элек Казан дип аталган башка кала булган дип исәпли. Казах дастаннарын һәм Ә.Диваев вариантын махсус өйрәнгән академик А.Орлов та аның фикеренә билгеле бер дәрәҗәдә кушыла һәм, калмыкларны куып җибәргәч, Чура батырның Казанга хан булып кайтуы Идел буе реалийлары белән ярашмый дип карый.

Казан татарларының беркайчан да калмыклар белән сугышмавына игътибар иткәндә һәм «Нәрек», «Шора батыр» («Чура батыр») дастаннарында тасвирланган геройларның чыгышлары һәм аерым тарихи реалийларның көньяк регионына туры килүен исәпкә алганда, әлеге галимнәрнең фикере дөрес булып тоела. XV–XVIII йөзләрдә нәкъ менә Урта Азиядә, ягъни Көнчыгыштан хәзерге Казахстан белән чиктәш Жунгариядә хакимлек иткән калмыклар үзләренең тирә-ягындагы биләмәләргә, шул исәптән Җидесу төбәгенә дә кат-кат яу чабып торган.

Нәрек (Нәрик, Нарыкбай) белән Шора (Чура) батыр чыккан «тама» исемле ыру да һәм, икенче вариант буенча, янә аргын кабиләсе дә («асылым артык аргынмын») Урта Идел буенда түгел, ә Көньякта, аерым алганда, Каспий – Арал диңгезләре арасында һәм Җидесу төбәген дә эченә алган Урта Азия регионында күченеп йөргән. «Шора батыр» дастанында әйтелгәнчә, тамалылар Җидесуда урнашкан Казан исемле калада да төпләнгән булган. Сүз уңаенда өстик: Казан дип исемләнгән яисә әлеге сүз кушылып ясалган географик атамалар, шул исәптән торак пунктлар хәзер дә Казахстанның төрле регионнарында очрый.

Калмыкларга каршы көрәшү өчен тама яугирләреннән төзелгән һәм башында Чура батыр торган хәрби дружинаның дастанда Аксак Тимер гаскәренә тиңләнүе, ягъни баскак әмирнең культ объекты рәвешендә телгә алынуы да бары Урта Азия җирлегенә нисбәт итеп аңлатыла ала. Ә Урта Идел төбәгендә Аксак Тимер, белүебезчә, Болгар биләмәләренә басып керүче һәм Алтын Урданы җимерүче итеп карала. В.Жирмунскийның, В.Бартольд белән бер үк фикердә булып, «XVI–XVII йөзләрдә мөселман авторлары «мәҗүси» калмыкларны Урта Азия мөселманнарының иң дәһшәтле дошманнары итеп санаган» дигән сүзләре исә «Нәрек» һәм «Шора батыр» дигән казах дастаннарының төп идеясенә һәм эчтәлегенә тулысынча туры килә. Шуңа күрә казах вариантындагы «Казанны кяфер (кәпер) алыр дип, әтием утырган алтын так (тәхет) яу кулына калыр дип, чыктым юлга мин» дигән юллардагы «кяфер» сүзен, кайберәүләрчә, русларга карата кулланылган дип карауның да зарурилыгы юк. Ник дигәндә, урта гасыр мөселман авторларының башка диндәге халыкны «гәүр», «кяфер» дип атаулары, гомумән, гадәти күренеш булган.

Шунысы гаҗәп: әлеге казах дастаннарындагы төп каһарманнарның исемнәре, хәтта Чураның әти-бабасы исеме, шулай ук ыруг-кабилә атамасы да «Чура батыр» эпосының татар, нугай һәм кырымтатар вариантларындагы исемнәр белән шактый тәңгәл килә. Аерым алганда, һәр ике төркемдә дә Чураның әтисе Нәрык (Нарәң, Нәрең, Нәрик, Нәрек, Нәрыкбай) дип, әнисе – Миңлесылу (Миңле Аруг, Миңсылу, Акминде), батыр дусты – Колынчак (Колыншак), Чураның әти-әнисен рәнҗеткән яки аның үзен үтерергә теләгән дошманы Али би (Гали бәй) дип исемләнә. Каһарманның асылы, ягъни ыру-кабиләсе исеме тама (күкес (көкеш) яки аргын кабиләсенең бер өлеше) дип күрсәтелә, бары Нәрыкның төп йорты, туган җире генә төрле регионнарга бәйләп бирелә. Алда исемләнгән казах вариантларында җир тама кабиләсе яшәгән һәм Казан дигән каланы да эченә алган төбәк итеп, татар вариантында – Дагстан, кырымтатар вариантында – Кырым, нугай һәм Польша татарлары вариантында Урта Идел буена урнашкан Казан дип күрсәтелә. Димәк, сюжет төзелешләрендә һәм конфликтның характерында җирле аерымлыклар булса да, «Чура батыр» эпос-дастанының төрле милли версияләре, – асылда, бер үк уртак чыганактан башлангыч алган һәм үзара «кан алмашкан» дигән сүз. Аерымланып торган өч вариантлы казах версиясе иң борынгы җирлек булганмы, әллә инде үзара якын татар, нугай, кырымтатар һәм Польша татарлары вариантларының берәрсеме – моны ачыклау өчен тарихи һәм чагыштырмалы планда өстәмә тикшеренүләр сорала.

«Алпамыш» дастанының казах варианты борынгырак булган кебек, «Чура батыр» эпосының казах версиясе нигезендә дә борынгырак катламның, шул исәптән әкияти-мифологик мотивларның күбрәк катнашканлыгын аерып күрсәтергә кирәк. Ачыклап әйткәндә, нугай, кырымтатар һәм татар вариантларыннан аермалы буларак, Ә. Диваев вариантында Чура батыр баласызлыктан интеккән Нәрыкбай һәм Гөлханыс гаиләсендә могҗизалы юл белән, ягъни болар, кат-кат гыйбадәт кылып, изге Баба Төкләскә (Төкле Бабага) ялварганнан соң дөньяга килә. Төрле батырлыклар эшләргә каһарманга Чуар дигән гайрәтле җитез аты, куәтле кылычы һәм җәясе ярдәм итә. Дошманнарына каршы көрәшү өчен, үзенә ярдәмгә дип, Казанга тамалар гаскәрен алып килергә барганда, ул хәтта, әкият батыры кебек, аждаһа белән дә көрәшә.

Башка милли вариантларда башлангыч конфликт чибәр хатын өчен барган итеп тасвирланса, әлеге казах вариантында ул урынны Чуар тулпар ала. Дастанның реаль тарихилыкка корылган нигезе, ягъни Чура батырның нәкъ менә үз ыру-кабиләсен җәберләп яшәгән айраклыларга һәм казахларның дошманнары булган баскынчы калмыкларга каршы көрәше әсәрне тарихи-героик эпослар рәтенә куя һәм, һичшиксез, аны Урта Азия регионы белән бәйли. Ә инде сүз барган дастанның архаик мотивларны киңрәк гәүдәләндерүен, кадимирәк булуын күз уңында



тотканда һәм казах җирләренә калмыкларның XV йөздә үк һөҗүм итә башлауларын исәпкә алганда, әлеге казах-кыпчак варианты (асылда, чагыштырмача мөстәкыйль вариант) башка милли версияләр өчен архетип, ягъни иң элгәрге оеткы-өлге ролен үтәмәде микән, дигән урынлы фикер соралып тора. Аерым галимнәрнең архаик характердагы казах вариантларын Җидесу регионындагы элгәрге Казан каласына бәйләп каравы да шундый ук нәтиҗәгә этәрә. Шуның белән бергә казахларда «Чура батыр» дастанының нугай, татар һәм кырымтатар версияләре белән шактый аваздаш булган соңрак чорга караган варианты да бар. Анда инде Чура батыр, әлеге милли версияләрдәге кебек үк, Идел буендагы Казанны рус яуларыннан яклап көрәшә.

Дастанның «Чура батыр хикәяте» дип аталган татар варианты Чура туганга кадәрге хәлләрне сурәтләүдән башланып китә. Аның булачак әтисе – Казый исемле би (бәк) тарафыннан тәрбиягә алып үстерелгән Нарәң батыр – Миңлесылу исемле бик чибәр кызга өйләнә. Аңа Казый бинең энесе гашыйк була һәм ире югында килеп аздырырга тырышуы Нарәң кулыннан үлүгә китерә. Күчеп килгән икенче урында да шул ук хәл кабатлана: Хаҗитархан солтанының, Миңлесылуның чибәрлегенә кызыгып, ирен юри йомыш белән читкә җибәрергә һәм моның хатыны белән якынлык кылырга тырышуы шулай ук аның өчен дә үлем белән тәмамлана. Шушы ук традицион мотивның архаиграк варианты белән без янә дастанның «Шора батыр» дигән казах вариантында очрашабыз. Анда Нәрекнең чибәр хатынына калмыкларның Үгезхан исемле ханы, кызыгып, ирен «18 айлык юлга» җибәрмәкче була. Ошбу текстта да Үгезханның бозыклыгы үлем белән очлана.

Юлда качып китеп барганда, Миңлесылуны тулгак тота башлый, ире, хәерле сәгатькә багышлап, намаз һәм дога укыганнан соң, шулай ук Чура исемле колын азат иткәч, боларның ир балалары туа. Иреккә чыккан кол Чура хөрмәтенә моңа, әсәрдә әйтелгәнчә, Чура дип исем кушалар, ләкин «чура» сүзенең мәгънәсе «кол» төшенчәсен

белдерү белән генә чикләнми, санскрит телендәге кебек үк, төрки халыкларда аның батыр, каһарман, батыр сугышчы дигән мәгънәләре дә бар. Төрки халыкларның үз эпос батырларын Чура дип атаулары шуның белән аңлатыла да.

Бала тугач, Нарәңнең гаиләсе Кырымга барып төпләнә. Шушыннан соң инде Чура дастанда беренче планга чыга һәм төп образ була. Башта аның, «Идегәй» әсәрендәге кебек, батыр балачагы тасвирлана: бозау көткәндә, зирәклеге һәм кыюлыгы-тәвәккәллеге белән иптәшләреннән өстен чыгып, ул аларның башлыгы булуга ирешә. Аннары, көтү кайтканда, һәр көн тегеләрне ат урынына үгез-бозауларга атландыртып һәм чыбыкка бәйләгән яулыкларны байрак итеп болгый-болгый кайтырга өйрәтә һәм: «Без Чура батырның гаскәребез!» – дип, яр-оран салырга боера. «Сугыш уены» көтелмәгән нәтиҗә бирә: «Чура батырның хәтәр гаскәре бар икән» дигән хәбәр бөтен тирә-юньгә тарала. Әлеге имеш-мимешләр хәтта Идел буенда яшәүче җирле халыкның, яу килүдән куркып, елганың икенче ягына күченә башлавына сәбәп була.

Бу хәл Кырымда яшәүче Чураның үзенә килеп ишетелә, һәм ул, атасы Нарәң батыр биргән гайрәтле атка атланып, биленә җәя һәм садак тагып, Идел буена юлга чыга. Елганың икенче ягына күченүчеләр арасында ул яр буенда аһ-ваһ килеп йөрүче бер картка тап була. Суда үгезе туарылып, арбасы-йөге белән бергә моның кызы агып китеп бара икән. Чура, тиз генә кереп, кызны коткара да юлын дәвам итә. Шунда аның артыннан, үзе югында кәләшен коткарган өчен рәхмәт әйтергә, танышырга дип, бер егет куып җитә. Ул әлеге кызның кияве һәм Чураның булачак көрәштәш дусты Колынчак батыр булып чыга. Кырым батырын картның өенә алып кайтып кунак итәләр. Төн кунганда ике батыр арасында булган сөйләшү һәм «киләчәктә кыз кемгә тиеш?» дип шарт-сүз куешу Чураның җиңүе белән тәмамлана. Ике яшь йөрәк уртак тел таба һәм ахырда, карт өендә зур туй ясап, Чураны өйләндерәләр. Колынчакка исә каһарман үзенең кыз кардәше Айсылуны кодалый. Тар даирәдә һәм шәхси кысада булган бу вакыйгалар Чураның киләчәктә күрсәтәчәк батырлыкларына үзенчәлекле кереш рәвешендә кабул ителә.

Хатынын алып, Кырымга кайтуына, Чураны һәлакәтле-фаҗигале хәл каршы ала. Ул монда юк чагында, Акташ дигән җирдән килгән Гали бәк боларның йорт-җирен талап, ата-анасын кыйнап һәм җәберләп, төрлечә мыскыл итеп киткән икән. Җитмәсә, киткәндә, этисенең Карагир дигән иң яхшы атын да үзе белән алган. Җавабы һәм әҗере, дастан традициясе таләп иткәнчә, каты һәм кырыс булып чыга: Чура, Гали бәкнең башын кисеп, атны кире өенә алып кайта. Сүз уңаенда әйтик: үзе янә Казанга киткәч, Гали бәкнең туганнары килеп, кабат моның эти-әнисен талап, бөлдереп китә. Бу хәл соңыннан Нарәң батырның, улын эзләп, Идел буена барып чыгуына сәбәп була.

Казанда Чура батыр, үз янына «Колынчак батырны чакыртып алдырып, шулай ук андагы батырлар белән кушылып», бертуктаусыз ябырылып торган рус яуларыннан шәһәрне саклый башлый. Шушыннан соң каһарманның Казанга бәйләнешле героик тормышын һәм батырлыгын күрсәтү әсәрдә үзәк урынны ала. Бу уңайдан дастанда игътибарны аеруча нык җәлеп иткәне шул: шәһәрне саклаганда, Чура батыр Шагали (Шаһгали) хан белән тыгыз бәйләнештә торган итеп, хан исә каһарманга һ.б. батырларга төрлечә ярдәм итеп торучы һәм изге эшләренә теләктәшлек итүче хөкемдар итеп сурәтләнә. Бу, әлбәттә, тарихи дөреслеккә туры килми. Белүебезчә, Шаһгали – Мәскәү тарафыннан Казан тәхетенә өч мәртәбә куелган марионетка-курчак хан. Ул колониаль сәясәт алып баручы русларга беркайчан да каршы чыкмаган, ә һәрвакыт аларның «җырын җырлаган» һәм шуның аркасында халыкның нәфрәтенә дучар булган кеше.

Бу урында, һичшиксез, Казан ханлыгы тәхетенең күп еллар буена Чыңгыз нәселеннән чыккан берничә династия вәкилләре һәм аларның тарафдарлары өчен «ызгыш алмасы» булганлыгын һәм әлеге көчләр артында, бигрәк тә соңгы дәверләрдә, йә Кырым, йә Мәскәү торганлыгын аерым рәвештә искәртеп китәргә кирәк. Шушыңа бәйле рәвештә Казанның морза-бәкләре һәм аларның иярченнәре дә капма-каршы ике төркемгә бүленгән булган. Төркемнәрнең беренчесе Мәскәү кулы астында, ягъни рус дәүләтенә буйсынып яшәүне яклаcа, икенчесе Кырымга бәйлелек ягын каерган, әмма шул ук вакытта ханлыкны рус йогынтысыннан азат итү өчен дә көрәш алып барган. Шундый шартларда тәхеткә Мәскәү тарафыннан кат-кат утыртылган Шаһгалинең дастанда уңай образ итеп тасвирлануы, билгеле, аның гамәли-реаль эшчәнлеге белән дә, шулай ук әсәрнең идея юнәлеше белән дә кискен каршылыкка керә.

Шуны да искәртик: кырымтатар вариантында әлеге катлаулы чорда тәхеттә утырган ханның исеме атап әйтелми, ә Польша татарлары вариантында – Сафа, нугай версиясендә исә Гәрәй яки бер вариантта ханбикә Сөембикә дип күрсәтелә. Шаһгалинең татар вариантында «идеаллаштырып» тасвирлануы сәбәбен, безнеңчә, ил язмышын хәл иткән фаҗигале хәлләргә карата чичән-җырауларның һәм, гомумән, халыкның гыйбрәтле-сатирик нәтиҗә чыгаруы, үкенү-тәүбәгә килергә чакыруы формасы итеп кабул итәргә кирәктер. Ачыклап әйткәндә, халык Казанны алуда үз гаскәрләре белән катнашкан сатлык Касыйм ханы Шаһгалине, нәкъ менә юри көлеп, ягъни фольклорга хас пародия алымын кулланып, Казанны яклаучы хан итеп тасвирлый. Моның белән халык, безнеңчә, шул чордан соң килгән буыннарга һәм безгә кинаяле тел белән «Хыянәтчел ялгышлык ясаган бабаларыгыз өчен тәүбә итеп, гыйбрәт алыгыз, безнең ханнар сатылу-хыянәт юлына басмыйча, нәкъ менә шулай халык белән бердәм булып көрәшергә тиеш иде!» дип әйтергә тели. Халык иҗатында сакланган «Шаһгали җыры» дигән җыр да шушы ук фикерне һәм соңлап килгән үкенү тойгысын белдерә. Анда Казан алынып, янә тәхеткә утыру турында хыялланган әлеге хан исеменнән: «Дус-дус дип йөргәнем бар да дошман икәнсез... Бездән калган малларны руслар килеп алалар» дигән гыйбрәтле-үкенечле сүзләр әйтелә.

Шаһгали хан үзе генә түгел, кызы Сарыкани да (кырымтатар вариантларының берсендә кызның исеме – Сары ханым) рус яуларына каршы көрәшүчеләр ягында торучы итеп сурәтләнә. Казанны саклаучы батырларга ул төрле бүләкләр өләшә, ә Чурага тартмага салынган «күкчыбык» дигән кылыч бүләк итә. Каһарман шул коралы һәм атлы гаскәре белән кат-кат ябырылып, шәһәрне алырга ашкынып торган рус яуларын кыра.

Дошман як Чура батырның һөҗүмнәреннән тәмам гаҗиз була, мөшкел-авыр хәлдә кала. Аптырагач, руслар, батырны ничек үтереп булыр икән дип, күк җисемнәре буенча күрәзәлек итүче астрологларга мөрәҗәгать итәләр. Болар «Чура батырга дошманнан бер кыз бирсәң, шул кыздан бер угыл булса, Чура батырның әҗәле шул угланнан булыр» дигән нәтиҗәгә килә. Белүебезчә, «ата белән баланың үзара сугышы» сюжеты, хәтта каһарманның үз улын яки үз этисен үтерүе мотивы дөнья фольклорында һәм әдәбиятында күптәннән инде билгеле. Җөмләдән, б.э.к. V йөздә үк яшәгән борынгы грек драматургы Софоклның «Эдип патша» дигән трагедиясендә чит патшалыкта үскән Эдип, кем икәнен дә белмичә, үзенең этисен үтерә. Фирдәүсинең «Шаһнамә» эпосында, әрмәннәрнең «Давид Сасанский» дигән эпик поэмасында һәм русларның «Илья Муромец и сын» былинасында да без бер якның үлеме белән беткән шундый ук тип фаҗига белән очрашабыз.

Вакыйгаларның ары таба үсешеннән күренгәнчә, руслар астрологлар әйткәнчә эшли. Үзе янына махсус рәвештә озата килүче арчилар белән җибәрелгән марҗа кызын Чура батыр хуш күреп кабул итә һәм аның белән яши башлый. Әмма кыз, балага узу белән үк, үзен Казанга җибәрүчеләрнең сүзен тотып, кире үз ягына качып кайта. Аннары инде Чурадан туган бала, ягъни этисенең язмышын хәл итәчәк угыл руслар арасында тәрбияләнеп үсә. Дастанның кырым-татар версиясендә Чура – исеме әйтелмәгән Казан ханының Сары ханым исемле кызына өйләнгән итеп күрсәтелә һәм баланы да шул таба, ләкин ошбу кыз көтмәгәндә генә дошман ягына чыгып китә, димәк, бу очракта да Чураның улы руслар арасында тәрбия ала.

Шактый вакытлар узгач, Чура батыр сугыш мәйданында йөзгә-йөз үзенең үсеп җиткән улы белән очраша. Казан–Мәскәү арасындагы конфликт һәм бәрелешләрнең шактый еллар буена дәвам иткәнлеген исәпкә алганда, эпик вакытның кысып та тасвирлана алуын истә тотканда, моңа, әлбәттә, гаҗәпләнергә кирәкми. Марҗадан туган бала рус явы составында татарларга каршы сугышырга, Казанны алышырга килгән булып чыга. Ата белән ул бер-берсенең кем икәнен белмичә, сугыш мәйданында бик озак алыша, көч ягыннан да, осталык буенча да бер-берсенә бирешми. Ике арадагы каты орыш бигрәк тә кырымтатар вариантында шактый тәфсилләп тасвирлана. Моңа кадәр бер-ике селтәнүдә әллә никадәр дошман яугирләрен түшәп салган яу батырының, күпме генә тырышып караса да, улын үтерергә көче җитми. Ахырда моның аты, тәмам кызып, тыя алмаслык хәлгә килеп, өстендәге батыр җайдагы белән бергә Идел ярыннан егылып төшә. Суга батып үлгәндә, Чураның ачынып әйткән соңгы сүзләре мондый:

Индегедән арбаган
бездәй ирләргә
Казан атлы
сар да (шәһәр дә) юк.

Әсәр дөнья күргән басмаларда «арбаган» сүзенең мәгънәсе «бәхет, уңыш» дип күрсәтелгән. Безнеңчә, бу сүз йә «сихерләнгән, алданган» мәгънәсендә килгән «арбаг» тамырыннан алынган, йә булмаса, – монысы дөресрәктер дә, бәлки, – ул башта, гарәп шрифты белән язылган текстта, «һәлак булу» мәгънәсен белдергән «арда» рәвешендә булган. Димәк, Чура батыр, асылда, «моннан соң инде һәлак булган безнең кебек ирләргә Казан дигән шәһәрдә гомер итү насыйб булмаячак» дип, бәхилләшү сүзләрен әйтә. Бу сүзләрнең төбендә шулай ук «шәһәрне саклаучы ирләр кырылып бетеп, Казан руслар кулында калачак» дигән мәгънә дә ярылып ята. Мондый мәгънәне, әлбәттә, каланың фаҗигале язмышы шаһиты яки замандашы булган чичән-җыраулар салган. Һәм дастанның ахырында шулар ук исеменнән, әлеге мәгънәне раслап, «Соңра рус гаскәре, галиб (җиңүче) булып, Казан шәһәрен алды. Рус падишасына табигъ булдылар (буйсындылар). Бу Казан шәһәрен алганнан берничә ел соңра Хаҗитархан (Әстерхан) шәһәрен янә алды» дигән үтә гыйбрәтле бетем-эпилог та өстәлгән.

Аерып әйтергә кирәк: дастанның нугай һәм кырымтатар вариантларында Чураның әҗәле, туганда ук, судан булачак, дип юралса да, асылда, бу үлемнең үз улы аркасында икәнлеге бәхәссез. Мифологиядә һәм әкияти-мифологик эпоста аеруча куәтле дошманны шул затның үз коралы белән генә үтереп була дигән мотив бар. Дастанда да шушы ук мотивның үзенчәлекле төстә файдаланганлыгы сизелеп тора. Үзенчәлекле төстә дигәндә, без Чура каның марҗа каны белән катышуын күздә тотабыз. Нәкъ шушы хәл халыкның «Батыр үлеме марҗадан» дигән мәкаленә туры килә торган фаҗигага туура сәбәп була.

(Дәвамы киләсе санда).

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ

МОСТАФА

(Дәвамы. Башы 20, 21 нче саннарда).

«Улың нык синең, молодец! Йөрәгең куркусыз икән. Кайберәүләр шушы... беренче сызык аша атлаганда камырга әйләнәләр. Мондый корыч куллар һәм корыч йөрәк совет властена һәрчак кирәк булачак. Җиңүләребез ныгыган саен, аның дошманнары ишәя торачак. Ә без партиянең курку белмәс батыр солдатлары!»

Аракы тәмсез, җылы һәм гадәттән тыш әче иде, бугазны ертып-тырнап үтте дә ачтан чурлаган ашказанын көйдереп алды. Шулай булса да икенче чәркәне Мостафа үзе сорап алып эчте, сындырып капкан ипи катысын авыз эчендә әүкәләде. Күмәкләп тагын берне өстәделәр.

Шуннан соң гына аның күңел болгануы туктады, уйлары бер урынга сыешып анык юнәлеш алды. Уйлары үзенеке түгел иде Мостафаның, теге бичараның соңгы сүзләре хәтердә яңара да, аны шунда ук командир фикере басып, каплап китә. Мостафа командирына да, иптәшләренә дә аны-моны сиздермәде, бүтәннәргә ияреп көлгәндәй итте, командирының һәр ым-ишарәсен күзәтеп-көтеп торды, кул чапты, үкчәсе белән идәнгә типте. Тора-бара, өченчеме, дүртенчеме шешәне башлаганда, зиһенендә бер сүз генә сөрелеп калды: «Дошманнары арта торачак совет властеның!»

Ялгызы гына кайтып барганда, уйлары уянып тагын бәргәләшә башладылар. «Бала-чагаң дүртәү икән, ни-нәмәрсә саташып, дөньядагы иң гадел, иң хак совет властена каршы төшеп маташасың, йонкытыйк? Кайсы илнең шпионы идең, сатлык җан?.. Әллә диверсант булып ил казанышларын җимереп йөрдеңме?.. Күпмегә саттың туган илне?.. Дөрес, дүрт бала әз түгел-түгелен... Хатын тол калды дисеңме? Балаларыңны ятим, хатыныңны тол иттең, әшәке җан!»

Мостафа кала тормышын яратты, гомергә шунда төпләнергә ниятләп башта хатынын үз янына чакырды. Малайлар Мостафаның этиләрендә яшәп торды. Инде шәһәрнең аулак урамнарының берсендә йорт сатып алып, яңача тормыш итә башлагач балаларны да озак тотмады. Иркен генә, тату гына тормыш көтә башладылар. Йорт аулак, күрше-күләннән кергән-чыккан кеше юк диярлек, сабыр һәм тыйнак Халисә дә кала тормышын үз итте, яратты. Күңелен өзмәс борчыган бер мәсьәлә генә бар иде: ул иренең эше, аның гел-гел төнгелеккә йөрүе, таң яралганда гына йә кәефләнеп, йә бөтенләй исереп, егылыр дәрәҗәгә җитеп кайтып керүе иде. Ярый, иптәшләре белән бер утырсын, атна саен салып кайтсын, кыенлык белән генә булса да аларына түздең дә, ди... Юк шул, аның Мостафасы ике-өч көнгә бер дөм исерек килеш кайта...

Башта нык чәпчеде Халисә, «балаларны алам да авылга кайтып китәм!» – дип куркытып карады, елады, каргады, атна буе сөйләшмичә тел яшереп йөрде.

Хатын-кызга Аллаһ Тәгалә чиксез киң вә юмарт күңел биргән, ир хакына кара язмышка да чыдый алар. Халисә яши-яши иренең тома сүзсезлегенә дә, таң аттырыр өчен генә кайтып йөрүләренә дә – һәммәсенә дә ияләнде. Күнекте дип булмый, ара-тирә янып-кабынып киткән чаклары булды, иренә ташланып көчсезләнгән йодрыклары белән аның корыч калкан күкрәкләрен төя-төя, бәргәләнеп елады.

Көннәр бер-берсен алмаштырып үтә торды, Мостафа бүген дә, таң уянып килгән мәлдә генә, ихатасы турына кайтып җитте. Халисәнең язмышын йомарлап, эчкә яшереп, иренен тешләп, сызып йөргән көннәре иде. Андый чакта Мостафа кайтып



керүгә ашыгып чишенеп ташлый, өс-башларын идәндә өеп, бер читкәрәк тибеп очыра, караватка ат менгәндәй сикереп куна, хатынын очыртып кочып ала, аракы исе тончыктырмасын өчен, авызын читкә бора, кайнар иңбашына авыр башын салып, иркәли. Дәшми, мышный гына. Озак итеп, манма тиргә батканчы коча. Иркәләү газапка әйләнә. Түзә Халисә, зарланмый. Ир хакы – Алла хакы. Аны бала чактан шулай өйрәткәннәр, ир хакын хаклаучы булырга әзерләгәннәр.

Мостафа тәмәкесен тартып бетереп, төпчеген күнитек үкчәсе белән җиргә сеңдергәннән соң, капка келәсен күтәрде, гаҗәп: капка эчтән дә бикләнгән иде. Аның өй алдындагы сирень үскән бакча коймасы артында үзе генә белгән тимер кендеге бар иде. Мостафа шуның белән каерып азаплана торгач эчтәге бик күтәрелде, капка ачылды. Тәрәзәдә кысып куйган ут яктысы күреп кинәт айнып китте: «Балаларга бер-бер хәл булганмы әллә?» дип уйлады. Ашыгып ишеккә атлады һәм түземсезләнеп шакылдата башлады. Эчтән йомшак кына йөткергән тавыш ишетелде. Халисә йокламаган икән, чишенмәгән дә, кысып кына куелган җиделе лампа челтәреннән төшкән чуар нурларны ияртеп килеп тә чыкты. «Әкрен», – диде ул ипле, йомшак тавыш белән. «Электр һаман юкмыни?» – дип сорады Мостафа өзеп кенә. Өченче көнге җилдә багана авып, алар урамнары белән утсыз калганнар иде. «Күрәсең ич», – диде тыныч кына Халисә. Мостафа күтәрелеп бәрелергә авызын ачкан иде, хатыны йомшак кулы белән аңа кагылды: «Иплэп, җаным, эти килде бит. Йокла, дим. Ятмый. Ишекле-түрле йөрде гел. Сине көтә. Бигрәк озак тордың, әткәсе». «Спирт озаттык, – диде Мостафа, чишә башлаган каешын яңадан тартып-кысып, – әзрәк тамак та чылаттык». «Кирәкмәс иде лә... – диде хатын, әрнеп. – Ичмасам эти белмәсен иде!» Мостафа бу юлы аңлатуны (түргә кереп) кирәк санамады, лампаны хатыны кулыннан тартып алып, эчке бүлмәгә китте. Өстәлгә терсәге белән таянып утырган әткәсе ут яктысыннан күзләрен челт-челт йомып аңа карады. Әткәсенең арык, нык ук бөкрәйгән җилкәсен күргәч, Мостафаның җанына ниндидер күптән татымаган җылылык йөгерде. Ул аңа-моңа хисап биреп тормастан, тырма куллары белән әткәсенең иңнәрен кочып үзенә таба тартты. Сүрән, куркынган яктылыкта алар бер-берсен таныргга теләгәндәй тырышып-тырышып карашып тордылар.

Таңгача тинтерәп көткән әткәсенең тәҗел вә авыр йомыш белән килгәнен чамаласа да, карт, татар гадәтен саклап, серен чыгарып бушанырга ашыкмады, саран гына хәл-әхвәл белештеләр. Халисәнең нидер әзерләп чәшке-чынаяк кузгатканы ишетелде, кече яктан самовар уянып тавыш бирде. Авыл-күрше хәлләрен бер-ике сүз белән белдергәннән соң, карт улына текәлеп карап болай диде: «Тәҗел бер маза килеп чыкты бит әле, улым. Башка бәла дисәң дә ярыйдыр...» Мостафа күкрәген баскан авырлыкны җиңәргә теләп тирән генә көрсенде, аңлату көтеп, әткәсенә карады.

Халисә, җитез кайный торган җиз самоварын кертеп, өстәл түренә утыртты, аяк үрә генә чәй агызды. «Ягез, утырышыгыз, – диде ул ягымлы төнге тавыш белән. – Әти, бая да чәй эчмәдең. Балын, маен кабып эч. Сумса суынгандыр инде, аны җылытып тормадым». Халисә акланган төсле тәрәзәләргә теге яктан терәлеп басып торган куедан куе караңгылыкка бакты.

Аталы-уллы күптәннән ризык бүлешкәннәре, уртак табын тирәсендә булганнары юк икән, башта ятсынып, соңра тарсынып чәйгә тотынырга базмыйча утырдылар. Ниһаять, Мостафа җанланды, зәңгәр бизәкле чәшкесен мичкә капкачы хәтле учына утыртып шопырдатып чәен чөмерде. Кыстасалар да, карт чәйгә үренмәде, тонык көмештәй елтыраган дага сакалын сул учына сыйдырып, улының пешенә-пешенә өченче чынаякны эчеп бетергәнен сабыр гына көтеп утырды. Авыр сулады, көрсенде, төннең сак тынлыгы рөхсәт иткәнчә җиң эченә йомшак кына йөткеренде. «Улым, – диде карт, тәүге сүзеннән үк йомышының җитди, олы икәнен сиздереп, – башка бәла төшәргә тора бит әле! Теге сине укырга китәргә өндәгән бәндә бар бит әле?..» «Муллинмы?» – диде Мостафа буш чәшкесен чыңгылдатып. «Шул инде, шул, кадалгыры! Беркөн килеп чыккан бу, кызмача. Исерек түгел, йөгенә кермим, мәгәр салган. Чәй куйдык, дигәндәй... Түргә үк кереп утырды, түш кесәсеннән сәгать чылбыры чыгарып уйната. «Хат язамы?» – дип сине сорый, «Укуыннан канәгатьме?» – ди. Синең эштә булуыңны белмәмешкә салына! Күзләре – тонык, бур мәченеке төсле төрле якка тәгәриләр, икмәктер! Шуннан әпә-чәпә сөйләшкәләп, аз-маз дөнья хәлләренә дә кагылгалап утырабыз, бәрәмәч, аягына басты бу, бәбәкләрен миңа терәде. Имәнеп киттем. «Урманыгыз янды, ун гектарда күпме агач юкка чыкканын беләсеңме? Совет властеның явыз дошманнары ут төртте, бер дә бүтән түгел!» димәсенме бу!

Ут чыгып, авыл өстендәге урманның шактый зур кишәрлеге янып бетүе хакында Мостафаның колагына чалынган иде, андый-мондый нечкәлекләрен белмәгәнгә, этисенә таба иелде, яңалыкларны көтеп сагайды. Карт туры сүзгә керешмәде, тәэсирләре белән бүлешергә тотынды: «Әй-яй, хәтәр икән ул урманга төшкән ут! Ходай күрсәтмәсен. Өч көн, өч төн тоташ янды бит, әй. Һич сүндерермен димә икән! Бер башта бетте дип кенә уйлыйсың, икенче төштән дөртләп кабына. Ишле яңгырлар килеп булышмаса, беткән идек. Әле дә көйрәп ятасы икән. Шуннан теге тоз күзне әйтәм, тасма телне! Син, димәсенме бу, фәлән-фәлән числоларда, ди, ут чыккан вакытны әйтә бу, кич кырын бозау эзләп болында йөргәндә, үзән аша урман ягыннан шыпырт кына кайтып килүче ике кешене очраттыңмы, ди. Очратуың турында раслап менә шушы дукаментка кулыңны куй, ди. Кешеләрнең берсе чулак Мөҗәһит иде, икенчесе теге, син егет чакта уйнап үскән Мидхәт иде, ди. Рәхимовны әйтә инде!.. Юк, мәйтәм, безнең бозау юк быел, сыер кысыр калды, рәхмәт төшкере, дим... «Бозавың юк икән, сарык эзләп чыккан идең бит», – ди. Ризаланмадым, кулымны куймадым. Кырмавык икән теге быткыч, тигәнәк икән! Өзми-куймый бәйләнде бит. Бер керә, ике, өченчесендә куркыта ук башлады. «Син ут салган дошманнарны күргәнсең. Синең мал эзләп буталуыңны әйтеп торучы шаһитлар бар», – ди. «Бармадым мин ул көннәрдә мал багарга», – дип карышам, ул сүгепме-сүгә! Аты-юлы белән җибәрә! Тукмап чыгарыр идем мин ул сатананы, сиңа бер-бер авырлык килер дип кенә шикләнәм».

Эчкән аракысы Мостафаның башыннан чыгып бетмәгән иде әле, аның тиз үк, шушы таңда авылга кайтып китәсе, дөп итеп Муллинның каршысына басасы һәм «Не сметь!» дип тегенең ипи шүрлегенә менеп төшәсе килде. «Не сметь!» дип команда биреп кычкырганын сизми дә калды Мостафа. Кече якта бала елады, шактый нык киергән икән бугазын йорт хуҗасы. Карт сүзен яңартмады, чәен чәшкесеннән генә йоткалап бетерде, улының күзенә туры карарга тырышып: «Йә, улым, ни дисең? Нинди киңәш бирәсең?» – дип сорады.

Мостафа ике сүз белән чияләнгән төенне чишеп булмаслыгын тиз аңлады. Карт атаң, киңәш сорап, синең алга килеп тезләнсен әле! Аптыраган җанның бердәнбер өмете син! Тик... районның иң хәтәр кешесе Муллинны да ничектер ризалатырга кирәк. Кулы озын аның Муллинның! Муллин да сау яшәсен, эти карт та судан коп-коры чыксын?!

Сүзсез җайсызлыктан аларны Халисә коткарды. «Ятыгыз инде», – диде ул кече яктан, әллә үгетләп, әллә кушып. Мостафа шушы саламга ябышты: «Ятыйк булмаса, – диде ул, учы белән авызын каплап, иснәгән булып. – Әнә яктыра. Аннан уйлашырбыз».

Башка төннәрдә, хатынын куенына алмаса, мендәргә башы тиюгә йоклап китә иде Мостафа. Бүген, юк, төнге, таң алды мәшәкатьләре белән йокы да каядыр качкан булып чыкты. Була бит шундый авыр чаклар, әллә уяу кеше, әллә йокыда, иллә мәгәр төш күрә! Ята-ята боргалана, тәгәри, мендәр почмакларын йомшартып карый – йомшармый мендәр! Кап-каты!

Әллә өнендә, әллә төшендә аңа бер тавыш ишетелде: «Мин синең атаң ич!» Караса, почмакта командиры басып тора. Ак күлмәк, ак чалбар кигән. Күлмәге кардай, түшендә кан табы! Ни гаҗәп, кан табы бер заман җәелә дә башлады; җәелә, җәелә – бөтен түшенә таралды.

Мостафа идәнгә шуып төшкән салкын мендәрен алыйм диеп иелде дә күзләрен ачты, караса, баш очында этисе басып тора. Ап-ак күлмәк кигән, ак ыштанының балагы очындагы баулар артыннан сөйрәләләр, димәк, чиктән тыш ашыккан карт. «Җайлы чакта китимче мин, улым, шулаймы? Уйлыйм да үземнең бәлагә юлыкканымны чамалыйм. Куркуын курыкмыйм, җаны барга юне чыгар әле!»

(Дәвамы киләсе санда.)

Үлеп терелү йоласы

Нурихан ФӘТТАХ

Фәнни әдәбиятта бу йоланы инициация дип атыйлар. Латинча initiatio сүзенең мәгънәсе: «совершение таинств, мистерий». Инициация урына русча «посвящение, приобщение» дигән сүзләр дә кулланыла. Бу сүзләрнең, терминнарның берсе дә әлеге йоланың тулы эчтәлеген чагылдыра алмый. Без моны татарча «үлеп терелү йоласы» дип атарбыз.

Үлеп терелү йоласы Австралиядә, Африкада, Яңа Гвинеядә һ.б. җирләрдә очрый. Бу йоланың эчтәлеге шуңа кайтып кала: кабиләдә ир һәм кыз балалар билгеле бер яшькә кадәр әниләре һәм хатын-кыз туганнары белән бергә үсә, бергә тәрбияләнә. Бераз вакыттан соң, тиешле яшькә җиткәч, ир балалар белән кыз балаларны бер-берсеннән аералар. Ир балалар аерым йортта яисә ирләр йортында өлкән ирләр белән бергә тәрбияләнә, кыз балалар шулай ук әниләре, әбиләре, апалары белән бергә үсә. Ир балалар –ирләр һөнәренә, кыз балалар хатын-кыз һөнәренә өйрәнә. Тагын да үсә төшкәч, ягъни үсмерлек чоры үтеп, балигъ булу чорына аяк басканда, ир балаларны төрле сынаулар аша үткәреп, ирләр җәмгыятенә, ирләр коллективына кабул итәләр. Яше җиткән кызлар да, төрле сынаулар аша үтеп, хатын-кызлар коллективының тулы хокуклы әгъзалары була. Ирләр арасына кабул ителгән ир балалар өйләнә, хатын-кызлар арасына кабул ителгән кызлар кияүгә чыга ала.

Сынау яисә үлеп терелү йоласын башкаруда бөтен ыру, кабилә катнаша. Билгеләнгән көнне барлык үсмерләрне бер урынга җыялар. Бу эштә өлкән ирләр яисә дин башлыклары җитәкчелек итә. Үсмерләрне авылдан читкә – куе урман арасына яисә еракка, таулар арасына алып китәләр. Тиешле әзерлектән соң аларны төрле авыр сынауларга дучар итәләр: аларның тәннәренә төрле җәрәхәтләр ясыйлар, алгы тешләрен сугып сындыралар, сөннәткә утырталар, беләкләрен тишеп каннарын чыгаралар, һ.б. Мондый сынау вакытында яшүсмерләр шыңшымаска, ыңгырашмаска һәм гомумән курку-каушау кебек тойгыларын сиздермәскә тиеш. Шул ук вакытта аңа кайбер азыкларны ашау да тыела. Ул сөйләшмәскә, ыруның башка кешеләре белән (аеруча хатын-кызлар белән) аралашмаска тиеш. Менә шул рәвешчә сынау берничә көн, берничә ай, хәтта берничә ел дәвам итәргә мөмкин. Мондый сынау вакытында кыз балалар да авылдан читтә – урман эчендә яисә таулар арасында яши.

Төрле җирдә, төрле халыкта бу йоланың башкаларныкына охшамаган үзенчәлекләре дә булырга мөмкин. Ләкин аның нигезе һәркайда бер төрле.

Үлеп терелүнең мәгънәсе фәндә төрлечә аңлатыла. Берәүләр моны яшьләргә кабиләнең күп еллык тәҗрибәсен тапшыру дип уйлый. Икенче берәүләр моны яшьләрне киләчәктәге авыр тормышка психологик яктан күнектерү, чыныктыру дип, өченче берәүләр кабиләнең бердәмлеген саклау кирәклеге белән аңлата. Бер автор тагын да яңарак фикер әйтә: «Инициация йолалары ул чынлыкта эш көченең составы һәм аны саклау турында кайгыртучанлык күрсәтүнең чагылышы булып тора», – ди. Без мәсьәләгә башкачарак күзлектән караячакбыз һәм әлеге йоланы кешенең тууга һәм үлемгә карата булган төп фәлсәфәсе нигезендә аңлатырга тырышачакбыз.

Яңа Гвинеядә, Сентана күле тирәсендә яшәүче папуасларда, битлек кигән кешеләр авылга килә дә, яшүсмерләрне тотып ала һәм урманга, табыну алачыгына алып китә. Хатын-кызларга әйтәләр: «Аларны Уаропо дигән аждаһа йотты», – диләр. 1891 елны инициация йоласы вакытында Коркор утравы папуаслары яшүсмерләрне төнгә урманда яшереп тота. Миссионер Кунце кызыксына башлый һәм: «Ник яшердегез аларны?» – дип сорый. Аңа: «Аларны Барак дигән ия ашады – хатыннарга һәм кызларга без шулай дип әйтәбез; берничә көннән соң ул аларны кире чыгарачак», – дип җавап бирәләр. Пурари елгасы дельтасында яшәүче папуаслар Кайемуна дип атала торган иянең сынын ясый. Һәрбер малай аның зур авызы аша эченә керергә һәм беркадәр вакыт аның «ашказанында» булып чыгарга тиеш. Шушы йолада катнашырга тиешле барлык малайлар ия эченәдә булып чыкканнан соң, Кайемунаны яндыралар. Йола вакытында гүелдәткеч нәрсәләр ярдәмендә ямьсез тавышлар чыгарып шау-шу ясала. Бу хәшәрәтнең тавышы дип уйланыла.

Үлеп терелү йоласы Яңа Гвинеядә әле бүгенге көннәрдә дә башкарыла. Кукукуку кабиләсендә һәр яшүсмер, ир кеше дип аталу хокукына ия булу өчен, махсус сынау үтәргә тиеш. Балага сигез яшь тулгач, ирләр рәтенә керү йоласы башкарыла. Кабиләнең «аксакаллары» яшь кукукукуларны урман эченә салынган ия йортына алып китә... Йолада катнашучылар бер сафка тезелә һәм тантаналы шартларда аларның борын яфракларын тишәләр. Борын яфрагын тишү бу очракта, күрәсең, «Үтерү»не яки ия авызына кереп чыгуны алыштырадыр.

Молук утрауларында үлеп терелү йоласында катнашкан һәрбер яшүсмерне Нику-Элате дип аталган бөек елан кабып йота һәм кире чыгара дип ышаналар. Африкадагы тома халкында да шундый йола бар. Үз теләкләре белән шундый йолада катнашучы ак тәнле кешеләрне дә томалар әлеге сынауларга дучар итә. Томаның дин башлыклары аларның тәненә җәрәхәтләр ясый, тиреләрен кисеп ала һәм: «Сезне бөек Урман Иясе ашап ташлады. Сезнең тәнегездә аларның теш эзләре торып калачак. Без – томалар кебек, хәзер сез дә ир булдыгыз», – дип әйтәләр.

Әлеге йола Австралия аборигеннарында да киң таралган. Тик монда яшүсмерләрне ия, аждаһа яисә елан авызына кертеп чыгару гадәте юк. Шулай да йоланың барлык детальләре яшүсмернең үлеп терелүен чагылдыра. Мәсәлән, Көнчыгыш Австралиядә сынау аша үтәргә тиешле яшүсмер үзен үлгән кеше кебек тотарга тиеш. Инициация йоласы ул чынлыкта үлү һәм терелү репетициясе. Кешеләр үлгәч терелү бар дип өметләнә. Һәм менә шуңа күрә дә инициация вакытында үлүгә, күмүгә һәм кайгы белдерүгә катнашы булган ритуал йолалар аеруча төгәл башкарылырга тиеш.

Үзәк Һиндстандагы санталларда үлеп терелү йоласы вакытында яшүсмернең сул як беләгенә яндырып берничә төртке ясыйлар, кызларның күкрәгенә берничә татуировка ясала. Көньяк Америкадагы яноама кабиләләре йола вакытында кызларны урман эчендәге ялгыз алачыкка урнаштыра. Алар анда беркем белән сөйләшми, бернинди хис-тойгыларын белдерми. Беренче көнне аларга ашарга-эчәргә бирелми. «Карантин» өч атнадан соң гына тәмамлана. Шуннан соң да әле алар – әлеге кызлар, ирләргә карамаска, кычкырып сөйләшмәскә тиеш.

Үлеп терелү йоласы борынгы грекларда да була. «Мәгълүм мифологик традициядә Ясонның Колхидада үлүе һәм яңадан терелүе турында берни әйтелми. Ватиканда саклана торган вазада исә аждаһаның батырны (Ясонны – Н.Ф.) йотуы һәм соңыннан төкереп чыгаруы сурәтләнгән», – дип яза Р.В.Кинжалов.

Шушы уңайдан без тагын да борынгы Мисырда, Сахарада табылган саркофаг капкачындагы Нутның кояш Раны тудыру күренешен күз алдына китереп бастырабыз. Чынлап та, Ра да Нутның авызына кереп үлә, тәмугка эләгә һәм яңадан туа. Ягъни кояш Ра көн саен үлеп терелү йоласын башкара.



Атнаның сәяси мизгелләре

ЯЛЫКТЫРГЫЧ КОНТРҺӨҖҮМ

Украинаның контрһөҗүмгә күчәргә әзерләнүе турындагы сүзләр инде күптәннән йөри. Бу җәһәттән төрле дәрәҗәдәге белгечләрнең, ул менә-менә башланырга тора, дигән фаразлары да шактый булды. Тик, көннәр үтә торды, ә аның актив фазасы һаман кичектерелә килде. Мондый хәлне шул ук экспертлар төрле сәбәпләр (язгы яңгырлардан соң туфракның кибеп бетмәве, гаскәрләрне әзерләүгә күбрәк вакыт таләп ителүе, сугыш коралларының яңа төрләре килеп җитмәве һ.б.) белән аңлатты. Һәм, ниһаять, узган атнада Украина президенты В.Зеленский үзенең видеомөрәҗәгатендә, Югары башкомандование ставкасының чираттагы утырышын үткәрүе, анда Украина кораллы көчләренең контрһөҗүмгә күчү вакытын раславы турында белдерде. Дөрес, аның төгәл датасын ул әйтмәде. Кремльдә исә, Киевнең андый игъланнарын Россиядә күзәтеп барулары турында әйтү белән генә чикләнделәр. Шуңа күрә, мондый хәлне инде тактика һәм мәгълүмат көрәше, дип кенә бәяләргә кала. Ак йортта исә Украинаның һөҗүмгә быел җәй күчәчәген әйткәннәр.

Ә ул арада бу дөньяның сәяси вакыйгалары үз чираты белән бара. Төркиядә, әйтик, президент сайлавының икенче туры үтте. Рәсми нәтиҗәләр буенча, анда бу илнең бүгенге президенты Рәҗәп Тайип Эрдоган, сайлаучыларның 52,14% тавышын җыеп, җиңеп чыккан. Аның көндәше Кемаль Кылычдароглу исә 47,86% кына тавыш җыя алган. Әлбәттә, Мәскәү өчен бу – кулай нәтиҗә. РФ Президенты В.Путин җиңүчене беренчеләрдән булып котлады һәм аны хәтта «кадерле дус» дип тә атады. Кабаттан сайланган президентның инаугурация мәрасимендә исә Россия исеменнән Дәүләт Думасы спикеры В.Володин катнашты.

Сәяси атнаның кайбер башка вакыйгаларын да санап үтик. АКШ президенты Джо Байден Төркия лидеры Р.Эрдоган белән Швециянең НАТОга керү мәсьәләсе хакында сөйләшкән. КАР (ЮАР) тышкы эшләр министрлыгы быел 22-24 август көннәрендә бу илдә узачак БРИКС саммитында катнашучыларга дипломатик иммунитет гарантияләве турында белдергән. Инаугурация мәрасиме узганнан соң, Төркия президенты янына, сөйләшү өчен, аерым-аерым Россия Президенты В.Путин һәм Украина лидеры В.Зеленский килеп китәргә җыена икән. Молдова лидеры Майя Санду, Россиянең вәзгыятьне катлауландырырга тырышуына да карамастан, 2030 елга Молдова һәм Приднестровье Европа Берлегенә әгъза булып керергә мөмкин, дип әйткән. Кытай Россия белән Украина арасында сөйләшүләрне яңартырга чакырган. Берлин Россиянең Алманиядәге 5 консуллыгыннан 4есен ябарга кирәклеге турында белдергән. Мәскәү моны ике арадагы мөнәсәбәтләрне җимерүгә юнәлдерелгән адым дип бәяләгән һәм аннан тыелып калырга чакырган.

Фоат УРАЗАЙ.

● Премьерадан соң.

СӘХНӘ –

Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театры 33 нче сезонда тамашачыларны премьералар белән дә, яңа проектлар белән дә сөендерергә өлгерде. Андый проектның берсе «Театраль педагогика» дип атала. Аның төп максаты – шәһәребездә яшәгән яшь тамашачыны, укучыны, укытучыны татар театр сәнгатенә тагын да якынайту, артистлар, сәнгать җитәкчесе белән ачык диалог алып бару һәм татар халкының танылган язучылары, драматургларының әсәрләре белән таныштыру. Әлеге проект кысаларында иң башта Т.Миңнуллин драмасы буенча куелган «Без китәбез, сез каласыз» спектакле күрсәтелде.

● «Болан».

Театр бу сезонда «Хәл бу ки...» дип аталган поэтик-документаль спектакльләр сериясен чыгаруны күздә тоткан иде, аның беренчесе «Хәл бу ки... Хәсән Туфан» – шагыйрьнең чынбарлыкка нигезләнгән тормыш мизгелләрен чагылдырды. Мәктәп дәреслекләрендә урын алган әдипләрнең тормыш юлы да, иҗаты да укучыларның күз уңына эләксә – эләгә, эләкмәсә – юк. Бүген, бөтен мәгариф системасы БДИ дигән бер сүзгә текәлеп торганда, кызганыч, татар әдәбияты турындагы мәгълүмат диңгездәге бер тамчы хәлендә генә. Бу җәһәттән «Хәл бу ки...» драмасы тамашачыларга шәхес бөеклеге, ил тарихындагы фаҗигале репрессияләр, чын мәхәббәт көче белән күзгә-күз карап очрашу мөмкинлеге бирә.

Үткән гасырның утыз җиденче еллары тарихка кара тап булып ягылган. Намус, тугрылык, дуслык дигән сүзләрнең сират күпере аша узып сыналу чоры бу. Спектакльдә әлеге сынауда иң көчлеләрдән булып кала алган Луиза Салиәскәрова образы калку итеп сурәтләнә. Ул рольне башкарган Флүзә Касаева (Татарстанның атказанган артисты) уенында «ир бирмәк – җан бирмәк» мәкале бөтен тулылыгы белән ачыла; үзенең канын (бәлки, шул сәбәпле, гомерен дә) бирү бәрабәренә төрмә камерасындагы Хәсәнен ачлыктан, авырудан коткарырга омтылган Луиза йөзендә хатын-кызның рухи көче чагыла. Спектакль шагыйрьнең биографиясен чагылдыруны максат итеп куймый, шулай да режиссер һәм инсценировка авторы Олег Кинҗәгулов кулланган символлар ярдәмендә иҗат һәм язмышның чәч толымыдай бик уңышлы үрелешен күрми мөмкин түгел. Хәсән Туфанның «Бирде дөнья кирәкне...» шигыре аша олысына-кечесенә бердәй таныш алкалар – парлылыкны, кавышуны һәм мәңгелеккә аерылышуны аңлаткан символик тамгалар спектакльнең башыннан азагына кадәр тамашачының күз алдында. Залга кереп, урындыкларга утырыша башлаганда ук, аларның карашы түрдә каршы алган Туфанның (Татарстанның халык артисты Рафик Каюмов) йомарланган учларында туктала. Хатынының соңгы ядкәре булып каршы алган алкалар, бераздан, бикле учтан «чыгып», бәхетле бөтерелгән Луизаның колакларында чыңлый; пычрак сәяси уен корбанына әйләнгән миллионнарның челпәрәмә килгән гомере булып, өстәлдә кадерсез аунап ята; акланган һәм акланмаганнарның бәгырь сызлавы булып, кабат уч төбендә сыкрый.

Спектакльдәге һәр персонажның шәхес һәм чор сулышын чагылдыру җәһәтеннән үз йөкләмәсе, миссиясе бар. Әдәбият галиме, «халык дошманы» дип атып үтерелгән Галимҗан Нигъмәти хатыны Жанна (Татарстанның халык артисты Гөлүсә Гайнетдинова) – андый тамга сугылганнардан йөз чөермәгән тугры дусларның җыелма образы кебек. НКВД солдаты – яшь артист Фердинант Насретдинов уенында үзенең дә система корбаны икәнен төшенеп өлгермәгән салкын йөрәкле, кансыз хәрби буларак кабул ителсә, ерак Бараба далаларында яшәп ятучы Кузьма карт (Фирдүс Сафин) һәм аның килене Клавдия Петровна (Индира Маликова) – кешеләрнең гап-гади бәхеткә хакы барлыгы, әмма ил һәм җир бүлешә алмаганнарның ул бәхетне бәллүр пыяладай кыеп төшерүләре хакында сөйләүче геройлар. Персонажларның барысы да спектакль барышында Х.Туфан шигырьләрен укый. Шагыйрьнең «Илдәниләр бар икән?», «Агыла да болыт агыла», «Нигә болай ашыгасың, йөрәк?», «Мин фәлсәфә чатырлары үрәм» һ.б. шигырьләре дә, Б.Пастернакның «Гамлет» шигыре дә яңгырый, һәм вакыйгаларга бәйле рәвештә аларның фәлсәфи асылы тамашачыга көзгедәгедәй чагылып тәэсир итә.

«Театраль педагогика» кысаларында бүгенге көндә Кече залда «Хәл бу ки... Фатих Кәрим» драмасы да мәктәп укучылары арасында киң яңгыраш алып килә. Ул театрның талантлы артисты Фирдүс Сафин инсценировкасы буенча куелды, режиссеры – Зөлфия Галиуллина. Тамашачыларга репресссия, сугыш елларында сынауга дучар ителгән язмыш һәм пулялар астында язылган үлемсез иҗат, Фатих (Марсель Мөсәвиров) һәм Кадриянең (Алсу Гыйльманова) мәңгелек мәхәббәте тәкъдим ителә.

Т.Миңнуллинның «Авыл эте Акбай» әкияте дә балалар өчен зур бер табыш, әлеге спектакль зур сәхнәдә бара.

Аяз Гыйләҗевнең «Баласын җуйган болан эзеннән» пьесасы буенча куелган «Болан» спектакле дә (режиссеры – О.Кинҗәгулов) премьера буларак дөнья күрде. Бу – гадәти драма гына түгел, ә ирония, юмор, гротеск белән сугарылган тамаша. Әлеге спектакль Татарстанның атказанган артисты Миләүшә Имамованың 50 яшьлек юбилее уңаеннан тәкъдим ителде.

Татарстан Театр әһелләре берлегенең финанс ярдәме белән куелган «Җаның ниләр тели?» дигән героик трагикомедия масштаблы булуы белән дә, бизәлеше һәм шактый фәлсәфи сорау күтәрүе белән дә үзенчәлекле. Беренчедән, спектакльдә бөтен



●«Хәл бу ки... Хәсән Туфан».

●«Хәл бу ки... Фатих Кәрим».

ТОРМЫШ КӨЗГЕСЕ

●«Җаның ниләр тели?»

труппа диярлек катнаша, күмәк күренешләрдәге актерларның да һәрберсенең үз йөкләмәсе бар. Икенчедән, рәссам Л.Хөсәенова бизәлешендәге сәхнә декорациясе, Р.Яхин, А.Монасыйпов, Р.Еникеев, А.Ключарев кебек композиторларның затлы музыкасы сәхнәдәге вакыйгаларга тәңгәл килеп, аларның эчтәлеген ачуда аерым бер роль уйный. Өченчедән, спектакль нәрсә турында дигән сорауга өздереп кенә бер җавап яңгырамый. Кемдер аны «авыл темасы, авылларның бетүе турында» дип кабул итәргә мөмкин, башка берәү өчен спектакль һәр буынга телдән-телгә күчеп килгән бичуралар белән дә кадерле булыр, кемдер исә кеше дигән затның асылын чагылдыра торган гомум сыйфатларга игътибар итеп укталыр. «Спектакльдә авыл темасының куе төсмерләр белән баюы – куелуга әзерлек барышында туган үзенчәлек. Пьеса кешенең матди байлык артыннан куып иманын, вөҗданын җуя алуы хакында. Бетеп барган авыл – кеше җанының бу ягын тулы күрсәтү өчен локация, декорация генә», – ди автор Артур Шәйдуллин.

Спектакльнең режиссеры, театрның сәнгать җитәкчесе Олег Кинҗәгулов исә биредә бик гади фәлсәфә чагыла дип саный: «Без бит менә телибез, телибез, тик нәрсә теләргә кирәклеген генә белеп бетермибез. Спектакльдә Гарифулланың (Марсель Мөсәвиров): «Сез кыюлык сорыйсызмы, әллә кыюлык күрсәтер өчен шартлар һәм мөмкинлекме?» – дигән репликасы бар. Бу фәлсәфә Соломон легендаларыннан килә: ул бит бер дә хаким булырга телим дип сорамаган, ә зирәклек сораган... Узган ел яз көне Артур миңа 6 пьеса тәкъдим иткән иде, башта һичберсе дә «эләктермәсә» дә, кабат укыгач, «Җаның ниләр тели?» дигәнендә бичуралар, йорт иясләре турындагы этюд игътибарны җәлеп итте. «Күренеш җитенкерәми иде, кайбер персонажларның язмышы ачыкланып бетмәгән, Сирин – безнең дингә якын булмаган мистик җан иде. Менә шуларны үзгәртү турында автор белән киңәшләштек, пьеса белән бер елга якын эшләдек. Аллага шөкер, үз фәлсәфәсе булган спектакль килеп чыкты».

Бу спектакль – безнең тормышыбызның көзгесе. Кешеләрне заман үз иләгендә или: һәркем нәрсәгә лаек – шул рәвешле. Көчсезләр дә, телсезләр дә, нәфес, дан-дәрәҗә колы булганнар да, башкалар мәнфәгатен кайгыртып, үзен корбан итәргә әзерләр дә бар ул иләктә. Тик заманга гына үпкәләү дөрес булыр микән? Заманны гаеплибез, мәктәпләр бетүгә, балаларның туган телдә сөйләшмәвенә, кешеләрнең бәгыре кырысланугa – бетмәс-төкәнмәс сәбәпләргә зарланабыз... Р.Фәйзуллинның «Җаныңның ваклыгын сылтама заманга» дигән шигырь юллары бар. Ә бит кемнедер гаепләгәнче, олыбыз-кечебезгә үзебезнең җан түренә үрелеп карау, аның тузанын кагу комачауламас иде.

Авыл өлкәннәрен ишетегез (Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты И.Фәхретдинов, Татарстанның халык артистлары Г.Гайнетдинова, Р.Каюмов, Б.Сәлахов, Татарстанның атказанган артистлары Р.Сәгъдуллин, Г.Фәйзерахманова): кемдер мал астын чистарта торган сәнәгә турында кайгыра; икенче берәве, завод төзер өчен уңайлык ясап, ниемә авылга асфальт салдырдың, газ керттең, дип авыл башлыгын битәрли; өченчесенә һаман саен авыл кешесеннән акча каерулары ошамый. Ошамый, әмма алдына куелган тартмага иң беренчеләрдән булып кесәсендәге соңгы тәңкәләрен чыгарып сала!.. Берсен, үзе дә таныргa теләмәгән татлы хыялы булып, авыл башлыгы кәнәфие ымсындырган икән... Элекке полиция лейтенанты кобурасын һәм яңа погоннарны сагынып тилмерә...

Тамашачы күз алдында без яшәгән чорның байтак затлары җанлана, анда татлы сөйләп кешене төп башына утыртучы түрә дә (Э.Латыйпов), милләт өчен җан атуы тел тегермәненнән артмаган активист та (Р.Ибраһимов), сенсация эзләп йөрүче журналист та (Татарстанның атказанган артисты Ч.Садыйкова), бәхете һәм бәхетсезлеге фатир, мал-туар, мәхәббәт дигән төшенчәләрдән торган ханымнар да (А.Гыйльманова, Л.Минһаҗева, Татарстанның атказанган артисты Н.Сәләхова), гомер буе башкалар тормышын кайгыртып яшәгән авыл башлыгы да (бармак белән генә санарлык булса да, тормышта андыйлар да очрый әле, бу рольдә Татарстанның атказанган артисты Р.Гыйләҗев уйный) бар.

Спектакль тамашачыны битараф калдырмый – иң мөһиме шул. Соң чиктә, бик күпләр: «Шундый сорау һәм мөмкинлек бирсәләр, мин нәрсә теләр идем икән?» – дип булса да уйланып чыга залдан. Кызык шул, бер теләккә ике катлы фатир да, мунчасы булган дача да, тулы бер галәм дә сыяргa мөмкин. Һәркемнең үз каланчасы.

Быел Аяз Гыйләҗевнең тууына 95 ел тулу уңаеннан театр тарафыннан үткәрелгән чаралар турында да әйтеп үтик. Коллектив белән язучының каберен зиярат кылу, аның хатыны Нәкыя апада кунакта булу, «Татмедиа»да пресс-конференция оештыру, радио-телевидениедә чыгышлар ясау һәм февраль аенда Казанда гастрольдә булып, Камал театрында өч көн дәвамында спектакльләрне тәкъдим итү Аяз ага рухына дога булып ирешкәндер.

«Тантана» премиясендә Индира Маликованың «Иң яхшы эпизодик роль» номинациясендә (Клавдия Петровна роле өчен) җиңү яулавы, Татарстанның атказанган артисты Рафил Сәгъдуллинның Дамир Сираҗиев исемендәге премиягә ия булуы, «Абага алмасы ачы була» спектакле (Р.Сабыр) иҗат төркеменең Тукай бүләгенә кандидат итеп күрсәтелүе, төрле төбәкләргә гастрольләр дә – театр өчен куанычлы вакыйгалардан.

Афишалар, яңалыклар, «бу спектакльгә урыннар калмады» дигән – тамашачы өчен көенечле, артистлар өчен сөенечле белдерүләр, берсеннән-берсе җылы кайтавазлар, кыскасы, кайнап торган тормыш безнең социаль челтәрләрдә һәм театр сайтында даими яктыртылып килә. Күзгә-күз театр залларында очрашырга язсын.

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА,
театрның әдәби
бүлек җитәкчесе.

● Тукайның Фәтхи Бурнаш тарафыннан әзерләп 1926 елда чыгарылган тәүге сайланма әсәрләр китабы.

● «Аң» журналында Г.Тукайның вафаты турында игълан ителгән сан.

БЕЗДӘН КҮЧКӘН

(Ахыры. Башы 21 нче санда).

«Беркемгә каршы да сугыш алып бармаучы» илнең патша хөкүмәте 1818-1850 еллар дәвамында Кавказны тулысынча яулау өчен сугыш кузгата. Егетләрен сугышка алудан тыш, өстәмә салымнар белән дә газаплыйлар. Кеше башына 10 кило сохари, кием-салым, 8 йортка бер ат, Кавказ тауларына үрмәләү өчендер унар метрлы юан һәм нечкә арканнар әзерләү бурычы житкерелә. 1839 елда шушы гаделсезлек өчен Күгәрчендә яңа чуалыш кузгала. Алар Оренбургтан салым җыярга килгән түрәләрне кыйнап җибәрә. 27 октябрьдә авылга 4 казак һәм тикшерүче килеп төшә. Тугыз гаилә башлыгы судка чакырыла, йорттан-йортка йөреп, сатуга яраклы бар нигъмәтне җыеп чыгалар. Мондый талаудан җыелган мөлкәт сугыш кирәк-ярагы гына түгел, Мәскәү белән Петербург арасында салына башлаган тимерьюлны төзү өчен дә озатыла...

Күгәрчен егетләре үз авылларыннан соң Каргалы, Стәрлебаш, Бохара мәдрәсәләренә барып та белем ала. Вәлит Шаһимәрдәнов атлы шәкерт Баймактагы Юлык авылына барып, татар мөгаллиме Мөхәммәтҗан ишанда гыйлем эсти. Наданлык – ул караңгылык та бит, ә Күгәрченнең Сәгыйтов, Искәндәров атлы ирләре Оренбург һәм Каргалы байларына ялланып, Бохарага тикле кәрван йөртә.

Тәүлегенә 140 чакрым ара узып, алар базарлардан тирә-як халкына борыч, дарчин, канәфер, чәй-шикәр, йөзем белән бергә читек-кәвеш, чапан-чалма, кәләпүш һәм сәхтиян читекләр алып кайта. Күгәрчен кызлары һәм хатыннары да һич һөнәрсез түгел, алар базарларга кәҗә мамыгыннан челтәрләп бәйләнгән затлы шәл һәм мамык күлмәкләр озата. Күгәрчен ирләре Оренбургта 1838-1844 елларда алып барылган Кәрвансарай төзелешендә дә катнаша. Һәр ел саен дүртәр ир-ат Кәрвансарайдагы кунакханә һәм мәдрәсә, шәрык өслүбендә калыккан мәчет төзелешен алып бара, Хәмидулла атлы егет хәтта есаул дәрәҗәсенә дә лаек була... Кызганычы шул: 1846 елда кузгалган янгын Күгәрченнең янә 23 йортын, 1849 елда тагын 8 ихатаны юкка чыгара. Шуңа да карамастан, 1850 елда Күгәрчендәге халык саны 320 гә җитә.

Ә аннары «һичкемгә дә һөҗүм итми торган» ил 1873 елда Коканд, Хива, Бохара ханлыкларын яулау, 1877-1878 елларда Босфор һәм Дарданелл бугазларын кулга төшерү, Урта диңгездә үз хакимлеген урнаштыру өчен, Төркиягә каршы сугышка ташлана. Күгәрчен егете Нуретдин Сәлимов атлы гаскәрдә хезмәт итеп, Хива ханы Әсфәндиярны кулга төшерүдә катнаша. Шушы ук авыл егетләре Фәйзулла белән Мөхәммәтнәфыйк рус солдатлары белән бергә 1878 елда Андрианополь каласына бәреп керә, әмма урам тутырып яткан мәет тауларыннан өшәнеп, кире чигенәләр...

1887 елда патша галиҗәнапларыннан җан башына салым бетерелү турында фәрман килеп төшә. Бу исә төп йорттан угыл-киленнәрне аерып чыгару, аерым йорт төзеп, үзбаш яшәү өчен форсат тудыра. Авылның үзәк урамы буйлап ике якка Үрге һәм Түбән очлар үсеп чыга. Ләкин 1891 елның җәендә корылык башлана да ике ел буе дәвам иткән ачлык барышында 32 кеше вафат була. Адәм балалары эт, песи белән туклануга житә, тиф чире кузгала. Тик барыбер авылда 110 йортта 225 ир-ат, 230 хатын-кыз гомер сөргән әле. Ә 1900 елда авылның 152 йортында 848 кеше гомер иткән. Йортларны дүрт яисә алты почмаклы итеп салганнар, дүрт почмаклыларына читәннән үреп, өчпочмак өстәгәннәр. Авыл мәдрәсәндә 1895 елда – 76, 1913 елда 81 шәкерт белем алган.

1904 елда башланган рус-япон сугышына Күгәрчен авылы янә 4 егетен озаткан. Алар Беренче Себер корпусы составында Мукден каласы янында сугышка керә, Сагынбай Ишкилдин атлысы яуда һәлак була. Сәхиулла Ваһапов белән Нуретдин Халитов атлылары кайсыдыр диңгез портына житеп, андагы япон корабларын төпкә җибәрү өчен суга чумып, кораб стенасын борау белән тишү кебек аферада да катнаша. Соңыннан икесе бергәләп «Рус-япон сугышы» дигән бәет тә тудыра. Андагы «Бозлы суда кара төндә / Корабларын тишәбез. / Күпләребез чыдый алмый / Су төбенә китәбез», дигән юллар хакыйкатьтән һич тә ерак йөрми...

1914 елда Күгәрчен авылындагы мәдрәсәдә укыта башлаган Сафиулла атлы 23-24 яшьләрдәге егет белән бәйле бер хатирә бик кызыклы. Нәкъ шул көннәрдә авылга икенче тапкыр кияүгә чыккан бер хатын күчеп килә, ә аның 17-18 яшьләрдәге бик тә чибәр Фәрхинур атлы кызы бар икән. Сафиулла белән Фәрхинур бер-берсенә шундук гашыйк була. Әмма үги атай Фәрхинурны 46 яшьлек бер иргә икенче хатынлыкка биреп, бик зур калым акчасы каерырга ниятли. Туй көне якыная. Хәвефне сизенеп, яшьләр авылдан качып китәргә план кора. Ләкин Фәрхинурны үги атасының ике кызы саклый, түшәктә дә кәләшнең ике ягына ятып йоклыйлар, хәтта аның итәк очларын үзләренекенә дә бәйләп куялар. Кәләш җаен табып кайчы эләктереп ята һәм сакчылар йокыга киткәч, итәкләрен кисеп качуга ирешә. Алар 15 ел үткәч, 1930 елда гына Күгәрченгә Оренбургтан колхозлар төзү уңае белән әзерләнгән «Галиябану» спектаклен күрсәтергә, артистлар труппасы составында килеп төшә. Төп рольләрдә, әлбәттә инде, Фәрхинур белән Сафиулла уйный...

Ә 1914 елның 7 августында Герман сугышы башлангач, шушы ук Күгәрчендә бер егет бер кыз өчен Әмирҗан атлы авылдашын күсәк белән сугып үтерә. Бер үк төрле каршылыкта ике төрле тәкъдир...

Ә сугышка егетләрне генә түгел, атларны да күпләп озаталар. Фронтка озату өчен, халык сохари әзерли, аның нормасы 1914 елда 4 кг булса, 1916 елда 12 кг га җитә...

1917 елда патшаның тәхеттән баш тартуын Оренбургтан Кызыл Мәчеткә кайтып баручы олаучылардан гына ишетәләр. Властька большевиклар партиясе менеп алгач, аның үз сүзендә ничек торуын да бик тиз чамалыйлар. 1918 елның 2 ноябрендә, мәсәлән, ЧОН отряды берүзе яшәгән ятимә Хәят карчыкның халык сәдака-хәер рәвешендә биргән 4 чиләк бодаен һәм 2 чиләк тарысын талап ала. Шул ук көнне Троицк каласыннан килеп тегермән эчендә яшәгән урыс картын канга батырып кыйныйлар: «Соңгы ике айда кемнәр тегермән тарттырды, давай, сөйлә!» Ике сүзнең берендә «Именем революции!» дип яный-яный, кызылгвардиялеләр авылның 122 йортын шәрә калдырып чыга...

1918 елның апрелендә Оренбургтан Темәскә юл алган Зәки Вәлиди дә Күгәрчен авылы аша урап үтәргә мәҗбүр була. Юлда гел кызылларның отрядлары очрап торганга, ул Мокач-Чаер аша Күгәрченгә көймә белән чыккан икән. Вәлиди халыкның кызылларга һәм «ирекле башкортлар» гаскәренә мөнәсәбәтен ачыкларга тели. Ә халык яшереп тормый, чөнки аларны кичә кызыллар талап чыкса, бүген «башкорт хөррияtчеләре» килеп, бугазланып ала. Вәлиди аннары мәчеткә кереп, «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем алган Нуретдин атлы егет белән очраша. Болар сөйләшеп торган арада урамнан бер чапкын авылга 30-40 лап кешелек отряд якынлашуы турында сөрән салып уза. Берничә егет озатуында Вәлиди Үрген авылына юнәлә, «баш башкорт»ка башкача Күгәрченгә килеп күренү бәхете эләкми...

1921 елда башланган ачлык Күгәрчен халкын яртылаш кырып сала. Бер язмада вафат булучылар саны 594 дип күрсәтелсә, икенчесендә 648 кеше вафат итеп теркәлә. Бу елда Кече Башкортстан 13 вак кантонга бүленсә дә, коточкыч казаны контрольдә тота алырдай бер оешма да булмый. Мәҗит Рәфыйковның этисе, күңелне юату өчен язучы, гомер буе мәдрәсәдә укыткан Мәгъсүм агай теркәп калдырган истәлекне ачыйк. «Илдә укый-яза белүчеләр нибары 32 % кына тәшкил итсә, Күгәрчендәге ирләрнең – 76, хатыннарның 68 проценты төпле гыйлемгә ия». 1927 елда мәҗбүри рәвештә латин графикасына күчерсәләр дә, гыйлемгә омтылыш барыбер юкка чыкмый, 1932 елда ук авылда җидееллык мәктәп эшли башлый...

Күгәрчендә 10 хуҗалыктан торган беренче колхоз 1929 елның 1 августында оеша. Унынчысы – президиумга сайланган крестьян Нургали Гомәровның 8 яшьлек улы. 1930 елның февраль ахырында инде Күгәрчен хуҗалыкларының күпчелеген колхоз ягына аударып бетерәләр. Ә кем колхозга керми, шул – кулак! Һич тә ялындырып тормыйча, районнан авылга ОГПУ рәисе һәм тагын 6 коралланган кеше килеп төшә. «Япония белән Америка тегермәненә су койган» М.Халитов, Г.Хәсәнов, Г.Бәширов, бертуган Искәндәровлар һәм тагын ике кешенең гаиләләре авылдан сөрелә. «Кулаклы-муллалы, мәчетле-Корьәнле искелек белән колхозлы, коммунлы, комсомоллы яңа тормышның бугазга-бу-

КҮГӘРЧЕН

газ килгән чаклары», – дип хозурланып искә ала аны М.Рәфыйков үзенең «Су башы» дигән китабында. Ә ике аты, дүрт умартасы булган В.Ваһапов, ике сыер, өч сарыкка ия М.Хәйбуллин һ.б. сөргенгә юл ала. Башкортстан буенча 12 мең кеше кулга алына, аны да азсыналар, 1931 ел башында тагын 2878 кеше төрмә һәм лагерьларга озатыла. Ә бөек замана терәге булган колхоз 32 баш сыер, 46 баш ат һәм 73 баш сарык белән коммунизга юл тота...

1931 елның 9 июнендә авылда Коръән һәм гарәпчә язмалар саклаучы кешеләрне дә тикшереп чыгалар. Авыл мулласы Сәхиулла Маннанов йортыннан урамга куыла. Ә 1932 елның кышында янә 1921 елгысыннан һич тә кайтыш булмаган яңа ачлык афәте куба. Күгәрченнекеләр азык эзләп Казахстанга юл алса, ачлыктан котылырга атлыккан казах вәкилләре Башкортстанга килеп егыла, шундыйлардан Мөхәммәт Янгучугов авылда төпләнеп тә кала. Ә казах далаларында купкан ачлык турында Миркасыйм ага Госманов: «Киез тирмәләрнең әйләнә-тирәсендә ачтан үлүчеләрнең күмелмәгән мәетләре аунап яткан буп-буш казах авылларын еш урап үтәргә туры килде», – дип, ачынып бәян итә. Менә яңа тормыш!..

1937 елның маенда Моракган килгән чиновник: «Йә мәчет манарасын аударып котыласыз, йә Себергә кулак итеп сөрәбез!» – дип өркеткәч, япәтник кешеләр табылмыйча калмый. Әүвәл Күгәрченнең ике ире үзәк мәчет манарасын пычкы белән кисеп аудара, 1939 елда икенче мәхәлләнең Яшел мәчет манарасы да юк була... Аның каравы, салым системасы гөрләп эшли. Сыер-сарыгы бар гаиләгә еллык салым – 4 кг сары май, 45 кг ит, 5 сарык тиресе, 150 йомырка. Балаңны 8-10 нчы класста укытасың килсә, елына 50 сум. Түләмисең икән, балаңны ал да, әллүр колхоз фермасына!..

Күгәрчен авылы Бөек Ватан сугышына 240 ир-егетен озатса, шуларның 105е яу кырыннан әйләнеп кайта алмый. Исән кайткан 137 ирнең дә байтагына озак еллар буе яшәргә насыйп булмый, алар фронтта алган яраларыннан бер-бер артлы китә, кими бара. Ә колхоз дигәннәренең күкрәк сугардай егәре дә юк бит. 1941 елның май аенда колхозда 58 баш сыер, 786 баш сарык, 318 күркә, 253 ат исәпләнә. Атларның күпчелеген фронтка озаталар. Авылда өрәктәй ябык хатын-кыз да, сыннары да ныгып өлгермәгән малай-шалай белән кыз-кыркын. «Фронт таләбе буенча» 1942 елның башында гына да авылдан 240 бияләй, 310 пар оекбаш, 34 сарык тиресе, 17 пар киез итек, капчык-капчык сохари озаталар. Йортында балалар авызына чүпләп салыйм дисәң, бер валчык икмәк юк. Ындыр табагында эшләүче хатын-кызлар кесәсеннән ярты кило бодай, арыш, солы табыла икән, бер ел төрмә. Ике алъяпкыч кесәсеннән кило ярым арыш табылган М.Сәлимова, бер кило да 700 грамм борчак «урлаган» Г.Якиева, иген үлчәүче М.Гомәровка икешәр ел төрмә... Ә иректә калганнар сыерлар белән басуларны сөр-тырмала, үгез җигеп, керосин ташы. Урак өсте җитсә, һәр хатын-кыз көненә урак белән 25 сутый ашлык урырга, урак барышында 1,5-2 мең көлтә бәйләргә тиеш. Җыелган ашлыкны кырып-себереп, әллә кайлардагы мөгәҗәйләргә илтеп яшерәләр, ә яз җиттеме, чана-арба тартып, һәрбер хатын шул җәһәннәмдәге мөгәҗәйдән берьюлы 32 кг орлык ташырга тиеш. Ул гына да җитми, мәктәп балаларына тикле, бригадаларга бүленеп, ягулык өчен җәй көне икешәр мең плитә кизәк сугып киптерергә мәҗбүр ителгән. Монысы да – якадан килеп эләктергән яңа тормыш...



● Без Нигъмәтулла агай мирасханәсендә.

Күгәрченлеләр әлеге каза-михнәтләрне онытканнар инде. Бүгенге яшь буынга сөйләрдәй ветераннар да сирәк кенә калды. Әле ярый, аларны бүлек-бүлек итеп туплый һәм китап итеп чыгара белгән өлкән буын вәкиле Нигъмәтулла Ваһапов атлы гүзәл ядкәрче бар. Без аның белән Күгәрчен авылы мәктәбендә таныштык, аннары ул яшәгән йортына да кунакка алып китте. Йорты – байтак музей һәм архивларны да көнләштерә алырлык затлы мирасханә. Үзе – сокланырдай гыйлемле, бик тә сирәк мөгаллим.

Нигъмәтулла агай 1945 елда Күгәрчендә туган. Кәрвансарай төзелешендә есаул дәрәҗәсен алган Хәмидулла – аның ерак бабасы. Нигъмәтулланың әнисе сабыйга ике яшь вакытта ук вафат булып куя, әтиләре Хәмидулла 1950 елда яңа хатын алып кайта. Нигъмәтулла 1961 елда җидееллык мәктәпне тәмамлый да Чиләбе каласына, бертуган апасы Галиябану янына китеп бара. Тулай торакта яши, төзелештә эшли, кичке урта мәктәпне тәмамлый. 1968 елда Казан университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Кураторлары – Хатыйп Миңнегулов, төркемдәш дуслары – Роберт Миңнуллин, Мөҗәһит Әхмәтҗанов. Студент вакытында ук фольклор җыю экспедицияләренә йөри, археологик казу эшләрендә катнаша. 1973 елда университетны тәмамлагач Алексеевск, Арча, Кукмара районнары мәктәпләрендә тарих һәм тел-әдәбият фәннәрен укытса да, фән белән шөгыльләнүдән туктамый. Экспедицияләрдән бик тә сирәк кульязмалар һәм китаплар табып кайтканга күрә, Нигъмәтулланы Татарстан Фәннәр академиясе каршындагы аспирантурага чакыралар, ә үзе Милли музейга фәнни хезмәткәр булып күчә. Әмма адәм баласы хыял-ниятләрен канат итә башласа, усал тәкъдир аны җир өстенә тартып төшерә шул. Авылдагы 82 яшьлек әтисе кинәт авырый башлагач, аны тәрбияләү өчен, Нигъмәтуллага Күгәрчененә кайтып китәргә туры килә, ул шундагы мәктәпкә укытырга керә. 1979 елда башкорт кызы Сания белән гаилә гаилә корып, гомерлеккә төпләнеп тә кала. Ике кызлары бар, Ләйләсе – психолог, ә Ләйсәне – филология фәннәре кандидаты.

Нигъмәтулла агай безгә йортындагы идән-ятакларга дистәләгән борынгы китап нөсхәләрен җәеп салды. Габдулла Тукайның әле үзе исән чагында ук дөнья күргән «Исемдә калганнар», «Печән базары» һ.б. китаплары. Сәгыйт Рәмиевнең тәүге җыентыгы. Риза Фәхретдиннең 1908 елда ук басылган «Асар» данәләре, шуның ук Ибн Баттута сәяхәте турында бәян иткән китаплары. Ул Оренбургта бастырган «Әбугалисина», Каюм Насыйри, хәтта Турнереллиның Болгар хәрабәләренә багышланган һәм рәсемнәр белән баетылган мираслар. Һади Атласиның 1911, 1914 елларда дөнья күргән «Себер тарихы» һәм «Сөембикә», Әхмәтзәки Вәлидинең 1912 елда Казанның «Милләт» нәшриятында бастырылган «Төрек вә татар тарихы» китаплары... Революциягә кадәр үк нәшер ителгән «Кояш», «Йолдыз», «Казан мөхбире», «Аң», «Дин вә мәгыйшәт», «Ялт-йолт» матбагаларының аерым данәләре... Безне аеруча Тукайның вафаты турында хәбәр иткән «Аң» журналы битләре, аның әсәрләрен 1926 елда туплап, Фәтхи Бурнаш чыгарган сайланма әсәрләр китабы шаккатырды. Без бүген йөз мәртәбә күчереп бастырган Кушлавыч авылының, анда Тукай үскән йорт, ул укыган мәдрәсә, хәтта шагыйрьнең Клячкин хастаханәсендә вафатына ике атна кала алынган соңгы рәсеме – һәммәсе дә шушы 1926 ел китабында дөнья күргән икән...

Нигъмәтулла агай китап-газеталарның бер битеннән икенчесенә бал кортыдай күчә, гарәпчә һәм иске төрки телдә язылган барча текстларның аңлатмасын бирә, иңнәренә канат үскән сыман, күзләрендә – очкын. Без, фәкыйрьләр, текәлеп шаккатабыз. Нигъмәтулла агай да инде ярты гасыр элек үк фәннәр кандидаты, хәтта доктор була алыр иде. Әдәбият фәне күренеклегә әверелә алырдай бер галимен югалткан...

Дөрес, Күгәрчендә дә эзсез генә гомер итмәгән ул. Кырык елга якын гомерен бөтен тирә-як балаларын укытуга биргән. 1994 елда «Башкортстанның атказанган мөгаллиме» исеменә лаек булган. 2006 елда «Россиянең иң яхшы укытучысы» конкурсында җиңгән. 2003 елда ук татар теле буенча дәреслек әзерләгән һәм аның шушы әсбабы 16 ел буе кабатлап басылган. 2014 елда үзе туган Күгәрчен авылының тарихына багышланган китап та нәшер иткән. Без бүген байтак мәгълүматны шул китаптан алдык. Күгәрчен районында гомер итүче туганнары аны Татар иҗтимагый үзәгенең урындагы рәисе итеп тә сайлаган. Ул бүген дә сукранмыйча, туган мәктәбенә һәм татар фәненә бирелеп яши. Ә мин фәкыйрегезнең күңелен тынгысыз уй бораулый: Нигъмәтулла агай кулындагы зиннәт кемгә калыр, кемгә эләгер икән?..

Вахит ИМАМОВ.

Автор фотолары.

(Дәвамы. Башы 20,21 нче саннарда).

Гаяз Исхакый һәм Габдрәшит Ибраһим мөнәсәбәтләре

Әлбәттә, Г.Исхакыйның Г.Ибраһим өстенә аткан бу дәлилсез гаепләүләрен тарих растамады, ләгънәтләрен милләт кабул итмәде, чөнки Габдрәшит хәзрәтнең дә ислам өчен, халкыбыз өчен хезмәте гаять зур иде! Әлбәттә, Габдрәшит хәзрәткә «Шаһгали варисы» дигән кара тамга да ябышмады, киресенчә, туган ягы аны зурлап, Күчем хан дәвамчысы итеп кабул итте. Шәҗәрәсе буенча Г.Ибраһимның Себергә ислам дине алып килгән Бохара дәгъватчы-сәедләр токымыннан булуы, нәсел тамырларының Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәламгә барып тоташканы да билгеле. Әмма ни гаҗәп, Г.Исхакый томлыкларын әзерләүчеләр, аның тарихи хатасын төзәтәсе урында, Г.Ибраһим исемен түбәнәйтүдә үз өлешләрен керткән. Г.Исхакый мәкаләсендәге «Буби»ларның мөдәррисләрен төрмәләргә яптыручылар…», дигән сүзләрне шәрехләп, томны төзүче, текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче З.Мөхәммәтшин Буби мәдрәсен яптыруда Габдрәшит хәзрәтне дә гаепләп, «М.Мәһдиев мәгълүматлары буенча, Г.Ибраһимовның да катнашлыгы булган. Алар тырышлыгы белән Бубилар мәдрәсәсеннән ун кеше кулга алына» дип яза (Күрсәтелгән хезмәт, 333 б.).

Бу да Габдрәшит хәзрәт өстенә ыргытылган яңа яла! Билгеле булганча, Г.Ибраһим җәдитчә укыту тарафдары була, «Иттифак» корылтайлары Бубилар белән бергә уздыра, 1907 елда «Мең дә бер хәдис» китабы өчен хөкем ителә һәм 1908 елда илдән чыгып кача. Бубилар мәдрәсәсен 1911 елда ябалар, җитәкчеләрен кулга алалар, ул вакытта Габдрәшит хәзрәт Төркиядә яши, аның ничек ул мәдрәсәне яптыруда катнашы булсын?! Бу вакытта ул Истанбулда, Йосыф Акчура, Әхмәт Тажетдиннәр белән бергә, «Тәгаруфи мөслимин» дип аталган журнал чыгара, анда даими рәвештә Россия мөселманнарының авыр хәле тасвирлана. Шул сәбәпле аның үзен Россиянең патша хөкүмәте «кара исемлеккә» кертә. 1911 елның 6 февралендә Ырынбур губернаторы исеменә язылган «О движении панисламизма» дип аталган белешмәдә 56 ышанычсыз «панисламист»ның исемлеге бирелгән, алар арасында Г.Ибраһим да бар. (ГАОО, ф.10, оп. 4, ед.хр. 412, стр. 5.) Һәм ул елларда тентелгән, кулга алынган татарларның кайберләрендә Габдрәшит хәзрәтнең тыелган китабы – «Мең дә бер хәдис» табыла. Бары тик шуннан чыгып кына Г.Ибраһимны Буби мәдрәсәсен яптыруда, җитәкчеләрен кулга алдыруда гаепләү – бу аңа күрәләтә яла ягу, намусын пычрату булып тора!

Әгәр Г.Ибраһим ул вакытта Россиядә булса, аны беренче булып төрмәгә утыртырлар иде! Петербург охранкасы аны инде 1907 елдан бирле күзәтә, эзәрлекли, эзләтә, яңадан кулга алырга җыена. Бу хакта охранканың 1911 елның 9 февралендә Казан округ

● Алда, уңнан сулга: Гаяз Исхакый, Габдрәшит Ибраһим, Габделхәй Корбангалиев. 1933 ел, октябрь. Токио, Япония.

судына Г.Ибраһим буенча әзерләп җибәргән белешмә-справкасы да расләй:

«Ибрагимов издавал книги, брошюры и газету на татарском языке. Против Ибрагимова за издание нескольких книг и экземпляров газеты преступного содержания по постановлению судебных властей было возбуждено уголовное преследование с положением ареста на означенные издания и он был присужден к содержанию в крепости на один год. Но, ликвидировав типографское дело, 11 апреля 1907 года Ибрагимов не отбыв наказания скрылся» (ЦГА РТ. Ф.41. Оп. 11. Д.1. Л.125.)

Дөньяга карашлар бәрелеше

Күргәнебезчә, Г.Ибраһим патша хөкүмәтенең дә, совет хакимиятенең дә төп дошманы булган, аңа «панисламист» һәм «пантюркист» дигән ярлык гомерлеккә тагылган, һәм ул, чыннан да, зур мәгънәдә исламчы һәм төркиче булган, аны беркайчан да яшермәгән. Әмма кайбер татар милләтчеләре аңа «авантюрист», «шарлатан» дигән ярлык та ябыштырмакчы булганнар, мөгаен, Габдрәшит хәзрәтнең дөньякүләм зур проектларга алынуы, җиңел генә дөньяның теләсә кай почмагына чыгып китүе, чит мәмләкәтләрнең патшалары, король-императорлары, принцлары белән бер дәрәҗәдә сөйләшә алуы, Төркия-Мисыр-Германия-Японияләрдә газета-журналлар чыгаруы аңа бераз гаҗәпләнеп һәм ышанмыйча карарга сәбәпче булгандыр...

Инде тагын узган гасырның утызынчы еллары азагына, Япониягә кайтыйк. Күргәнебезчә, Г.Исхакый белән Г.Ибраһимның ул чордагы каршылыгына өлешчә Габделхәй Корбангалиев та сәбәпче була. Әлбәттә, ул үзе барлыкка китергән, тоткан, оештырган ислам җәмгыятен, мәчет-мәктәбен, типографиянматбагасын Г.Исхакыйга бирергә җыенмый. Г.Исхакый аның өстеннән япон хөкүмәтенә шикаять язса да, бу илдә әле Г.Корбангалиевкә кагылмыйлар. Ул әле 1938 елга кадәр иркенләп Япониядә яши, Токиода Җәмигъ мәчете төзету артыннан йөри, мәчет җирен тагын үз исеменә теркәтә, чөнки ул вакытта ислам дине бу илдә рәсми рәвештә танылмаган була. Инде сиксәнгә җиткән Габдрәшит хәзрәт Япониядән читкә чыкмый, Токио мәчетендә дин сабаклары бирә, дәреслекләр яза, бу илдә ислам динен рәсми рәвештә таныттыру өчен япон сәясәтчеләре белән зур сөйләшүләр алып бара.

Ерак Көнчыгышта зур эшләр башкарып, яңа татар оешмалары төзеп һәм милли газета ачып, мөһаҗир татарлар арасында шактый каршылыклар чыгарып, Г.Исхакый 1936 елда Европага кайтып китә. Әмма аларның каршылыклары барыбер дәвам итә, матбугатта бу темага һаман мәкаләләр күренеп тора. «Яңа милли юл» журналының 1938 елгы 7 нче санында Г.Исхакыйның «Июль. 1938 ел.» мәкаләсе дөнья күрә, ул анда, җирле хәбәрчегә таянып, 12 майда Токиода мәчет ачылуын, «провокатор Корбангалиевнең японнар алдында йөзе ачылуын» яза. Ерак Шәрык мөхбире «Монда хәзер Корбангалиев йиренә Рәшит казыйны утыртырга теләү фикере йөридер. Японнардан да кайберәүләренең бу кешенең аксакалына хөрмәтән, шул фикерне алга сөрүләре сизеләдер», – дип хәбәр итә (Г.Исхакый. Әсәрләр. 12 том. – Казан, 2012, 274 б.)

Моңа каршы Г.Исхакый шунда ук үз фикерен белдерә, ул Япониядә Корбангалиев урынына Г.Ибраһимның мөселманнар лидеры булуына, аны Токио мәчете имамы итеп билгеләүгә кискен рәвештә каршы төшә. «Милли хаин Корбангалиев япон хаине сыйфаты берлә төрмәдә, – дип яза ул. – Инде шул ук төрмә мөһаҗирлеге фикеренә каршы, Совет хөкүмәтенең аҗанлыгында (шпион, агент. – **Ф.Б.**) булынган кызыл хаҗины михраб, мөнбәргә чыгарырга телиләрме? Без моңа ышанмыйбыз. Ләкин шундый бер хата тәкрарланачак булса, аның да нәтиҗәсе гайне булачагын алдан хәбәр бирү өчен бер дә пәйгамбәр булу лязем түгелдер. Шуңа башка мәсьәләнең тагы бер тарафы бардыр. Ул да – Рәшит казыйның коммунизм пропагандасы өчен Төркия тәбәгаленнән (гражданлык, ватандашлык) мәхрүм ителүедер. Мөһаҗир төрекләр, төрек тәбәгасе булмаса да, Төркия хөкүмәте, Төркия дәүләте тарафыннан нәфрәтле тамга басылган бер кешене һичбер вакыт үзләренең дин башлыклары итеп танымаячак. Төркия дәүләте дә, Төркия әфкяре гомумиясе дә үз иленнән куылган бер кешенең «дин башлыгы» ясалырга теләвен үзенә каршы дустлык диеп кабул итә алмаячактыр.» (Шунда ук, 274-275 бб.)

Без монда да Г.Исхакыйның тарихи хатасын төзәтергә мәҗбүрбез. Әйе, 1935 елның 8 августында Г.Ибраһим Төркия ватандашлыгыннан чыгарыла, әмма, Г.Исхакый язганча, «коммунизм пропагандасы» өчен түгел, ә «Төркия кануннарын бозганы өчен», ягъни Төркиядәге сәяси вәзгыятьне тәнкыйтьләгәне өчен чыгарыла. Токиодагы төрек хәрбиләренә җеназа намазы укымаганы өчен, Төркия ватандашлыгыннан чыгарылган дигән сүзләр дә йөри, имеш, ул аларга, «сез инде мөселман түгел», дигән. Ә Төркия ул вакытта Советлар иле белән дус мөнәсәбәттә була, Г.Ибраһим, киресенчә, бу дуслыкка зыян сала, аларның икесен дә тәнкыйтьли.

Бу мәкаләсендә дә Г.Исхакый Габдрәшит хәзрәтне «совет хөкүмәтенең аҗанлыгында булынган кызыл хаҗи» дип атый, ягъни берниндi дәлилсез, кешегә совет шпионы, агенты, дигән яла яга. Ул моны нәрсәгә таянып әйтә соң? Г.Ибраһимның, Г.Исхакый кебек, социалистик идеяләр белән мавыгып, 1915-1917 елларда Европада алар белән бергә конференцияләрдә булганы өченме? 1919 елда, Ленинга ышанып, Россиягә кайтуы, совет хакимияте татарга азатлык бирер дип өметләнүе, заманында үзе язган автономия проектын монда тормышка ашырырга тырышуы Г.Ибраһимны соңыннан совет шпионлыгында гаепләргә сәбәпче була аламы? Ул үзе дә бик тиз шушы кызыл-канлы режимның корбаны була бит, туган шәһәре Тарада төрмәгә эләгә, хөкем ителә, Аллаһ ярдәме белән генә исән калып, 1921 елда илдән чыгып кача. Шушы төрмәсе һәм хөкеме өчен, ул бу илдә рәсми рәвештә репрессия корбаннары исемлегенә кертелгән, 2008 елның 28 февралендә Омск өлкәсе прокуратурасы тарафыннан Г.Ибраһим тулысынча аклана, исеме өлкәнең Хәтер китабына кертелә.

Шул ук вакытта совет органнары Г.Ибраһимны Төркия, Германия, Япония шпионы дип атый, аны чит илдән торып, татарларны бәйсезлеккә котыртып ятуда гаепли. 1937 елда Омск өлкәсендә «Милли Шура» дип аталган «контрреволюцион» оешмага каршы эш ачыла, шушы гаепләү белән, 40 татарны атып үтерәләр, сигезен унар елга хөкем итәләр. Менә шушы гаепләү карарында Г.Ибраһимовның да исеме төп котыртучы, совет дошманы буларак телгә алына:

«Одновременно через приезжавшего из Германии Ибрагимова Абдрашита при участии муллы Шугурова Шакира и купца Айтыкина Махмут-Рефата контрревоюционная организация установила связь с руководителями Аллаш-арды Турулбаевым Айдерханом и Абдрахимовым Султаном и уфимским центром, возглавляемым Таржимановым Кашафутдином и Фахрутдиновым Резеитдином. …Через находящегося в Турции Ибрагимова Абдрашита устанавливается связь с Харбинским белоэмигрантским татарским центром и через муллу Саитова Наби поддерживает связь с уфимским центром «Милли Шуро», и через него же установила связь с офицерско-повстанческой организацией в Омской области» (Тарское Прииртышье и проблемы сохранения историко-культурного наследия малого исторического города России. – Тара, 2006, стр.75.)

(Дәвамы киләсе санда).

Фәүзия БӘЙРӘМОВА.

УКЫТУЧЫ белән укучы дуслыгы

1980 еллардагы район газетасы төпләнмәләрен актарып утырганда «Укытучыма» исемле шигырьгә күз төште. Авторы – моннан өч ел элек арабыздан вакытсыз китеп барган, олы йөрәкле, талантлы якташыбыз Шәһинур Әхмәтсафа булып чыкты:

Мин гөлләрнең
Күңелегез кебек иң нурлысын,
Сезгә бирер идем.
Шигырьләрнең, сүзләрегез кебек
Иң җылысын
Сезгә бирер идем,
Укытучым минем!..

1959 елда Урта Кирмән урта мәктәбенә, Алабуга дәүләт педагогика институтын тәмамлап, ике яшь кыз – Фәридә Шәрипова һәм Әнисә Кәримова эшкә килә. Энергияләре ташып тора: укыталар да, халыкны агарту эшенә һәм күрше авыл сәхнәләрендә концерт-спектакльләр куярга да өлгерәләр. Алтынчы сыйныфта укучы Ш.Мостафинның югарыда телгә алган шигыре шул кызларның берсе – Әнисә Касыйм кызына багышлап язылган да инде. Әнисә ханым бу класста рус әдәбияты, алман теле укыта, әдәби геройлар аша яшүсмернең күңелен яулап ала. Үзе дә иҗади кеше булган Әнисә малайның иҗатка омтылганын күреп ала, аңа һәрьяклап ярдәм итәргә омтыла. Инде ир уртасы һәм олпат язучы булып җитешкәч тә Шәһинур үзенең укытучысын зур хөрмәт белән, иҗатының чишмә башында торучы итеп искә ала иде. Мәктәптә башланган, үзара хөрмәткә корылган дуслыклары гомерләре буе сузылды.

Безнең мәктәп музеенда Әнисә Кәримованың шәхси архивыннан бер өлеш саклана. Бернича папкадан торган бу архивны безгә вафатыннан соң укытучының кызы Энже тапшырды. Урта Кирмәннән соң Әнисә Касыйм кызы үз туган ягында – Әгерҗе районының Тирсә авылына кайтып укыта. Ләкин кайда гына эшләсә дә, ара еракலыгы алар дуслыгы югалуга сәбәп була алмаган. Архивтан күренгәнчә, Әнисә Касыйм кызы укучысының иҗатын һәрдаим күзәтеп, аның матбугат битләрендә басылган язмаларын аерым ватман битләренә ябыштырып җыеп барган. Кайберләрен автор үз автографы белән укытучысына җибәрә торган булган.

Бер генә бәйрәм дә игътибардан читтә калмаган. Гади генә календарьны да зур итеп, шигырь юлларына салынган матур теләкләр белән бүләк итә Ш.Мостафин:

Гөлгә, шигърияткә гашыйк җан Сез,
Күңелегез тулы – яхшылык!
Сезнең белән аралашкан саен,
Күз аллары китә яктырып...

Язучы әлеге сүзләр белән остазын 1996 ел белән котлаган. Аннан алдарак язган бер хатында «Сез беренче илһам чаткысы – Гомер буе бара яктысы», дигән юллар да бар.

Казан дәүләт университетының 19 яшьлек студенты Ш.Мостафин 8 нче мартка мөгаллимәне яңа шигырен җибәреп сөендергән:

Язлар килә тагын җир өстенә,
Язлар килә, килә ярсынып...
Әй син, гомер язы, нигә шулай
Тиз китәсең икән ашыгып?!.

Ничек кенә булмасын, һәр кешенең «менә ул чын укытучы» диярлек остазы бар. Ул аны еллар үткән саен сагынып искә ала, гомер буе аңа рәхмәт укый. «Мин сезнең алдыгызда түбәнчелек белән баш ияр идем», дигән рус шагыйре Н.А.Некрасов. Шәһинур да укытучысын зурлау өчен нинди генә сүзләр тапмаган!

Күрәсезме, әнә,
Ап-ак карлар ява урамда.
Юк ла,
Җиргә ап-ак бәхет ява –
Сөенәмен:
Туар көннәр шулай
Ап-ак бәхет булып урала.
Туар көннәр Сезгә, укытучым,
Бәхет, шатлык, кайнар хис бирер.
Кыенлыклар аша, Данко кебек,
Җиңеп чыгар өчен көч бирер.

Мондый котлау алган укытучының нинди хисләр кичерүен күз алдына китерү дә кыен түгел. Тормышта укытучысын зурлаган укучы үзен дә зурлавын аңлап та бетермидер әле. Укучысының күргән хөрмәтне укытучы башкаларга сөйли, шатлыкны уртаклашмыйча буламыни? Яхшы гамәлең башкаларга да тарала.

Әнә шундый котлау-хатларны бик күп алган Әнисә Касыйм кызы. Аларның һәркайсы «Кадерле укытучым», «Хөрмәтле остазым», дип башлана. Һәркайсының эчтәлеге бер-берсен кабатламый, һәркайсы аерым шәхескә багышланган сыман.

Чәчәкләрнең, укытучы күңеле кебек,
иң нурлысын,
Сезгә бирер идем – котлап
бәйрәм көнен.
Рәхмәтләрнең укытучы күңеле кебек,
иң олысын
Сезгә дияр идем, Укытучым минем!

Инде гаилә коргач та укытучысы белән Шәһинурның аралары суынмый. Хатлар гаилә исеменнән языла башлый. Җае чыккан саен, Әнисә Касыйм кызының өендә булырга вакыт табылган. Укытучының юбилей кичәләре алардан башка узмаган.

1967 елда Татарстан китап нәшриятында «Иркен минем Туган илем» исемле альманах басылып чыга. Анда яшь шагыйрь, КДУның икенче курс студенты Ш.Мостафинның да бернича шигыре дөнья күрә. Әлеге җыентык та Әнисә Касыйм кызының архивында урын алган. Китапчыкның тулы хокуклы авторларының берсе буларак, яшь Шәһинур аңа мондый истәлек язган: «Кадерле укытучым Әнисә Касыймовнага укучысы Шәһинурдан бер истәлек. Бу – күңелләрдән очып чыккан беренче карлыгач кына әле. Беренче карлыгач артыннан башкалары да кайта. Аларын да бергә каршыларга насыйп булсын. Зур ихтирамым билгесе итеп кабул итегез».

Вакыт үзенекен итә. Әлеге истәлекхатлар шактый таушалган, саргайган. Ләкин алардагы ихласлыкны, күңел җылылыгын, укучының үз укытучысына булган олы хөрмәтен бернинди вакыт та юкка чыгара алмый. Бүгенге буын укучы-укытучыларына үрнәк итеп куярлык өлге бу. Шундый күренешләргә дә очраган бар: укучы шәп булып чыкса – үзем тырыштым, ди, начар булып чыкса – укытучым начар булды, ди. Машинасын туктатып, укытучысы белән пыялаңы төшереп кенә сөйләшкәннәрне дә күргәнем бар. Аларга Шәһинур хатларын укытырга иде...

Мин искә алган Әнисә Касыйм кызы да, Ш.Мостафин да мәрхүм инде. Берсе – балалар күңеленә изгелек орлыклары салып, гомерен кеше шәхесе формалаштыруга багышлаган, икенчесе – укытучысыннан алган изгелекне гомере буе кайтарырга омтылып яшәгән бу ике изге җан һаман истән чыкмый.

Ринат ХӘЙРУЛЛИН,
Мамадыш районы
Урта Кирмән урта мәктәбенең
тарих укытучысы.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

10 июнь (шимбә). ***Зөлкагдә аеның 21 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 1.27 сәгатьтә калка, 11.10 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.25 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Ай һәм дару үләннәре (1)

Дару үләннәре сихәт бирсен өчен, аларны билгеле бер көннәрдә генә җыю файдалы. Айның 9, 15, 23, 29 нчы көннәрендә үлән җыярга да, сихәтле төнәтмәләр ясарга да ярамый. 3,7, 12, 16, 24 нче Ай көннәрендә дару үләннәрен җыю уңышлы. Дарулы төнәтмә һәм сыгынтыларны Айның 5, 8, 12, 13, 16, 17, 24, 28 нче көннәрендә әзерләү яхшы. Ә дару үләннәрен җыю өчен иң шәп вакыт – 8-15 август.

11 июнь (якшәмбе). ***Зөлкагдә аеның 22нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 1.36 сәгатьтә калка, 12.44 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.26 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Ай һәм дару үләннәре (2)

Дару үләннәренең тамырын кими баручы Ай Кәҗәмөгез, Кыз, Үгезбозау йолдызлыгында чакта иртә язда яки көзен Кояш чыкканчы яки баегач җыю файдалы. Чәчәкле өлешен үсә баручы һәм тулган Ай Игезәкләр, Үлчәү яки Сукояр йолдызлыгында чакта кояшлы көннәрдә көндез, чык тамчылары парга әйләнеп беткәч җыю яхшы. Чәчәк таҗларын үсә баручы Ай Кысла, Чаян, Балыклар йолдызлыгында чакта, чык кибеп беткән мәлдә җыю нәтиҗәле. Дару үләннәренең җимеш яки орлыкларын тиз арада куллану өчен кирәк булганда үсә баручы Ай Кучкар, Арыслан, Укчы йолдызлыкларында чакта, озак саклау өчен исә кими баручы Ай Кучкар һәм Укчы йолдызлыкларында чакта кичке якта, әмма Кояш батканчы җыярга киңәш ителә. Сабак һәм яфракларны үсә баручы Айда җыю яхшы.

12 июнь (дүшәмбе). ***Зөлкагдә аеның 23 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 1.44 сәгатьтә калка, 14.14 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.28 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Ромашка шифасы

4 өлеш дару ромашкасы чәчәге, 1 әр өлеш каен бөресе һәм җитен орлыгын кушып, шуның 2 аш кашыгын ярты литр суга салалар, сүрән утта 10 минут пешерәләр, сөзеп, җылы килеш баш тиресенә ышкыйлар (чәч юылган булырга тиеш), полиэтилен башлык киеп, 20-30 минут торалар, аннан соң чәчне юмыйча киптерәләр. Атнасына 2-3 тапкыр шулай дәвалану чәч коелудан саклый.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

13 июнь (сишәмбе). ***Зөлкагдә аеның 24нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 1.53 сәгатьтә калка, 15.45 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.29 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Лимон һәм суган сихәте

4 лимонның кабыгын 1 литр суда 15 минут пешерәләр дә, кавыклы чәчне атнасына 1 тапкыр шул су белән чайкыйлар. Яки суганны боламык ясап изеп, баш тиресенә сөртәләр, полиэтилен башлык киеп, өстеннән сөлге урыйлар. 2 сәгатьтән соң шампунь белән юалар.

14 июнь (чәршәмбе). ***Зөлкагдә аеның 25 нче көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 2.04 сәгатьтә калка, 17.13 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.31 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Карабодайлы кефир

Ашказаны асты бизе авыртып интектергәндә, карабодай ярмасын каһвәтарткычта тарттыралар, шуның 1 яки 2 аш кашыгын 1 стакан майсыз кефир яки эремчек суына салып, төнгелеккә калдыралар. Иртәнге аш урынына ашыйлар.

15 июнь (пәнҗешәмбе). ***Зөлкагдә аеның 26 нчы көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 2.10 сәгатьтә калка, 18.43 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.31 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Көзән җыерганда

Төннәрен аяк балтырларын көзән җыерса, калийга бай ризыкларны күбрәк ашарга кирәк. Йөзем, курагә, инҗир, әстерхан чикләвеген иттарткычтан чыгарып, бал кушалар да, 2 атна буе, көненә 2 тапкыр, ашарга ярты сәгать кала, 1әр аш кашыгы кабалар.

16 июнь (җомга). ***Зөлкагдә аеның 27 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 2.40 сәгатьтә калка,20.10 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.32 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аерuча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

Алмалы коймак

Ярты литр кефирга 2 аш кашыгы манный, бераз шикәр салып, 10 минут тоталар. Аннары 1 йомырка, ярты стаканга якын он, вак шакмаклап туралган 1 алма, сода, тоз өстәп, камыр туглыйлар һәм майлы табада гадәти коймактай пешерәләр.

Әһли бәйт

Әһли бәйт бер йортта яшәүче гаилә әгъзалары дигән сүз. Пәйгамбәр Әфәндебезнең барлык гаилә әгъзаларын белдерә. Бу мәгънәдә «әһли бәйт» – Рәсүл Әкрәм Әфәндебез һәм Аның гаиләсе, Гали, Җәгъфәр, Гакыйль, Габбас һәм аларның гаиләләре дигән сүз. Рәсүлуллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә сәлам-салават әйтү бөтен мөселманнар өчен ваҗиб булган кебек, әһли бәйткә хөрмәт һәм мәхәббәтле мөнәсәбәттә булу да барча мөселманнарның вазыйфасы санала.

Аллаһ Рәсүленең әһли бәйтенә зәкят алу хәрәм. Пәйгамбәр Әфәндебез галәйһис-салатү вәссәләм бер көнне хәзрәти Хәсәннең дәүләт казнасына зәкят итеп бирелгән хөрмәнең бер данәсен авызына капканын күреп ала. Ул шундук хөрмәне авыздан чыгарырга куша һәм:

«Мөхәммәд гаиләсенең зәкят ашамаганын белмисеңмени?» – дип кисәтә.

Зәйд ибне Әркам радыйаллаһу анһе болай дип сөйли: «Бер көнне Рәсүлуллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм, Мәккә белән Мәдинә арасындагы Хум чишмәсе янында басып, безгә нотык тотты. Аллаһка хәмедсәнәләр әйткәч, безгә үгет-нәсыйхәт кылды. Аннары болай дип мөрәҗәгать итте:

«Әй кешеләр! Мин дә бер кеше. Якын арада Раббымның илчесе миңа да киләчәк һәм мин аның чакыруына буйсынып, китеп барачакмын. Сезгә ике мөһим нәрсә калдырам. Берсе – кешене дөреслеккә алып бара торган юламан һәм нур булган Аллаһ Китабы – Коръән. Аңа ябышыгыз һәм бик ныклап тотыныгыз!..»

Шулай итеп, хәзрәти Пәйгамбәр галәйһис-салатү вәссәләм Коръәни-Кәримгә тотынырга, аңа ябышырга кушты. Аннары сүзен болай дип дәвам итте:

«Сезгә шулай ук әһли бәйтемне калдырам. Аллаһтан куркыгыз һәм әһли бәйтемә хөрмәт белән карагыз. Аллаһтан куркыгыз һәм әһли бәйтемә хөрмәт белән карагыз!»

«Пәйгамбәрнең әһли бәйте кем инде ул, әй Зәйд!? Хатыннары да әһли бәйтеннән саналмыймыни?» – дип сорагач, Зәйд: «Хатыннары да Аның әһли бәйтеннән. Фәкать Аның чын әһли бәйте – үзеннән соң да сәдака алу хәрәм саналганнары», – ди. «Сәдака алу кемнәргә хәрәм кылынды?» – дип сорыйлар. «Гали, Гакыйль, Җәгъфәр һәм Габбасның гаиләләренә», – дип ачыклый.

Рәсүлуллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә:

«Аллаһны нигъмәтләре белән ризыкландырган өчен яратыгыз. Мине исә Аллаһны ятратканга күрә сөегез. Әһли бәйтемне исә мине яраткан өчен яратыгыз.»

Бер көнне Пәйгамбәр Әфәндебез, мөбарәк оныклары Хәсән белән Хөсәеннең кулларыннан тотып, халыкка болай дип белдерә:

«Кем мине, бу икәүне, боларның этиләрен һәм аниләрен сөйсә, кыямәт көнендә минем белән бергә булыр» (Тирмизи, «Мәнакыйб», 20/3733).

Әсхәбе кирам Рәсүлуллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең якыннарына карата бик зур хөрмәт һәм мәхәббәт саклый. Чөнки гашыйк зат сөйгәненә карата мәхәббәте аша аның дусларын, хезмәтчеләрен, ашаган ризыкларын, кигән киемнәрен, кыскасы, аның белән бәйле һәм аны хәтерләткән һәрнәрсәне сөяр. Мәхәббәте көчәйгән саен, сөю хисләрен сөйгәне тирәсендәге һәрнәрсәгә күчерер.

Аллаһ Рәсүлен җаннарыннан да ныграк яратучы, сайлап алынган сәхабәләрнең Аллаһ Рәсүленә якын торган берсе, Ул атына-дөясенә менәргә җыенганда, шундук өзәңгедән тота торган була. Кыямәт көнне бөтен туганлык бәйләнешләре өзелеп, бары Аның белән бәйләнешле гына сакланып калачагын белгәнгә, хәзрәти Пәйгамбәрнең якыннарыннан берәрсе белән өйләнешеп, Рәсүлуллаһ белән туганлык элемтәсе кору мөмкинлеген чын күңелдән телиләр.

Аллаһ Рәсүленең пакь нәселеннән килгән кешеләр хәзерге заманда ислам дөньясының төрле почмакларында яши. Хөсәен радыйаллаһу анһе нәселеннән килүчеләрне «Сәйийд», Хәсән радыйаллаһу анһе нәселен дәвам итүчеләрне «Шәриф» дип атыйлар. Төрекләр сәйийдләрне «әмир», башларына чорнаган яшел чалманы «әмир чалмасы» дип йөртә. Рәсүлуллаһ нәселеннән булган хатын-кызлар да яшел баш киеме киеп йөриләр.

Төрекләр әһли бәйткә хезмәт итүне кыйммәтле бер вазыйфа дип саный һәм моның өчен рәсми бер оешма булдыра. Госманлы дәүләтендә әһли бәйт эшләре белән мәшгуль ошбу рәсми хезмәткәрләрне «Накибүл-әшраф» дип атыйлар. Накибүл-әшраф Пәйгамбәр Әфәндебез нәселеннән сайлап куела һәм алар әһли бәйтнең төрле эшләрен башкара: аларга тиешле нәрсәләрне терки, туу һәм үлем турында мәгълүматларны язып бара, аларның очраклы һөнәр белән шөгыльләнә башлауларына каршы тора, хатын-кызларның үзләренә тиң булмаган ир-атларга кияүгә чыгуын тыя.

Накибүл-әшраф Пәйгамбәр нәселенең гомуми бер опекуны булып, башкарган вазыйфасы бәрабәренә иң югары дәрәҗәдәге оешмалардан санала һәм рәсми мәрасимнәрдә хәлифәдән соң икенче рәттә урын ала. Падишаһлар тәхеткә утырганда, иң элек хөкемдарга Накибүл-әшраф ант итеп дога кыла, аннары башка даирәләр ант китерә. Бәйрәм белән тәбрикләгәндә дә, Накибүл-әшраф беренче булу хокукына ия. Һәр ике очракта да падишаһ Накибүл-әшрафка хөрмәт йөзеннән, аягүрә басып тыңлый.

Сәйийд һәм шәрифләр канунга һәм гадәт-йолаларга каршы килә торган гамәл кылса, Истанбулдагылар Накибүл-әшраф, төбәкләрдәгеләр исә җирле идарә рәисләре тарафыннан җәзага тартыла. Җәзалау вакытында әүвәл яшел чалманы алып үбәләр, җәза процедурасы тәмамлангач, аны кире кайтаралар.

Хәдисләр

● ***Кол ялган сөйләүне һәм ялган сөйләү ниятен йөртүне дәвам иткәндә, йөрәгендә кара нокта ясалыр. Соңыннан бу нокта зураер һәм йөрәк тәмам кап-карага әйләнер. Бу зат ахырда Аллаһ каршында «ялганчылар» арасына кертелер.***

● ***Берәрегез берәр төрле яманлык күрсә, аны кулы белән төзәтсен. Көче җитәрлек булмаса, теле белән төзәтсен. Моңа да көче җитмәсә, күңеле белән нәфрәтләнсен! Бу исә – иманның иң зәгыйфь хәле.***

● ***Аллаһ белән ант итәм, Җәнабел-Хакнең синең аркылы бер кешене булса да һидаяткә ирештерүе (иң кыйммәтле дөнья нигъмәте саналган) кызыл дөяләр хуҗасы булуыңнан хәерлерәк.***

● ***Бездән бер нәрсә ишетеп, аны шул ук рәвештә башкаларга тапшыручы затның йөзен Аллаһ ак кылсын! Үзенә белем, хәбәр җиткерелгән күпме бәндәләр бар ки, ул белемне аны ишеттерүчедән дә яхшырак аңлар һәм кулланыр.***

● ***Миңа әүвәлге пәйгамбәрләрдән берсенә дә бирелмәгән биш үзенчәлек бирелде:***

1. Бер айлык юл ераклыгында дошман йөрәгенә курку салу белән ярдәм алдым.

2. Миңа җир йөзе пакь итеп, мәчет кылынды. Шунлыктан өммәтемнән һәрбер мөэмин, намаз вакыты җиткәч, шул булган җирдә намазын укысын!

3. Миннән әүвәлге һичбер пәйгамбәргә хәләл кылынмаган ганимәт миңа хәләл ителде.

4. Шәфәгатькә рөхсәт бирелде.

5. Миннән әүвәлге пәйгамбәрләр бары аерым халыкларга җибәрелә иде. Мин исә бөтен кешелеккә пәйгамбәр итеп җибәрелдем.

● ***Сез мине хакымнан артык булган дәрәҗәгә күтәрмәгез! Чөнки Аллаһ Тәгалә мине рәсүл итеп җибәргәнче башта кол итеп яралткан иде.***

● ***Һидаяткә өндәүче затка үзенә иярүчеләрнең савабы кадәр савап бирелер. Бу аларның савапларыннан һичкадәр киметмәс.***

Халык фикере, имеш



Сүзем Казанда салыначак Җәмигъ мәчетенә багышланган. Былтыр Идел буе Болгарында ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышлап уздырылган чараларга төрле җирләрдән күп санлы кунаклар килгән иде. Казанда Җәмигъ мәчете салынасы урында, Казансу елгасы буенда Россия хөкүмәте җитәкчесенең урынбасары – якташыбыз Марат Хөснуллин һәм килгән кунаклар катнашында уздырылган җыелышта, мәчет нигезенең беренче ташын салу тантанасы билгеләп үтелгән иде. Мәчетнең төзелеш эшләре көз көне башланачак дигән сүз әйтелде. Бер ел вакыт узып китсә дә, төзелеш эшләре башланмаганлыгын күреп торабыз.

Гадәттәгечә, милләтебезгә багышлап берәр нәрсә эшлисе булса, төрле мәкерлекләр, каршылык күрсәтүләр башланып китә. Хәзер Казанның Җәмигъ мәчетен төзү өчен узәктән читтәрәк урыннар тәкъдим ителә икән. Ул Казанның иң зур данлыклы мәчете булгач, аның урыны да шәһәр читендә була алмый бит инде. Күз күрке җирдәге «Акчарлак» ресторанын сүткән урын 15 елдан бирле койма белән әйләндереп алынган көйгә тора. Мисал өчен, бу урында яки Октябрь шәһәрчегендә бушаган урында мәчет салырга рөхсәт бирелсә, монда да шул ук кешеләрнең, имзалар җыеп, каршылык күрсәтә башлаячаклар икәне билгеле. Алар шуның өчен кулгалан кешеләр, кемнәр икәнлеге дә билгеле, югыйсә. Казанда чиркәүләр салганда, андый вызгыш чыгарып йөрүчеләр булганын хәтерләмим.

«Халык фикере» дигән сүз ул кемнәрнеңдер үзләренә кирәк проблемаларны чишү өчен генә кулланыла дип аңларга кирәктер. Милләтара вызгыш чыгарырга тырышкан берничә шомлы кешенең фикере халык фикере була алмый. Менә без, татар халкы, 2017 елда башланып киткән, мәктәпләрдә балаларга ана телендә укуларны тыю белән килешә алмыйча, үзебезнең фикерләребезне әйтеп төрле югарылыклардагы җитәкчеләргә кабат-кабат мөрәҗәгать итүләр, исәбе-хисабы булмаган бу турыда язылган мәкаләләрдәге халык фикерен нишләп үтәмиләр икән, алай булгач? Референдумда күпчелек тавыш белән җиңү яулаган һәм Конституциядә язылган хокукларыбызның үтәлүе ни өчен тыелды икән? Гадел булмаган, «халык фикере» дип яшерелгән мәкерле гамәлләрдән арынып яшәүләр насыйп булсын иде.

Рәфкать ИБРАҺИМ.



Капка – авыл бизәге



Татар авылының бизәге булган, агачтан уеп ясалган тәрәзә йөзлекләре, бизәкле агач капкалар тарихта гына калып бара. Заман белән бергә авылның да йөзе үзгәрә – тәрәзә йөзлекләре хәзер калайдан, капкалар тимердән ясала. Шулай да авылларда башка йортлардан аерылып, агачның бөтен матурлыгын күрсәтеп торган йорт-капкалар да очрап куя. Шундыйларның берсен Әтнә районының Олы Мәңгәр авылы аша узып барганда очраттык. Искиткеч нәфис, таш белән агачны аралаштырып эшләнгән капка һәм йортның хуҗасы белән дә танышып чыктык. Бу матурлыкны Ринат Ибраһимов үз куллары белән тудырган. Ринат ага 1973 елны бәхет эзләп Төрекмәнстан якларына китеп бара. Шунда балалары туа, озак еллар ерак араларга йөрүче шофер булып эшли, ком чүлләрен аркылыга-буйга иңли. Анда җирле халык белән дус булып бик әйбәт яшиләр, тик туган яклар сагындыра – ике КамАЗга төялеп, 1995 елда Олы Мәңгәргә кайтып төшәләр. Ком-таш арасында яшәгәндә, аны агач эше бигрәк тә сагындыра. Туган якка кайткач, рәхәтләнеп эшкә чума. Йортны да, капканы да үз куллары белән төзи. Ташны карьердан үзе ташый, кирәгенчә кисә. Алар мал-туар асрап яши, ике сыер, берничә үгезләре бар. Урта́нчы улы авылда баш ветеринария табибе, олы улы һәм кызы Казанда эшлиләр. Хатыны Гөлфия ханым гомере буе шәфкать туташы булып хезмәт куя. Ринат ага авыл тарихын бик яхшы белә, кайчандыр бу авылда яшәгән күренекле байлар, муллалар турында сәгатьләр буе сөйли ала. Без кергәндә исә ул тагын нидер ясап ята иде. Баксаң, күз явын алырлык матур капкасын сүтеп, яңартырга җыенуы икән, башында яңа идея туган. «Монысын сүтәргә кызганыч түгелме?» – дигән сорауга ул: «Тагын да матурын ясыйм», – дип җавап бирде.

Эльмира СИРАҖИ.
Автор фотолары.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

9 июнь – «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» (М.Галәү).
10 июнь – Әнкара шәһәреннән Төркия дәүләт театрының «Мәңгелек» китап кибете» спектакле (С.Аксал).
10 июнь – Шәрык клубында 15.00 – «Бичара кыз...» (Г.Ильяси). 18.00 – К.Иванов исемендәге Чуаш дәүләт театрының «Мин сүнсәм дә, син ян!» спектакле (М.Сунтал).
11 июнь – «ЕТ CETERA» Мәскәү театрының «Лица» спектакле (А.Чехов).
12 июнь – «ЕТ CETERA» Мәскәү театрының «Сердце не камень» спектакле (А.Островский).
13 июнь – «ЕТ CETERA» Мәскәү театрының «Стакан воды» спектакле (Э.Скриб).
14 июнь – «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин).
15 июнь – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
16 июнь – «Сагынырсызмы?» (А.Шәйдуллин).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

9, 10 июнь – «Севильский цирюльник» (Дж.Россини).
14 июнь – «Шүрәле» (Ф.Яруллин).
15, 16 июнь – Казан хореография училищесы укучыларының концерты.

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

9 июнь – «Идегәй» (халык дастанына нигезләнгән).
10 июнь – Владикавказ шәһәреннән В.Тхапсаев исемендәге Төньяк Осетия дәүләт академия театрының «Ричард III» спектакле (У.Шекспир).
11 июнь – Әлмәт татар дәүләт драма театрының «Ул әле өйләнмәгән иде» спектакле (Г.Исхакый).
13 июнь – «Полиционер» (И.Зәйниев).
14 июнь – «Беренче мәхәббәт» (И.Гали).
15 июнь – 10.00 – «Тинчуринда кунакта» квесты. 18.30 – «Аферист» (Н.Исәнбәт).
16 июнь – «Кияүләр» (Х.Вахит).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

9 июнь – «Йосыф» (Кол Гали).
10 июнь – Түбән Кама татар дәүләт драма театрының «Аксак» спектакле.
11 июнь – 13.00 – «Кәҗүл читек» (Г.Исхакый). 18.00 – «Ак чәчәкләр кебек...» (Р.Мухина).
13 июнь – «Гөлчәчәк» (татар халык әкиятенә нигезләнгән).
14 июнь – «Яралу» перформансы (идея авторы һәм хореографы Е.Музеева).
15 июнь – «Супер кияү» (Т.Миңнуллин).
16 июнь – «Мәхәббәт күгәрченнәре» (В.Гуркин).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

9 июнь – 12.00 – «Три солнца». 18.30 – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).
10 июнь – зур залда – «Маугли» (Р.Киплинг). Кече залда – «И, кызык Шүрәле!..» (Г.Зәйнашева).
11 июнь – зур залда – «Волк и семеро козлят» (Э.Гыйлемханова инсценировкасы). Кече залда – «Серая шейка» (Д.Мамин-Сибиряк әкиятенә нигезләнгән).
12 июнь – Фойеда – «Приключения пингвиненка Пинка» (А.Галиуллина). Зур залда – «Буратино» (А.Толстой).
14 июнь – «Буратино» (А.Толстой).
15 июнь – «Али-баба и сорок разбойников» (В.Смехов).
16 июнь – 11.00 – «Али-баба и сорок разбойников» (В.Смехов). 19.00 – «Авиатор» (Е.Водолазкин).

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

10 июнь – С.Рахманинов исемендәге «Ак сирин» XII халыкара фестивале кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт симфоник оркестры концерты. Дирижер – Ян Латам-Кениг. Солист – Анна Цыбулева.
14 июнь – Неоклассика. «Игра престолов» симфониясе.

Сталинның эш хакы

Иосиф Сталинның эш хакы төрле булган. Мәсәлән, 1936 елда ул аена 1200 сум, 1952 елда 10 мең сум алган, бу вакытта илдә уртача хезмәт хакы 600-700 сум булган. Кызы Светлана Аллилуева истәлекләреннән күренгәнчә, җитәкченең эш хакын, конвертка салып, ай саен өстәленә куйганнар, ул исә, санап та тормыйча, акчаны өстәл тартмасына салган. Сорагач кына, күпме кирәк, шулкадәр биргән. Ә 1980 елда Леонид Брежневның айлык хезмәт хакы 800 сум булган, бу чорда халыкның уртача эш хакы 170 сумнан артмаган.

(“Караван историй”).

Алынма сүзләр тыела

Италиядә рәсми хәбәрләрдә алынма инглиз сүзләрен куллануны тыярга җыеналар, әлеге фәрманны бозучыларга 5 меңнән алып 100 мең еврога кадәр штраф салынырга мөмкин. Мондый терминнарга, мәсәлән, киң таралган “дедлайн”, ”хэштег” һәм “брифинг” сүзләре керә. Инглизчә “диспенсер” сүзе урынына Рим түрәләргә “dispensatore di liquido igienizzante per le mani” гыйбарәсен кулланырга куша. Яңа закон буенча, итальянча “bru-sketta” урынына инглизчә “bru-shetta” дип әйткән өчен дә җәза биреләчәк һ.б. Лингвистлар әйтүенчә, хәзерге итальян телендә 800 меңнән артык сүз бар, шуның 9 меңе – инглиз теленнән кергән алынмалар. Белгечләр исәпләвенчә, 2000 елдан бирле Италиядә инглиз телен куллану 773 процентка арткан. Ә бездә, РФ Дәүләт Думасы инглиз теленнән кергән сүзләргә каршы көрәшергә өндәгәч, шау-шу купкан иде – янәсе, “хайп”, “фейк”, “коворкинг” ише алынмаларны кулланмыйча ничек яшәрбез соң? Россия законы исә түрә һәм гражданнарны рәсми документларда әдәби рус теле нормаларын сакларга гына өнди. Хөкүмәттә рус теле буенча комиссия төзеләчәк, законның үтәлүе ул төзегән сүзлекләр һәм белешмәлекләр исемлеге буенча контрольдә тотылачак. Штраф түләтергә җыенмыйлар да. Сүз уңаеннан, итальян законнары бөтен чит телләрдән кергән алынма сүзләрне куллануны чикли, әмма “англомания”дән котылу өчен махсус берничә пункт өстәгәннәр, яңа канунны премьер-министр Джорджия Мелони партиясе хуплаган.

(“Dzen.ru”).

Ямаулыгы үзендә

Танылган актер Джеки Чанның гомерен һәм сәламәтлеген имиништләштерергә җөрьәт иткән теләсә кайсы компания күптән банкротлыкка чыгар иде инде. Бу гаҗәп тә түгел – үз карьерасында Джеки 3 мең тапкыр имгәнгән һәм җәрәхәтләнгән. Кино төшерү мәйданчыгында беренче тапкыр ул 19 яшендә, 1973 елда имгәнгән – Брюс Ли ялгыш агач таяк белән яшь актерның күзенә бәргән. Бәхеткә, Джеки сукырайммаган.1978 елда Чан кулы белән кылычка тотынган. Тик ни өчендер анда бутафор кылычы урынына чын үткен корал булып чыккан, ургылып кан ага башлаган, режиссер исә, сценарий буенча шулай булырга тиештер, дип, төшерүен дәвам иткән. Шул ук 1978 елда Джеки уңышсыз егылган һәм күзенә зыян китергән, хәтта операция ясатырга туры килгән. 1983 елда актер, 8 метр биеклектән егылып, 5 кабыргасын, борынын сындырган, муенын имгәткән. 1985 елда бишенче кат биеклегеннән егылып, Джеки 2 умырткасын сындырган, оча сөяген имгәткән. Аны гарип булып калыр, дип фаразлаганнар, тик 2 ай хастаханәдә яткач, актер кабат яраткан эшенә кайткан. 1986 елда Чан 6 метр биеклектән башы белән җиргә килеп төшкән, нәтиҗәдә баш сөяге чатнаган, миенә кан сауган. Башына пластина кертеп теккәннәр, сул колагы ишетми башлаган. 1993 елда Джеки ике автомобиль арасында кысылып калган, аяклары сынып, өч айны хастаханәдә үткәрергә туры килгән. Әмма актер, дәваланып чыгуга ук, шушы трюкны кабатлаган, бу юлы бер җирен дә имгәтмәгән. 1995 елда тубык сөяген һәм аяк бармакларын сындыргач, гипс өстеннән кроссовка кебек буялган оекбаш киеп, фильмда төшүен дәвам иткән. 2005 елда Чан, кинога төшкәндә аттан егылып, аркасын имгәткән, тагын бер эпизодта штык белән учын үтәли тишкәннәр. Экстремал актерның гомеренә бик еш куркыныч янаса да, ул тик утырырга җыенмый: 7 апрельдә 69 яшен тутырган Джеки Чан, һаман кинога төшүдән тыш, хәйриячелек белән дә шөгыльләнә, җырлар яздырып, дисклар чыгарырга да өлгерә.

(“I-fakt.ru”).

● «Россия» фирма поезды Мәскәү-Владивосток маршруты буенча йөри.

● Европа-Кытай Яңа Ефәк юлы.

● Испаниядән Кытайга бара торган поезд 13 052 км араны (экватор озынлыгының өчтән берен!) 21 көндә үтә.

● Трансавстралия тимер юлы.

● Hyperloop иң тизйөрешле поезды капсуласы.

Тимер юл хикмәтләре

Дөньяда иң озын һәм авыр товар поезды Көньяк Африка Республикасында йөри – ул 7,3 километр озынлыкта һәм 69400 тонна авырлыкта. Ә иң озын пассажир поезды АКШта, 250 вагонлы составның гомуми авырлыгы 15500 тоннадан артып китә. 1981 елда Франциядә Париждан Лионга сәгатенә 260 чакрым тизлек белән йөри торган поезд җибәрелгән, 1990 елда инде ул сәгатенә 500 чакрым үтәргә сәләтле поезд белән алыштырылган. Япониянең Токио һәм Осака, Германиянең Вюрцбург һәм Ганновер шәһәрләре арасында тизлеге 300, Кытайда 350 километр-сәгатьле поездлар йөри. Парижга Франциянең көньягындагы Перпиньяннан көн саен түтәлдән яңа өзелгән яшелчә ташый торган товар поездлары сәгатенә 140 чакрым ара үтә. Транссебер тимер юл магистраленең (Мәскәү-Владивосток) озынлыгы 9289 чакрымга якын, ул 87 шәһәр, 16 зур елга аша уза, 207 чакрымы Байкал күле буйлап бара, бер якка юлны 6 көндә уза. Иң туры һәм озын тимер юл Австралиядә, 478 чакрым буена ул бер генә борылыш та ясамый. 2016 елда ачылган, дөньяда иң озын – Яңа Ефәк юлы дип йөртелә торган Мадрид (Испания)-Иу(Кытай) тимер юлы 13 052 чакрымга сузыла, әлеге товар поезды 21 көндә 8 ил аша үтә. South China Morning Post хәбәр итүенчә, 2035 елда Кытайның Гуанчжоу һәм Шанхай шәһәрләре арасында Hyperloop иң тизйөрешле поезды йөри башлаячак, элек 3 сәгатьлек юлны 15 минутта үтәргә мөмкин булачак: яңа маршрутның озынлыгы 175 чакрым, капсуланың тизлеге исә сәгатенә 1000 километрга җитә алачак! Әгәр мондый поезд җибәрелсә, Мәскәүдән Санкт-Петербурга 55 минутта барып җитеп булыр иде... Hyperloop технологиясен 2012 елда Илон Маск уйлап тапкан: пассажирларны ташучы капсула вакуумлы торба эченнән электромагнит кыры ярдәмендә хәрәкәт итә, бу бик зур тизлеккә ирешү мөмкинлеген бирә.

(“Интересно.сс”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

12 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00 «Манзара». 16+
8.00 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 16+
10.00, 23.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.35 «СЕБЕР КИЯВЕ». 16+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.30 «История побед. КамАЗ-мастер». 12+
15.00 «СОКРОВИЩА ЕРМАКА». 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00, 20.00, 21.00 Праздничный концерт, посвящённый Дню России. 16+
19.30, 22.05 Новости Татарстана. 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.40 «Шаян хәлләр». 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 0.40 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 17.05 «Музыкаль мәйдан». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05 «Музыка елгасы». Ренат Еникеев турында телеочерк. 16+
15.00 «Заман көзгесе». 6+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.05 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.35 «Адымнар». 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы». 6+
18.00, 22.05, 0.00 «Яңалыклар». 16+
18.20 «Ватандашлар». 16+
19.00 Россия көненә багышланган бәйрәм концертыннан турыдан-туры трансляция. 6+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ВАЛЬС-БОСТОН». 12+
11.10 «География вкуса». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00 «ДУША ШПИОНА». 16+
16.10 «Большой праздничный концерт, посвящённый Дню России «Мы - вместе». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «ДОМОПРАВИТЕЛЬ». 12+
21.30 «Один день в городе». 12+
23.00 «ВЕЧНОСТЬ МЕЖДУ НАМИ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00, 10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
6.10 «Символы России». 12+
7.00 «День России».
10.15 «Кто, кроме нас». 16+
11.10, 12.15, 15.15 «Империя. Петр I». 12+
15.50 Гала-концерт Всероссийского музыкального патриотического фестиваля «Своих не бросаем». 12+
19.10 «Михаил Задорнов. Мысли и предсказания». 16+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»
23.45 «Женщины Алтая». 12+

«РОССИЯ»

5.20 «УКРОЩЕНИЕ СВЕКРОВИ». 12+
7.15 «УКРОЩЕНИЕ СВЕКРОВИ. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 12+
11.00, 13.00, 17.00, 20.00 Вести.
12.00 Церемония вручения Государственных премий Российской Федерации.
13.30 «ЛИКВИДАЦИЯ». 16+
18.00 Большой праздничный концерт, посвящённый Дню России.
21.05 Вести. Местное время.
21.20 «МИСТЕР НОКАУТ». 12+
23.30 «НЕБО». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.05 Мультфильмы.
8.30 Легенды мирового кино.
8.55, 23.25 «АЛЕКСАНДР НЕВСКИЙ».
10.40, 22.30 «Александр Невский. За Веру и Отечество».
11.35 Исторические курорты России. «Анапа. Золотой берег».
12.05 «МИНИН И ПОЖАРСКИЙ».
13.50 Письма из провинции.
14.20 «Псковские лебеди».
15.00 «Петр Великий. История с французским акцентом».
15.45 «Вся Россия». Фестиваль фольклорного искусства.
16.30 «СЕМЁН ДЕЖНЁВ».
17.50 «Алексей Брусилов. Служить России».
18.30 Государственный академический Кубанский казачий хор. Концерт в Московском международном Доме музыки.
19.30 Новости культуры.
19.45 «Щедрин-сюита».
21.05 «ДЕВУШКА БЕЗ АДРЕСА».

«НТВ»

5.05 «Новые русские сенсации». 16+
6.00, 8.20 «ЧАС СЫЧА». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
10.20 «ПЁТР I. ПОСЛЕДНИЙ ЦАРЬ И ПЕРВЫЙ ИМПЕРАТОР». 16+
13.25 «ОТСТАВНИК. СПАСТИ ВРАГА». 16+
15.30, 16.20 «ОТСТАВНИК. ЗАЩИТА ДЕДОВА». 16+
19.40 «ОТСТАВНИК. БЛИЖНИЙ БОЙ». 16+
23.00 Праздничный концерт, посвященный 12 июня. 12+

Сишәмбе

13 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Төймә».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30 «Заман көзгесе». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Нәсыйхәт». 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
19.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Халкым минем». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «Удиви меня». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «МУЖ СЧАСТЛИВОЙ ЖЕНЩИНЫ». 12+
11.00 «Ученые люди». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
14.45 «Пять причин поехать...» 12+
15.00 «Ядовитые твари». 12+
15.30 «Игры разведок. Немузыкальная история». 12+
16.20 «ПРАКТИКА-2». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ОНА НЕ МОГЛА ИНАЧЕ». 12+
23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ВЕЛИКАЯ». 12+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ВАЛЮША». 12+
23.55 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 13.45 «Викинг Ролло - от изгнанника до завоевателя».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 15.50 «В ПОИСКАХ КАПИТАНА ГРАНТА».
10.15 «Наблюдатель».
11.15 XX век. «Мастера оперной сцены. Зураб Соткилава».
12.20 Цвет времени. Василий Поленов. «Московский дворик».
12.45 Новости. Подробно. Книги.
13.00 «Игра в бисер» «Поэзия Афанасия Фета».
14.40 «Забытое ремесло».
14.55 Линия жизни. Сергей Урсуляк.
17.15 «Передвижники. Николай Ярошенко».
17.45 Выдающиеся дирижеры XX века. Карлос Кляйбер и Венский филармонический оркестр.
18.30 «Ростов-на-Дону. Особняки Парамоновых».
19.00 «Почерк эпохи». «Василий Жуковский. «Верь тому, что сердце скажет...»
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Дмитрий Баранов. «Предметный» разговор, или Как вещи взаимодействуют с людьми».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Искусственный отбор.
21.40 65 лет Сергею Маковецкому. «Белая студия».
22.25 «МАКАРОВ».

«НТВ»

4.55 «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
20.00 «ЭФФЕКТ ДОМИНО». 16+
22.15, 0.00 «РЕАЛИЗАЦИЯ». 16+

Чәршәмбе

14 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». 16+
11.00, 0.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Бергәләп еңәрик».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...». 12+
19.00, 0.50 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 0.25 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 18.20, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.40 «Җир белән күк очрашканда». Зөлфирә Зарипова турында телеочерк. 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Кунак БИТ Шоу». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00, 0.15 «Гаилә учагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ОНА НЕ МОГЛА ИНАЧЕ». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
14.45 «Пять причин поехать...» 12+
15.00 «Ядовитые твари». 12+
15.30 «Анальгетики. Пить или не пить». 16+
16.20 «ПРАКТИКА-2». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ВЕЛИКАЯ». 12+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ВАЛЮША». 12+
23.55 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 13.45, 0.30 «Карл V. Миссия невыполнима».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 15.50 «В ПОИСКАХ КАПИТАНА ГРАНТА».
10.15 «Наблюдатель».
11.15, 23.35 XX век. «Вместе с Дунаевским».
12.10 «Первые в мире».
12.45 Новости. Подробно. Кино.
13.00 Искусственный отбор.
14.40 «Забытое ремесло».
14.55 «Монологи кинорежиссера. Станислав Говорухин».
17.15 «Библейский сюжет».
17.45 Выдающиеся дирижеры XX века. Леонард Бернстайн и Лондонский симфонический оркестр.
18.30 «Посёлок Юрино. Марий Эл. Шереметевский замок».
19.00 «Почерк эпохи» с Кириллом Кяро. «Янина Жеймо. Эталонная Золушка».
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Егор Сартаков. «Смысл названия поэмы Н.В. Гоголя «Мертвые души».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Абсолютный слух.
21.40 Власть факта. «Интеллектуальная собственность и информационная эпоха».
22.25 «ЗАПОМНИТЕ МЕНЯ ТАКОЙ».

«НТВ»

4.50 «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
20.00 «ЭФФЕКТ ДОМИНО». 16+
22.15, 0.00 «РЕАЛИЗАЦИЯ». 16+

Пәнҗешәмбе

15 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Классный час». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.10 «Сөенеч».
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00, 21.10, 0.50 «Соотечественники». 16+
18.00 «Юлчы». 16+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Погружение на 100». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Гаилә учагы». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.20 «Кунак БИТ Шоу». 16+
19.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
21.25 «Җир белән күк очрашканда». Зөлфирә Зарипова турында телеочерк. 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ОНА НЕ МОГЛА ИНАЧЕ». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
14.45 «Пять причин поехать...» 12+
15.00 «Ядовитые твари». 12+
15.30 «Владимир Крючков. Последний председатель». 16+
16.20 «ПРАКТИКА-2». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ВЕЛИКАЯ». 12+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Китайская мечта. Путь возрождения». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ВАЛЮША». 12+
23.55 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 13.45 «Брачная политика династии Габсбургов».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 15.50 «В ПОИСКАХ КАПИТАНА ГРАНТА».
10.15 «Наблюдатель».
11.15, 23.35 «Сомневаюсь в явном, верю чуду... Несколько встреч с академиком А.Б.Мигдалом».
12.10 «Первые в мире».
12.45 Новости. Подробно. Театр.
13.00 Абсолютный слух.
14.40 «Забытое ремесло».
14.55 Линия жизни. Владимир Краснопольский и Валерий Усков.
17.15 Пряничный домик. «Беломорские узоры».
17.45 Выдающиеся дирижеры XX века. Георг Шолти и Симфонический оркестр Баварского радио.
18.45 Цвет времени. Тициан.
19.00 «Почерк эпохи». «Михаил Салтыков-Щедрин. Сказки для взрослых».
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Константин Дудаков-Кашуро. «Художники звука. Как искусство изменило мир музыки».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 «12 стульев». Держите гроссмейстера!»
21.40 «Энигма. Владислав Сулимский».
22.25 «ЗАПОМНИТЕ МЕНЯ ТАКОЙ».

«НТВ»
4.55 «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
20.00 «ЭФФЕКТ ДОМИНО». 16+
22.15, 0.00 «РЕАЛИЗАЦИЯ». 16+

Җомга

16 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 16+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Юлчы». 16+
22.10 «КВН РТ-2023». 16+
23.10 «ПИРАТЫ ЭГЕЙСКОГО МОРЯ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.50, 18.20, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.50, 16.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30 «Тау астында». Фәүдәт Гыйләҗев концерты. 6+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Йөрәктән - йөрәккә». Хәйдәр Бигичев турында телеочерк. 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
19.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Туган җир». 12+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ОНА НЕ МОГЛА ИНАЧЕ». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ГДЕ-ТО ВО ВРЕМЕНИ». 16+
14.30 «Ученые люди». 12+
15.00 «Ядовитые твари». 12+
15.30 «Генерал Кинжал. Звездные часы Константина Рокоссовского». 12+
16.20 «ПРАКТИКА-2». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 Концерт «Навсегда». 12+
23.20 «Баня, водка, гармонь, Голливуд». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.30 «Удивительные люди. Новый сезон». 12+
23.55 «Истории Большой Страны». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 14.00 «Павел I».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 15.50 «В ПОИСКАХ КАПИТАНА ГРАНТА».
10.20 «ДЕТСТВО ГОРЬКОГО».
12.10 «Первые в мире».
12.45 Власть факта. «Интеллектуальная собственность и информационная эпоха».
13.30 «Уфа. Особняк Елены Поносовой-Молло».
14.55 «Забытое ремесло».
15.10 «Сергей Дрейден».
17.15 Письма из провинции.
17.45 Выдающиеся дирижеры XX века. Клаудио Аббадо.
18.45 «Билет в Большой».
19.45 «Смехоностальгия».
20.15 «Железный мужик» Ивана Грозного».
21.00 Линия жизни. Юрий Ряшенцев.
21.55 «ПРОЩАНИЕ СЛАВЯНКИ».
23.15 «2 Верник 2».

«НТВ»
4.55 «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «ЭФФЕКТ ДОМИНО». 16+
22.15 «РЕАЛИЗАЦИЯ». 16+

Шимбә

17 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 «Иҗатханә». Рабит Батулланың бәйрәм кичәсе. 12+
16.00 «Уроки истории». 6+
17.00 «Татар халык җырлары».
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит-шоу». 16+
23.00 «РАЗВОД ПО-ФРАНЦУЗСКИ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Музыка елгасы». Ренат Еникеев турында телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Җырлашып яшик, туганнарым!» Георгий Ибушев концерты. 16+
17.15 «Юксыну..» Вафирә Гыйззәтуллина җырлый. 6+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Гомер чишмәм». Рәсим Низамов концерты. 16+
23.00 Спектакль «И машина, машина, җитте минем башыма». 16+

«ЭФИР»
5.00, 8.30 «Ученые люди». 12+
5.30 «Великие полководцы». 16+
6.00 «Легенды кино». 16+
6.30 «Наукограды». 12+
7.00 «Супер МЯУ».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Тайные механизмы природы. Сезон 2». 12+
9.00 «РАЗ, ДВА! ЛЮБЛЮ ТЕБЯ!» 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «СОСЕДИ ПО РАЗВОДУ». 12+
14.45 «Пять причин поехать...» 12+
15.00 «Удиви меня». 12+
15.45 «Я ТРЕБУЮ ЛЮБВИ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЭЛИЗАБЕТТАУН». 12+
23.10 «ДВОЙНОЕ СЧАСТЬЕ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
8.35 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.05 «Все звезды русского космоса». 12+
12.15 «В личном счастье отказано». 12+
14.20 «ОШИБКА РЕЗИДЕНТА». 12+
17.10, 18.20 «Абракадабра!» 16+
19.55 «Кто хочет стать миллионером?»
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.20 «МАЛЕНЬКАЯ МИСС СЧАСТЬЕ». 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
12.00 «Доктор Мясников». 12+
13.05 «ПРОСТИ ЗА ЛЮБОВЬ». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 Концерт над Волгой. Посвящение русской провинции.
22.40 «СИНДРОМ ОТЛОЖЕННОГО СЧАСТЬЯ». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.40 «ПРОЩАНИЕ СЛАВЯНКИ».
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «ВО ВЛАСТИ ЗОЛОТА».
11.55 «Португалия. Дикая природа на краю земли».
12.55 «Страна волшебника Роу».
13.30 «КОНЕК-ГОРБУНОК».
14.50 Парад победителей телевизионного конкурса юных музыкантов «Щелкунчик».
16.45 «О БЕДНОМ ГУСАРЕ ЗАМОЛВИТЕ СЛОВО».
19.45 «Тайны Болливуда».
20.30 «ЗИТА И ГИТА».
23.05 «СКАЗКИ... СКАЗКИ... СКАЗКИ СТАРОГО АРБАТА».

«НТВ»
4.55 «Жди меня». 12+
5.45 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
7.25 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!» 16+
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Модный vs Народный». 12+
14.20 «Своя игра».
15.20 «Игры разумов».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Секрет на миллион». 16+
22.25 «Звезды сошлись». 16+

Якшәмбе

18 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Фәрештә түгел». Илсөя Бәдретдинова концерты. 16+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 «Полосатая зебра».
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы-шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Ачыктан ачык». 16+
11.00 «Тархан». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «Пар алма». Илназ Баһ һәм Гүзәл Идрисова концерты. 12+
14.55 «Сөенеч».
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00, 0.45 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 12+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «ИЗВИНИТЕ, МЫ ВАС НЕ ЗАСТАЛИ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 Спектакль «Алхимик». 16+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Илдус Әхмәтҗанов турында телеочерк. 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 Спектакль «Алты кызга бер кияү». 16+
16.20 «Кәмит Җәвит». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.00 Спектакль «Китәм инде, китәм». 16+

«ЭФИР»
5.00 «Ученые люди». 12+
5.30 «Великие полководцы». 16+
6.00 «Легенды кино». 16+
6.30 «Наукограды». 12+
7.00 «Супер МЯУ».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Тайные механизмы природы. Сезон 2». 12+
8.30 «География вкуса». 12+
8.45 «Я ТРЕБУЮ ЛЮБВИ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «УЛЫБКА БОГА, ИЛИ ЧИСТО ОДЕССКАЯ ИСТОРИЯ». 12+
15.10 «Блин. Ком». 16+
16.00 «РАЗ, ДВА! ЛЮБЛЮ ТЕБЯ!» 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «МОСТЫ ОКРУГА МЭДИСОН». 16+
23.10 «АВАНТЮРИСТКИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Космические истории». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь своих». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Екатерина Великая. Женская доля». 16+
13.05 «СПРОСИТЕ МЕДСЕСТРУ». 16+
17.00. 16+
19.00 «Призвание». Премия лучшим врачам России.
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»
23.55 Подкаст.лаб «Легкие деньги». 16+

«РОССИЯ»
6.00 «ЛЮБОВЬ ИЗ ПРОБИРКИ». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.40 «Большие перемены».
12.45 «ПЕРЕВОД С НЕМЕЦКОГО». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.25 «О БЕДНОМ ГУСАРЕ ЗАМОЛВИТЕ СЛОВО».
10.10 «Ростов-на-Дону. Особняки Парамоновых».
10.40 «СКАЗКИ... СКАЗКИ... СКАЗКИ СТАРОГО АРБАТА».
12.25 Письма из провинции.
12.55 «Закон журавля».
13.35 «Забытое ремесло».
13.50 Невский ковчег. Теория невозможного. Юрий Борисов.
14.20 «Музей Мирового океана. Власть Воды».
15.10 «САМЫЙ МЕДЛЕННЫЙ ПОЕЗД».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Пешком...»
17.40 «Театральная летопись». Юрий Соломин.
18.35 «Романтика романса».
19.30, 19.45 Новости культуры.
20.25 «АМЕРИКАНСКАЯ ДОЧЬ».
22.00 Екатерина Осмолкина, Кимин Ким, Анна Самострелова в балете П.И. Чайковского «Спящая красавица».

«НТВ»
4.50 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Ты супер! 60+». 6+
23.00 «Маска». 12+

Сәрхуш күрше – хәтәр кеше

Исереккә сәлам бирмә дигән мәгълүм сүз, иң әүвәл, аннан ераграк булырга тырыш дигәнне белдерәдер. Әгәр күршең эчкече икән, аннан әллә ни ерак китеп тә булмый, очрашырга, аралашырга, аның кыланмышларына түзәргә дә туры килә шул. Аларның хәвеф-хәтәр китереп чыгару куркынычы да зур бит әле.

Әлмәт каласында яшәүче 1975 елгы Айдар Хурамшин да эчәргә ярата, ләкин эшләмичә йөрүче айнымаслар рәтеннән түгел. Элегрәк шофер булып эшләгән, соңгы вакытларда шабашкаларга йөреп акча таба, хатыны, 10, 16 яшьләрендәге кызы, улы белән тора. Янәшә фатирда яшәүче Руслан ошбу гаиләне дә, салмыш чакта тыныч холыклы дип Айдарны да уңай бәяли. Ләкин А.Хурамшинның исерек чакта кызып, котырынып китә торган гадәте булуын, шул сәбәпле 2021 ел азагында үтерү белән янауда гаепләнеп хөкем ителүен һәм зарар күрүче мәрхәмәтлелек күрсәтү аркасында гына җәзасыз калдырылуын, ышанычсыз зат буларак полициядә исәптә торуын, еш кына административ җаваплылыкка тартылып килүен өстәргә, димәк, аның да бик юньле кеше булмавын искәртергә туры килә.

Узган ел көзендә А.Хурамшин өлкәнрәк Фидаил Вафин белән шәһәр янындагы Колшәрип авылындагы шәхси хуҗалыкта эшли. 2 ноябрьдә көн буе профнастил беркетә алар, кичке якта такси белән Айдар йорты янына кайтып туктыйлар, үзләре әйтмешли, арганнарны басу ниятеннән тамак чылатырга булалар, күрәсең, күплэп эчәргә уйламыйлар, юкса, кибеттән бер «чәкүшкә» аракы, литр ярым сыра гына тотып чыкмаслар иде.

Айдар фатиры кухнясында шуларны эчеп утырганда, хуҗабикә кайтып кергәч, аңа комачауламау йөзеннән, ирләр подъездга чыга, шешә һәм стаканнарны 4-5 нче катлар арасындагы тәрәзә төбенә тезәләр. Бер хутланып киткәч туктый алмый алар, берничә тапкыр кибеткә барып кайталар, үзләре үк әйтүенчә, бик нык исерсәләр дә эчүне дәвам иттерәләр, шунда ук тәмәке көйрәтәләр һәм, әлбәттә, гәр килеп сөйләшәләр. Димәк ки, ошбу подъездагы фатирларда яшәүчеләрнең тынычлыгын бозалар.

Бу юньсезлек бик озак дәвам итә. Айдарның балалары, хәләл җефете йокларга ята, төнге сәгать 11 ләр тирәсендә хатын-кыз иренең җәлт кенә өйгә кереп чыгуын сизә, күп тә үтми фатир ишеге артында кемдер кайнашкан тавыш ишетә. Ишекне этә-төртә ача ул, чөнки лаякыл исерек ире комачаулык итә, шунда ук аркасы белән торган Айдарның алга иелеп канга баткан кешене өстерәве күренә, коты алынган хатын чәбәләнеп, нәрсә булды, дип кычкыра башлый, ир заты хәрәкәтсез гәүдәне коридорга алып кереп идәнгә сала. А. Хурамшин да канлы куллары белән башына ябышып шул тирәгә утыра.

Әлеге шау-шуны ишетеп күрше Руслан килеп чыга. Йөзе-бите дә канга буялган ир-атның өченче катта торучы Алексей Кузнецов икәнен таный ул, «112» хезмәтенә шылтыраткач, Айдарга юынып чыгарга куша, Алексейның йөрәк тибеше сизелмәгәч, тагын шылтыратып ашыгыч ярдәмне ашыктырып карый. Әмма әлеге кабалануларның хаҗәте булмый, 10-15 минуттан килеп җиткән табибләргә 43 яшьлек ир-атның үле икәнен теркәргә генә кала.

А.Хурамшин шул мәлдә үк: «Мин үтердем, үзем җавап бирәчәкмен», – дип сөйләнеп йөри. Нәрсә бүлешә алмадыгыз дигән сорауга җавап бирми. Гадәттә, моның ише фаҗигаләрнең төлгә алырдай сәбәбе дә булмый. Өлкән яшьтәге әнисе белән генә яшәгән буйдак А. Кузнецовның балаларыгыз шаулашып ял итәргә комачаулый дип югары фатирдагы Хурамшиннарга ризасызлык белдергән чаклары булган, ул көнне подъездагы тәртипсезлекне дә игътибарсыз калдырмаган. Әлмәттәге «Юбилейный» спорт сараенда сантехник булып эшләгән, беркайчан да закон белән каршылыкка килмәгән юньле кеше ул үзе. Полиция хезмәткәрләре уятып тетрәндергеч хәбәрне ирештергәч, ашыгыч ярдәм табибләренә 73 яшьлек бичара анага ярдәм күрсәтергә туры килә.

4-5 нче катлар арасындагы мәйданчыктагы бик хәтәр хәлләр килеп чыга. Күршеләр әйткәләшә башлагач, Ф. Вафин арага кергәндәй итә, үзләренең беркемгә дә комачауламауларын, тиздән таралышачакларын төшендерергә тотына. Шул арада хәмер сөреме тәмам аңгыраеткан А.Хурамшин фатириндагы эшкә ашарга алып бара торган пакеттагы кара саплы пычакны эләктереп чыга һәм шунда ук котырынып һөҗүм итә. Экспертиза аның А.Кузнецовка 13 мәртәбә чәнчүен, мәрхүмнең, башлыча, корсактагы җәрәхәтләр нәтиҗәсендә тиз арада үлеп китүен күрсәтә.

Әлеге хәл шешәдәш Ф. Вафинны да өркетә, ул шунда ук урамга чыга, урындыкта йоклап яткан төп шаһитны полиция хезмәткәрләре уята. Вакыйганы гаепләнүче белән бер чама сурәтле алар, Айдарның гаебен шомартып күрсәтергә тырышуы сизелә, әмма аңлы рәвештә кеше үтерүен таный, кырыс җәза бирмәүләрен сорый, бердәнбер улын югалтып ялгыз калган карчыктан гафу үтенүен дә белдерә. Тикшерү комитетының Әлмәт бүлегеннән Карина Артамонычева бер ай дигәндә җинаять эшен судка җиткерә. Хөкемдар хәтәр күршене 9 елга ирегеннән мәхрүм итәргә карар кыла. Аннан кала рухи зыян өчен 800 мең сум, күмү чыгымнарын капларга 31100 сум түләтергә дип белдерә.

* * *

Күршеләр икесе дә эчкече икән, алар кухня һәм башка уңайлыклары уртак булган «коммуналка»да яшәсә, пычаклы бәрелешләр куркынычы тагын да арта. Чистайдагы шундый торактагы фатир дип йөртелгән бүлмәләрнең беренчесендә 60 яшендәге Светлана Миңнебаева, икенчесендә 1967 елгы Сергей Маханов гомер итә. Күрәсең, ошбу сәрхушләр белән бер түбә астында көн күрергә теләүчеләр булмаганга, өченчесе буш тора.

С. Маханов элегрәк хатыны, 1993 елгы кызы белән яшәгән, алты-җиде ел элек кызы башка торакка күчкән, 2021 елда хатыны да ташлап киткән һәм элеваторда эретеп ябыштыручы булып эшләгән ялгызак абзый эчкечеләр өчен гадәти тормыш рәвешенә күчкән, ягъни вак-төяк йомышлар үтәп, чүплекләрдә актарынып яши башлаган. Әлбәттә ки, гомуми кухняда үзенә тиң кунакларны еш җыйган.

С. Миңнебаева Аксубай районындагы чуаш авылында 11 балалы гаиләдә туып-үсә, һөнәри училищеда укып чыккач, Чистай сәгать заводында, икмәк комбинатында, елгачылар җәмгыятендә эшләгән. 2008 елда кызы шушы фатирны алып биргән, 2019 елда ире үлеп киткәч, ялгызы калган. Аның янына атна саен диярлек Түбән Камада яшәүче оныгы Данил кайтып йөри, ошбу яшүсмер әбисенең эчәргә яратуын әйтә, бабай үлгәч аеруча нык сала башлады, дәваланып караган чаклары да булды, ләкин берәр айдан тагын йөгәннән ычкынды, дип сөйли.

Кыскасы, пар килгән кешеләр яши коммуналкада, үзара ызгышлар өчен сәбәпләр дә чыкмый калмый. С. Миңнебаева күршесе шешәдәшләрен җыеп утырганнан соң азыктөлек, савыт-саба һәм башка шәхси әйберләре юкка чыгудан зарлана, агайның, газны яндырып калдырып, урамга чыгып китүе аркасында чак кына янгын чыкмый калуын искә төшерә, янгынчылар ишекне ватып кереп сүндерде, ди. Өлкән яшьтәге күршеләр арасында мөнәсәбәтләр киеренке вә кызу булганга, монда янгынның икенче төрләренә кабынып китү куркынычы да була.

Узган елның 3 ноябрендә ул чакта 17 яшендәге студент Данил әбисе янына кайта. Икенче көнне иртәнге сәгать 6 тулганда ук домофон шылтырый, С. Махановның кунакларны кертүе ишетелә, әбисе алар янына чыгып китсә, онык йокыга тала. Төш вакытында уянып урамга чыгышлый кухняда йокымсырап утырган хатын-кыз һәм ир-атны күрә ул. Ә хуҗалар бүлмәләрендә черем итә. Бар да гадәттәгечә һәм тыныч була.

Мәхшәр Данил дуслары белән йөреп төнге сәгать 11 ләрдә кайтып кергәч башлана. Ул чакта кунаклар таралышкан була. Кәнәфидә яткан карчык, оныгы кайтканны тоеп, урыныннан тора, аңа ашарга да хәзерләп бирә, чәйнек тотып кухняга чыгып киткәч, аңкы-миңкә хәлдәге С.Миңнебаеваның: «Сергей, тор, уян!..» – дип чырылдап кычкырганы яңгырый. Данил күрше бүлмәгә кергәч, идәндә канга батып чалкан яткан С. Махановны күрә, аның футболкасын җыерып карагач, гәүдәдә пычак җәрәхәтләре булуын ачыклый. Аның чакыруы буенча килеп җиткән ашыгыч ярдәмнең ярдәме кирәк булмый инде абзыйга. Соңрак үткәрелгән экспертиза аның күкрәк, муен, кул, аяк тирәсендә 11 яра саный, йөрәк, сул як үпкә җәрәхәтләнү, эчкә литр ярым чамасы кан саву аркасында үлүен белдерә.

Моның кем эше икәнен ачыклау өчен, әллә ни баш ватарга туры килми. Икенче көнне айный төшкәч биргән беренче рәсми күрсәтмәсендә үк, С.Миңнебаева, үз сүзләре белән әйткәндә, туктаусыз эчеп, дусларын җыеп һәм башка начарлыклар кылып тәмам туйдырган С.Махановны бүлмәсенә кереп чәнчеп үтерүен сөйләп бирә. Җинаять коралын алдан шкафына яшерә, аннан соң идәндәге җәймә астына тыга ул. Барысы да ачык кебек булса да, тикшерү комитетының Чистай районара бүлегеннән А.Ганиевага ачыклыйсы мәсьәләләр җитәрлек була. Әйтик, әби кеше оныгы кылган явызлыкны үз өстенә алмыймы дигән сорау туа. Аннан соң ул сөйләгәннәр даими рәвештә үзгәреп тора. Мәсәлән, алдан йоклап яткан кешегә кададым дисә, икенчесендә, диваннан өстерәп төшердем, уяттым, әрләшә башлагач кабынып киттем, дип белдерә. Шул рәвешле, гаепне читкә этәрми ул, буташтырып сөйләүләрен исереклеккә сылтарга туры килә. Монысын үзе дә әйтеп тора ул, изоляторда озак вакыт эчмичә утыргач исемә төште дип, соңгы аңлатмаларына өстенлек бирергә куша. Шулай да өстәмә тикшерү чаралары, мәсәлән, оныгы Данил белән кара-каршы утырып сорау алулар (очная ставка) үткәрергә туры килә. Ахыр чиктә, явызлыкның оныкы кайтканчы кылынуы дәлилләнә, ягъни йоклаган, бу хәлне оныгы кайтканнан соң, бераздан исенә төшергән булып чыга.

Әлеге мәхшәрнең төгәл вакытын әйтә алмый ул, ләкин моның кичке сәгать 8 дән соң булуы ачыклана. Бу инде ул көнне коммуналкада бәйрәм иткән һәм иртәрәк чыгып киткән өч сәрхушкә дә шик төшә дигән сүз. Ахыр чиктә С. Миңнебаеваны аңлы рәвештә кеше үтерүдә гаепләгән җинаять эше март аенда Чистай шәһәр судына тапшырылды. Хөкем чыгарылмаган әле.

Наил ВАХИТОВ.

КАЕНЛЫ СӨЛГЕЛӘРЕ

Гадәттә, җырчы, биючеләр бик кеше сөючән була, бер сәхнә тәмен татып алган артистлар буларак, алар ялгыз калып озак уйланып-моңаеп утырырга яратмый. Һәм киресенчә, ялгызлыкны сөйгәннәр сәхнәдә үз-үзләрен күрсәтә, авызларына каратып сөйли, кылана белми. Икенче төрле әйткәндә, кеше табигатенең билгеле бер сыйфатлары теге яки бу һөнәргә ирешүдә ярдәм итә. Әйтик, җырчы яки биюченең озаклап чигү чиккәнен күз алдына китерүе кыен. Йә булмаса фән эшлеклесенең сәхнәдә сикереп-сикереп биюен күрү сәер тоелыр иде. Әмма бик сирәк кешеләрдә бер-берсенә капма-каршы холык сыйфатлары бергә кушылып китә һәм алар төрле һөнәрләрне үзләштерергә мөмкинлек бирә.Түбән Каманың Каенлы авылында кырык елдан артык мәдәният эшен оештыручы Фәүзия Әхмәтшина – әнә шундый сирәк очрый торган шәхесләрнең берсе.

Фәүзия ханымны Түбән Камада гына түгел, Казанда да инде күпләр белә. Ул 1991 елда ук Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә лаек. Каенлы авылында «Тамаша» исемле халык театрын җитәкли. Артистларның Казанга килеп тә спектакль күрсәткәне бар. Фәүзия ханым үзе хатын-кыз ролен иң шәп башкаручы буларак театр фестивалендә зур бүләккә дә лаек булган. Ф.Әхмәтшина җитәкчелегендә эшләп килгән «Хатирә» фольклор ансамблен белмәүчеләр, алар сәхнәләштергән «Сөмбелә», «Кунаклашу йоласы»н, «Карга ботка»ларын күрмәгән кеше районда сирәктер.

«Һәр авылга – үрнәк мәдәният йорты» республика бәйгесендә дә Каенлы клубы беренчеләр рәтендә. Ә бер елны Ф.Әхмәтшина «Мәдәният йортларының иң яхшы директоры» республика бәйгесендә баш бүләккә лаек булган.

Менә шул җор телле, һәм җырга, һәм биюгә оста, район мәдәният идарәсен җитәкләрлек куәсе булган ханым сәгатьләр буе басылып чигү чигәр дип кем уйлаган? Ничек кенә чигә әле! Татарстан Мәдәният министрлыгы республикабыз Рәисе Р.Миңнеханов ярдәме белән үткәргән «Татарстанның мәдәни башкаласы» бәйгесенә Түбән Кама районы үзешчәннәре үз осталыкларын күрсәтергә Казаныбызга килгәч, аларны тамаша кылырга җыелган башкала халкының күзләре шакмак булды. «Сәйдәш» мәдәният сараена килеп керешкә кунакларны сый-нигъмәт белән каршы алдылар. Кыстыбый, каклаган каз, авыл мичендә пешкән икмәк, яңа аертылган каймак шәһәр кешесенең төшенә дә керми. Шуңа да карамастан, күчтәнәчтән авыз иткәннән соң, бөтен кунакларның күзе чиккән сөлге, мендәр тышлыкларына төште. Бөтенесендә бер сорау – болар кулдан чигелгәнме, әллә кул машинасы ярдәмендә эшләнгәнме, дип гәпләшәләр. Ни кызганыч, бүген берьюлы шулкадәр кул чигүен күрү сәер. Әмма мәдәни башкала исеменә дәгъва кылган район үзешчәннәренең меңьяшәр Казан каласына кул машинасы белән чиккән сөлге алып килүе аннан да сәеррәк кебек. Халык кызып-кызып бәхәсләшкән арада милли кием кигән район үзешчәннәре җырлый, бии, тамашачыны биетә. Музыка тынганын гына көтеп, арадан берәү чиккән сөлгеләр белән кызыксынды. Һәм шул вакыт дистәләгән авызлар, чәйнәп бетермәгән күчтәнәч чәкчәк, бавырсакларны да онытып, кинәт тукталды. Боларның күбесен Каенлы авылында кырык елдан артык клуб мөдире булган Ф. Әхмәтшина чиккән ләбаса! Әле генә барысын да уздырып җырлаган һәм очып-очып биегән Фәүзия ханым шундый сәләткә ия дип кем уйлаган. Хәзер авылларда, гомумән, чигү бетеп бара. Каенлыда исә, күр әнә, сөлгеләрдәге милли бизәкләрдән күзләр камаша. Ф.Әхмәтшина үзе чигеп кенә калмый, авылдашларын да кызыктырып, «Оста куллар» түгәрәге оештырып җибәргән. Коронавирус котырган арада да бер дә төшенкелеккә бирелмәгәннәр, җыйнаулашып чигү чиккәннәр. Каенлы сөлгеләренең даны авыл эченә генә сыймыйча, бөтен районга таралган. Авыл, район Сабан туйларында Фәүзия апа һәм аның авылдашлары сөлгеләре һәрвакыт иң түрдә мәйданның төп бизәге булыр. Каенлының «Хатирә» фольклор ансамбле дә бер район чарасыннан калмыйча катнашып бара. Артистларның җидесендә дә – кулдан чигелгән алъяпкычлар.

Ф.Әхмәтшина хәзер сәхнәләштерүче режиссер вазыйфасында. Ул тәрбияләп үстергән яшь белгеч Айзилә Бузикова исә – мәдәният йортында сәнгать җитәкчесе. Мине җырларга да, биергә дә, хәтта чигәргә дә Фәүзия апа өйрәтте, дип Айзилә остазына рәхмәт әйтеп туя алмый.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 09.06.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2621

16+